www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

№ 46 (1462) 24 ноябрь 2023 ел

Татарстанда язылу индексы – П2355.

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga



6

Татар халкының яраткан әдибе Гадел Кутуйны 1944 елның көзендә Казан каласына ялга кайткан чакта Татарстанның мәдәният министры итеп тә куярга ниятлиләр, әмма ГКБ бөтенләй дә булмаган «җинаять»тә гаепләп, аны кире кага.



12-13

Г.Тукай әкиятләрен бизәгән рәсемнәре буенча рәссам Фәйзрахман Әминев йөз меңләгән укучыга таныш һәм кадерле, әмма рәссам үзе 1979 елда республиканың Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләген ала алмый кала.

14-15

Магнитогорск каласында туган Виктор Хомяков сугыш елларында фашистларның «Освенцим» концлагерын, аннары совет лагерьларын уза, ә 1960 елда хәрби самолет сынагандагы каһарманлыгы өчен Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә.

Әдип сүзе яши набат булып Илгә тапшырылган хатларда!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- 2024 елның 1 гыйнварыннан эшләмәүче пенсионерларның пенсияләрен 7,5 процентка арттыру турында закон кабул ителде.
- Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов «Казан» агросәнәгать паркында авыл хуҗалыгы ярминкәсендә булды.
- Гыйнвардан Татарстанда күп фатирлы йортларда капиталь ремонт өчен кертем артачак.
- Казан шәһәре Хәрби госпиталендә намаз уку бүлмәсе ачылды.
- Казахстанда композитор Нәҗип Җиһановның тормышы һәм иҗатына багышланган чаралар узды.
- Казанда Мәҗит Гафури исемендәге Башкорт дәүләт драма театры гастрольләре узды.
- Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры Төркиянең Истанбул шәһәрендә узган Халыкара хатын-кыз драматурглар фестивалендә катнашты.
- Казан хафизы Кувейтта Коръән укучыларының халыкара бәйгесендә өченче урынны яулады.
- Пенза өлкәсенең Татар Кынадысы авылында якташлары, күренекле татар язучысы Гадел Кутуйның тууына 120 ел тулуга багышланган чаралар узды.
- Киров өлкәсендә Татар мәгърифәте көннәре үтте.
- Уфада «Идел» халыкара башкорт һәм татар җыры фестивале узды.
- Сарман үзәк балалар китапханәсендә Шәүкәт Галиевнең тууына 95 ел тулу уңаеннан «Балалар әдәбиятында Шәүкәт Галиев» дигән әдәби сәгать үткәрелде.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

26 ноябрь – Әниләр көне.

27 ноябрь – Казанда беренче троллейбус линиясе эшли башлауга 75 ел (1948).

28 ноябрь – язучы Гадел (Гаделша) Нурмөхәммәт улы Кутуй (Кутуев)ның тууына 120 ел (1903–1945):

«Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Сине сагынган саен, миндә көч-дәрт арта, рухым канатлана. Чит илдә йөреп мин ачык аңладым: ...кеше өчен үз иленнән дә изгерәк, үз иленнән дә кадерлерәк, үз иленнән дә гүзәлрәк ил дөньяда юк ул».

– пианист, педагог, профессор, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Ирина Сергеевна Дубининаның тууына 100 ел (1923-2021).

СЫНАМЫШЛАР

24 ноябрьдә көн матур булса, җылы кыш фаразлана, ямьсез булса – киресенчә ● 25 ноябрьдә яңгыр йә кар яуса, 4 декабрьгә кадәр көннәр җепшек тора ● 27 ноябрьдә яңгыр яуса, киләсе елда бодай уңа; агачларны бәс сарса, солы уңа ● 29 ноябрьдә көчле җил иссә, 19 декабрьгә кадәр буран котыра.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **7 сәгать 37 минутта** чыкты, һәм ул **15 сәгать 25 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **7 сәгать 48 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **19 минутка** кыскарачак һәм киләсе җомгада, ягъни **1 декабрьдә 7 сәгать 29 минут** тәшкил итәчәк.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Ноябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 26, 27 ноябрь.**

* * *

Гадәттә, тулы айдан айның соңгы чирегенә кадәр **(27 ноябрь – 5 декабрь)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1445 ЕЛ

Бүген җөмәдел әүвәл аеның 11 нче көне

ПРЕМЬЕРА

Вахит ИМАМОВ

ТӘХЕТНЕ ХАН ТАШЛАМАС...

Г.Камал исемендәге академия театры Ркаил Зәйдулланың «Игезәк» атлы, моннан 20 еллар элек үк язылган драмасын сәхнәгә чыгарды. Әсәрнең сюжетын да, сәхнәдәге артистлар уенын гади, җиңел, ансат аңлаешлы, дип кенә булмый.

Безнең Англия тарихында король Ричардлар нәселеннән булган туганнар арасыннан берсенең икенчесен тимер битлек кидереп төрмәгә ташлаттыруын, әмма кырын эшнең егерме елдан соң да тарих аренасына калкып чыгуы турында укыган һәм хәтта бу темага куелган фильмнарын да караган бар иде. Тәхеттә утырырга лаеклы хакимдар булса да, фәкать таҗ һәм власть турында гына хыялланган оятсызының бертуган абыйсын төрмәгә ташлаттыруы күңелләрдә ярсу уята, кабих җанны гадел җәзага тартылуын сорап каннар кайный иде. Гәрчә үз дәүләтләребез тарихында да туганнар арасында берсен-берсе суюлар, хәтта угыл кешенең үз атасының гомерен кыю кебек гайре табигый хәлләр дә байтак булган инде.

Алтын Урда тарихында андый коточкыч суюларга атаклы Үзбәк хан нигез салган, диләр. Бер дистә хатыннарыннан туган угыл һәм оныклары аның тәхетенә нәфес сузмасын өчен, ул 1312 елда ук властька килгән чакта хәтта 110 га якын туганын үтерттергән, дигән мәгълүмәтләр дә бар. Икенче чыганакта «ул 42 туганын үтерттергән», дип гаебен «киметәләр». Әмма үз туганнарын күпләп үтертүдә аңа тиңнәр бик тә сирәк табылган, монысы хак.

Яман чир үтә йогышлы була бит, Үзбәк хандагы «гадәт» тиз арада оныкларына да күчкән. Үзеннән соң тәхетне өлкән угылы Танибәккә вәгъдә итеп киткәч, мондый «гаделсезлек» улы солтан Бирдебәк күңелендә дә «нахакка рәнҗетелү» хисе уятмыйча калмый. Кавказга ясалган бер поход барышында каладар итеп тау башында калдырылган Бирдебәк яшерен юллар белән качып кайта да, әүвәл этисе Танибәкне, аннары аның 11 варисын суеп үтерә. Күзе һәм аңы власть белән томаланган Бирдебәк хәтта Танибәкнең 8 айлык угылын да кызганып тормый, аның аякларыннан тотып, башы белән стенага бәрә... Ләкин тәкъдир дигәннәре Бирдебәкнең үзен дә аямый, аны 1359 елда чираттагы тәхет дәгъвачылары суеп үтерә һәм Алтын Урда тарихында 20 ел эчендә 25 хан алышынган канлы буталыш, канлы мәхшәр чоры башлана. Мондый мәхшәр 1380 елда тәхеткә Туктамыш хан менеп утырганнан соң гына тукталгандай була. Мәгәр мәгълүм – аны да 1406 елда сатлыкҗан Идегәй яраннары юк итә. Бу коточкыч мәхшәр Алтын Урда дәүләте җимерелү белән тәмамлана.

Р.Зәйдулла Бирдебәк хан идарәсен тәхет язмышына тәэсир кертү өчен иң кулай чор, дип сайлап алган сыман. Тик аңа, әлбәттә, тарихи эзлеклелекнең бөтенләй кирәге юк, ул тәхеткә шагыйрь күзаллавы һәм, әлбәттә, шагыйрь нәфесе буенча, үз «братын» – шагыйрь кешене утыртып карамакчы була. Моның өчен үтә җайлы һәм ышандыргыч ысул да бар сыман. Бату ханның кырыклап хатыныннан ким дигәндә бер йөз дәвамчы таралган бит. Ул йөздән соң икенче буында – бер мең. Андый бетмәс-төкәнмәс оныклар арасында, кан шаяртуы буенча, бер-берсенә игезәкләрдәй охшаш туганнар пәйда булу да мөмкин. Һәм менә Зәйдулла әсәрендә дә Бирдебәк аңа ике су тамчысыдай охшаш туганы – шагыйрь Әхмәт Казани белән очраша. Казан шагыйре Әхмәт, әлбәттә ки, ханлыкта гадел кануннар буенча яшәүче тәртип урнаштыру яклы. Бирдебәк ханга да тәхетне вакытлыча аңа биреп тору кызык. Ниһаять, Р.Зәйдулла фәрманы буенча, алар үзара килешә дә, тәхеткә бер тәүлеккә генә шагыйрь Әхмәт менеп утыра. Иллә мәгәр тәхетнең дә б-и-и-к йогышлы чире бар бит, каһәр. Хан менеп утырганчы гади генә урындык булса, ханның арты тиюгә, урындык шул мизгелдә власть тулы тәхеткә әверелә. Ә тәхет иясе – Аллаһы Тәгаләнең җир йөзендә билгеләп куелган идарәчесе бит ул. Күктә – Аллаһ үзе дә, җирдә – хан иң көчле! Тәхеткә арт саны тигән бәхет иясенең гамәлләрен тикшерергә дә һичкемнең хокукы юк. Чөнки ул гына иң гадел, иң лаеклы, ул – пәйгамбәр!

Өстәвенә, тирә-юньдә дә аның кубызына биеп торырга әзер яраннар табылмыйча калмый. Диван бәге белән карачы хәзер яңа ханның иң кансыз әмерен үтәүгә дә әзер, тик хан аларның изгелеген генә онытмасын һәм зуррак түрә урынын кызганмасын. Хәтта, кичә генә Бирдебәк хан белән түшәк бүлешкән Ханикә дә «шагыйрь Әхмәт»не «мең кәррә назлырак» ир дип тәкърарлый бит, мондый даннан ничек баш тартасың?!.

Кара гавам белән дәрвишләр арасында ханның «не настоящий» булуына шик белдерүчеләр табылмыйча калмый. Танышбәк атлы кардәше Әхмәт Казанига Бирдебәкнең малай чагында ук аның белән бил алышып һәм сер бүлешеп үсүен искә төшерә һәм бүгенге «хан»ның хәтта сөйләмендә дә өр-яңа тәсмерләр пәйда булуына киная ясый. Тик тәхет белән хушлашу – мөмкин гамәл түгел! Кичә генә шагыйрь булып йөргән «хаким» Әхмәт Танышбәкне суеп котылмакчы була. Мәгәр җансакчылар да уянган шул инде, алар бар халыкны бергә күтәреп, бар кешене дә «таплап» кына чәнчелдереп төшерү турында гапь кузгата. Яңа фетнә, гомумхалыкны берләштергән бунт куера. Әхмәт Казани да янә башына капчык киеп, халык хөкеме каршына тезләнергә мәҗбүр...

Финал хәл ителми, нәтиҗәне һәрбер тамашачы фәкать үзе йомгакларга тиеш. Әмма уйланырлык урыннары чиктән ашкан. Әле утыз еллар элек кенә миллионлаган инсан коммунистлар фиркасеннән котылып, гадел хакимият, һәрбер адәм баласын яклаячак гадел кануннар урнаштыру турында хыялланган иде. Бугаз ярып кычкырырга яраткан Ельцинның: «Сезгә никадәрле мөстәкыйльлек кирәк булса, шулкадәр алыгыз», – дигән юмакай сүзләренә алдандык. Аның урынына менгән икенчесе 2002 елда Бөтендөнья татар конгрессының корылтай делегатлары алдында «Тулысынча тиле хаким генә халыкларны туган телләрендә укытуны тыя ала», дип шәрран ярды да, 15 ел үтүгә нәкъ менә безне милли мәктәпләрсез калдыру турындагы фәрманга кул куйды. Ркаил Зәйдулла да, Англиянең йөзенә тимер битлек кидереп зинданга ташлаткан Ричардлары турында язган әдипләр дә хаклы – арт саннары тәхеткә тиюгә үк хакимнәрнең җаны алмашына һәм аларның берсе генә дә хакимиятне үз теләге белән ташлап китмәячәк. Алар тирәсенә акчага һәм властька табынган кемсәләр үләксә чукырга әзер козгыннар кебек җыелмыйча калмый. Менә шулары үзләренә җылырак оя, майлырак калҗа, абруйлырак кәнәфи дәгъва итә, хәтта өстәмә байлык талап кайту хакына хакимнән чит дәүләтләргә яу-талау походлары оештыруны да таләп итә башлый. Менә шул козгыннар көтүе эчендә үзләренең «зиһенлеләрдән-зиһенле» балаларын арттан этеп Айга мендерүчеләр саны ишәя. Ахыр чиктә, хакимнәр арасында да үзләренә ясалма игезәкләр әвәләп, үз хакимлеген сакларга омтылган җаннар табыла...

Тарих искә төшә. Россия тәхетенә үрмәләгән чакта Елизавета Петровна белән Әби патшабыз – Екатерина II фетнә куптарган гвардиячеләрнең иң беренче сафларында булган, битләрен итәкләре белән каплап, җир астында качып ятмаганнар. Совет галимнәре «народниклар» дигән битлек белән япкан террорчылар Александр Өченчегә каршы берсе артыннан берсе һөҗүм итеп торган, әмма патша читлек эченә яки бункер төбенә кереп яшеренмәгән. Николай Икенченең дә бронялар белән капланган вагоннарда гына күченеп йөрүе хакында һичбер чыганак юк. Чөнки болар асылда да үзләрен тарих һәм халык алдында җаваплы хакимнәр дип санагандыр, шуңа күрә ясалма битлек кигән игезәкләр артына да качып ятмагандыр, үз язмышларын үзләре хәл иткәндер. Ә аннары җәмгыять һәм хакимнәр вакланган, тавык чебиләре кебек бер-берсенә охшаш бак җанылар тәхетләрне тоткан. Бүген дә шул ук чир. Хәтта, әнә, кичә җансакчы булып яисә бассейннарда бергә йөзеп йөргән «ак тәнлеләр» дә саллы кәнәфи читенә арт саны эләгүгә үк үзен Ходай Тәгалә тарафыннан билгеләнгән түрә итеп саный. Ләкин шуларны кәнәфидә янәсы алыштыргач, кара гавам фейерверклар ясап күңел ача. Тормыш – балаган. Шушы битлек кигән түрәләр кулында курчак булып гомер итү әрәм. «Аллаһ вәзирләре, асабалар», имеш. Юк шул, Р.Зәйдулла тәхеткә мендергән Әхмәт Казанилар гына безгә бәхет юлап бирә алмас. Гадел җәмгыять төзү, бәхеткә юл яру – кара гавам кулында. Ә халыкның күзен ачуга ошбу әсәр дә барыбер ярап тора.

«Сөләйман» мәчете ачылды

Казанның Киров һәм Мәскәү районнары мөхтәсибәтендә өр-яңадан салынган иман йорты – «Сөләйман» мәчете ачылды. Ул – әлеге мөхтәсибәттә 13 нче мәчет.

«Сөләйман» мәчете 1999 елда төзелгән була. 2002 елда аның имамы итеп Илдар хәзрәт Баязитов билгеләнә. Бу бик истәлекле Аллаһ йорты була. Совет чорында Левченко бистәсендә имам булып Соруретдин Сөләйманов тора. Исеме үзгә булганга, халык аны Сөләйман мулла дип йөртә. Шуңа атап Левченкода 1997-1999 елларда төзелгән беренче мәчеткә «Сөләйман» исеме бирелә. Илдар Баязитов мәчет бинасының өске катын (мансарда) төзетә, анда тулай торак көйлиләр, мәчеткә манара да өстәп салына, уку класслары, ярдәмче тораклар барлыкка килә.

Хәйрия эшләре башлана, җәй көне мөселман балалары өчен даими рәвештә лагерьлар оештыралар. Алар арасында авырулары да хәтсез була. 2004 елдан бирле чукрак һәм начар ишетүчеләр белән эшлиләр.

2006 елда мәчеттә алып барылган тернәкләндерү, Коръән укырга өйрәнү курсларына күрмәүче яки начар күрүчеләрне дә җәлеп итәләр. Укыту бүлеге мөдире Мәликә Гыйльметдинова укырга өйрәтүнең үз методикасын һәм программасын булдыра. Әммә «Сөләйман» мәчетенең бинасы эшне тагын да җәелдерү өчен һаман да тар.

Барысы да очраклы хәлдән башлана. Казан мэры Илсур Метшин 2008 елның март аенда Левченко бистәсендә «Сөләйман» мәчетенә килеп чыга. Бирелә махсус курсларда уку өчен чират көткән сукырларны да күрә, изге эшләр өчен шартларның җитмәвенә, кысанлыкка да игътибар итә. Нәтиҗәдә 2013 елның июль ахырында барлык шартлар тудырылган «Ярдәм» мәчете ачыла һәм «Сөләйман» мәчетендә башланган кинкырлы социаль эшчәнлек «Ярдәм» мәчетендә дәвам иттерелә. «Сөләйман» мәчете командасы белән «Ярдәм» исемле мәчет үсеп чыга.

Әммә Левченкодагы «Сөләйман» мәчетен дә ташламыйлар. Иң зур теләкләре – заманча, хәйрия акцияләре үткәрү өчен уңайлыклары булган бина торгызу. Бу юлы да, үзләре әйткәнчә, Аллаһыбыз ярдәм итә. Илдар хәзрәт Баязитов танылган музыка белгече һәм композитор, озак вакытлар Казан консерваториясендә кафедра доценты булып эшләгән Разия Еникеева белән очраша.

Разия ханымның мәчетләр төзетүдә тәҗрибәсе дә бар. Аның ире, меценат Рөстәм Мөхәммәт-Мәсһүт улы Латыйпов исән вакытта мәчет төзергә хыялланып яшәгән була, әмма ул бу дөньядан иртәрәк китеп бара. Тормыш иптәшенең ниятен хатыны Разия ханым тормышка ашыра. Ул беренче мәчетне Яшел Үзән районының Түбән Вязовые бистәсендә төзетә. Ул чакта да мәсьәләне районның бу елларда хакимият башлыгы булган А.Тыгин белән очрашу хәл итә. Икенче Аллаһы йортын – 200 кеше сыярлык мәчетне Разия Еникеева үзенең шәхси җир кишәрлегендә – Хороводная урамында төзетә. Нәкъ менә шул микрорайонда мәчетләр җитми, үзәктәге мәчетләр исә җомга көннәрендә шыгрым тула.

Имам-мөхтәсиб Илдар хәзрәт Баязитов аңлатуынча, «Сөләйман» мәчетендә дә игелекле эшләр дәвам итә, биредә балалар өчен тәхфиз (Коръән ятлау) курслары оештырылачак. Анда берьюлы 36 бала укый алачак. Хәзерге вакытта балаларны туплау эше алып барыла.

Мәчет проекты авторы – архитектор Искәндәр Еникеев. Төзелеш эшләрен алып баруда инженер-төзүче Соруретдин Сөләймановның улы – Рәхимҗан Сөләйманов катнашкан. Ул мәчетнең иске бинасы материалларында әрәм итмәүләре, икенче бер Аллаһы йортын төзү өчен кулланулары турында сөйләде. Мәчет бистәне дә ямьләндереп тора. Аның өч ак гөмбәзе бар. Тышкы яктан да, эчтә дә ак төс өстенлек итә. Бинаның беренче катында 300 ир-ат берьюлы намаз укырлык зал, гардероб, тәһарәтханәләр урын алган. Икенче катта 80 хатын-кызга исәпләнгән намаз уку урыны, төрле кабинетлар бар. Мәчет уку сыйныфлары һәм ашханә белән җиһазландырылган, ике катлы ягында ислам мәдәнияте үзәге урнашкан.

«Сөләйман»ны ачу тантанасында бистә халкы, Россия төбәкләре һәм Татарстан мәчетләре имамнары, Казан мэры Илсур Метшин, Татарстан мөфтие Камил Самигуллин, баш казый Җәлил Фазлыев, Татарстан иҗтимагый палата җитәкчесе Зилә Вәлиева һ.б.катнашты.

Сөембикә КАШАПОВА.

Беренче очрашуда ук үлем

Пермь краенда 23 яшьлек егет социаль челтәрләрдә танышкан кызны беренче очрашуда ук вәхшиләрчә үтергән. Бу турыда полициягә сылтама белән «Вести» каналы хәбәр итте.

Соликамск шәһәрендә үтерү 9 ноябрьдә була. Пычак белән кискәләнгән кыз мәетен шәхси йорт ишегалдында табалар.

Әлеге йорт янынннан качып китеп баручы егетне видеокүзәтү камералары төшереп ала. Полиция ориентировка ясый һәм җинаятьтә шикләнелүче егетне биредә яшәүче бер хатын-кыз күрә. Суксун бистәсендә яшәүче 23 яшьлек егет моңа кадәр дә хөкем ителгән. Аны Соликамск шәһәрендәге бер кибеттә тоталар.

Тикшерү ачыкларганча, егет корбанын социаль челтәрләрдә таба, аннары кызга кунакка килә. Беренче очрашу план буенча барып чыкмый, егет белән кыз талаша, аннары егет кызга пычак белән ташлана.

Җинаять эше ачылган, диелә хәбәрдә.

1 нче биттә – Татар шагыйре Гадел Кутуйның 1925 елгы фотосы.

Шагыйрә бәйрәме

Үткән җомга кичендә республикабызның Милли китапханә залында үзе Башкортстанның Нуриман районында гомер итсә дә, ике күрше җөмһүрияттәге барча әдәбият сөючеләр өчен исеме һәм иҗаты күптән таныш булган шагыйрә, Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Һади Такташ исемендәге бүләк иясе Халисә Мөдәррисованың 70 яшьлеге уңаеннан бәйрәм кичәсе булып узды. Аңа күп сандагы фән һәм сәнгать эшлекләре, каләм осталары һәм Халисә ханым иҗатына мөкиббән тамашачылар җыйналды.

Гаять экерсез, мәгънәле һәм дулкынландыргыч булып узган кичәдә Татарстан Мәдәният министры урынбасары Ленар Хәкимҗанов, Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Казан шәһәре Башкарма комитетының җитәкче урынбасары Гүзәл Сәгыйтова, Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире Вахит Имамов, Язучылар берлеге рәисе урынбасары Илсөяр Ихсанова, Башкортстаннан килгән кунакларыбыз – М.Гафури исемендәге Академия театры директоры Ришат Фәйзуллин, Башкортстанның халык артистлары Илсөяр Газетдинова һәм Светлана Хәкимова, ике республика өчен дә кадерле әдибә Дилә Булгакова, Казанның театр көллиятендә укучы студентлар һәм мәктәп балалары чыгыш ясады. Х.Мөдәррисова сүзләренә язылган җырларны Татарстанның күренекле артистлары Зөһрә Сәхәбиева, Айгөл Бариева, «Фәридә-Алсу» дуэты, композитор Мөдәррис Газетдинов, шул ук М.Гафури театры артисткасы Светлана Хәкимова яңгыратты.

Татарстан укучылары Халисә ханым иҗатын берничә дистә еллар элек үк инде безнең «Казан утлары» һәм «Идел» журналларында, «Татарстан яшьләре» газетасында дөнья күргән шигырьләре аша белә иде. Ләкин ул әле бер үк вакытта күпләр сокланырлык драматург һәм проза остасы да икән. Аның «Бәхет хакы» исемле пьесасы инде 12 ел буе М.Гафури исемендәге театр сәхнәсеннән төшмичә уйнала. Халисә ханымның «Казан утлары» журналында быел гына басылган «Колхоз хикәяләре» циклы да меңәрләгән укучылар күңеленә хуш килгән. «Мәдәни җомга» газетасында шигырьләреннән тыш, Халисә ханымның бөек остазы Наҗар Нәҗми турында язган истәлекләре дә укучылар һәм галимнәр өчен бик кадерле булды. Кичә барышында да Гафури театры артистлары «Бәхет хакы» спектакленнән өзек уйнап алды.

Бәйрәм агышында бер сер дә ачылды – Халисә ханымның әби-бабалары, чыгышлары буенча, Актаныш районы туфрагыннан икән. 1735 елда ата-бабаларыбыз җирендә Оренбург крепостен төзүгә каршы купкан Акай явында катнашкан өчен татар крестьяннарын карательләр тарафыннан җәзага тарту башлангач, өстәвенә Агыйдел, Ык, Сөн елгалары буенда чәчүлек җир җитмәгәнгә күрә, Актаныш янәшәсендәге Җизмыек, Җияш, Шәбез, Аеш, Әлем, Исәнсеф һ.б. авыл гаиләләре, алдан килешү буенча, бүгенге Башкортстан мәйданына күчеп киткән. Араларында Халисә ханымның Җияш авылында яшәгән ерак бабасы да булган күчмәннәр Уфа аръягындагы Бүләкәй-Көзәй волосте җирләренә барып җиткән, аларны олыс старшинасы Әсәнов белән Мәсгуть Теләнчиев җитәкчелегендәге вотчинниклар каршы алган. Тиешле салым бәяләмәләрен түләгәннән соң килешү төзелгән һәм Актаныш крестьяннары бүген инде район үзәгенә әверелгән Кызылъяр, күршедәге Байкилде, Бикморза, Шиде авылларында яңа нигез корган. Һәр авыл крестьяннары аерым төпләнеп утырганга күрә, Кызылъярның бик күп урамнары тәүге елларында Җияш, Исәнсеф, Аеш, Әлем исемнәрен йөрткән. 1858 елда «Башкорт-мишәр гаскәре»ндәге җайдаклар санын киметү чаралары күрелә башлагач, «башкорт катламы» дәрәҗәсен һәм һәр ир-атка тиешле 40 ар дисәтинә чәчүлек җирны җуярга теләмичә, Актаныш, Мөслим, Әгерҗе, Сарман территориясеннән инде икенче, яңа төркем крестьяннар да килеп өстәлгән. Халисә ханым менә шушы барча тарихны җентекләп өйрәнгән дә үз нәселенең шәҗәрәсен төзегән. Сигез метр озынлыктагы затлы тукымага типография ысулы белән төшерелгән шәҗәрә 1500 гә якын кардәшләренең исемнәрен телгә алуы белән үк шаккатыргыч!..

Шагыйрәнең бәйрәм кичәсе дә нәкъ менә шулай шаккатыргыч, гыйбрәтле булып, күңелләрне җылытырлык дәрәҗәдә узды. Кичәне бик мөкәммәл итеп Илдар Кыямов һәм Резеда Сәлахова алып барды.

ТЕЛӘЧЕЛӘР БӘЙРӘМЕ

Казан шәһәренең «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә Теләче районының «Татарстанның мәдәни башкаласы» фестиваль-конкурсы кысаларында үткәргән мәдәният көне гөрләп, бәйрәм төсендә узды. Кунакларны фойедагы интерактив мәйданчыкларда төрле күргәзмәләр, осталык дәресләре, Олы Мишә авылының «Ядкәр», Субаштан «Нардуган» фольклор ансамбльләре, Теләченең «Мизгел» вокал ансамбле чын бәйрәмгә әверелдереп каршы алды.

Күргәзмәләрдә безне дә матур итеп өстәлләргә роза, кашкарый чәчәкләре кебек ясап, сәнгати бизәк итеп тәлинкәләргә тезелгән төрледән-төрле каклар үзенә тартып алды. Районның ашсу остасы Фаягөл Котдусова бәйрәм өстәлләренә какларны менә шулай бизәп әзерләгән. Фаягөл ханым рецептларын үзе уйлап чыгара. Инде как ясау белән шөгыльләнә башлаганына да җиде ел узган. Заказлары да күп, өенә килеп алалар. Быел хәтта Индонезиягә, Новокузнецкига җибәрергә алганнар. Хәзер Башкортстаннан бик күп заказ килгән. «Бәхетле» кибете дә Фаягөл ханым белән килешү төзегән. Ул Юныс Әхмәтҗанов исемендәге аш-су фестивалендә үз яшендәгеләр арасында беренче урынны алган.

Балалар иҗат үзәгендә өстәмә белем бирү педагогы Равилә Нәбиуллина нокталы бизәк төшерү белән шөгыльләнә икән. Аның шушы алым белән бизәкләгән нәфис тәлинкәләре, кечкенә куна такталары теләсә кайсы йортны, аш бүлмәсен ямьләндереп җибәрә. Аның шушы һөнәр белән шөгыльләнә башлавына 3 ел үткән, ул үз эшенең остасына әверелгән. Равилә хәзер тәлинкәләрне заказга да ясый башлаган. Ул әле паспорт тышлыкларын да бизи, келәм чигү белән шөгыльләнә. Төп эше исә – балалар иҗат үзәгендә. Ул һәркайсы 10-15 баладан торган биш төркемдә төрле кул эшләренә өйрәтү дәресләре үткәрә.

Балалар иҗат үзәге өстәмә белем бирү педагогы Фәния Галимҗанованың да күргәзмәгә куелган кул эшләренә хәйран калырлык. Ул чиккән мендәр тышлары, калфаклар, ашъяулыклар нәфис, матур. Фәния тегә, чигә, бәйли, буяулар белән такталарга бизәк төшерә, кулы чәчәкләр, халкыбызның бизәнү әйберләрен – муенсалар, алкалар ясау кебек эшкә дә ятып тора. Хәзер исә калфакларны бик яратып чигә. Ул аларны бисер белән дә, канитель белән дә бизәкли.

Мәдәният йортының икенче катына исә журналист һәм язучы, рәссам Дания Гайнетдинованың картиналар күргәзмәсе куелган иде. Кышкы урман да, су буенда утлап йөргән атлар, ярларында өянкеләр үсеп утырган тын аккан елга да дөньяның матурлыгы, аның кадерен белү турында искәртә.

Шунда ук Теләче Үзәкләштерелгән китапханәләр челтәре директоры Резидә Дәүлиева белән очрашабыз. Аларның гаять кызыклы эшчәнлек алып баруын күрсәткән күргәзмә үзенә тартып ала. «Бай мираслы Теләчем» дигән төбәк тарихын, җирле атамаларны, милли-гореф-гадәтләрне, йолаларны яктырткан әсәрләрдән тупланган китап, билгеле ки, зур кызыксыну уята. Ә менә «Тыңлагыз, әкият сөйлим» конкурсында балалар үзләре уйлап чыгарган әкиятләрен тәкъдим иткән. Алар китап итеп әзерләнгән. Алар әле иң мавыктыргыч әкиятләрдән мультфильм да эшләгән. Китапханәнең армиядә хезмәт итүче егетләр белән хатлар алышуы да 2021 елдан күркәм гадәткә әверелгән. Р.Дәүлиева җитәкчелегендә эшләп килүче «Йөзек кашы» әдәбият-сәнгать иҗат берләшмәсенә йөрүчеләрнең әсәрләре дә аерым китапларда урын алган. Шул ук вакытта үзәкләштерелгән китап йортында авыл һәм китапханәләр тарихлары өйрәнү дә алып барыла. Китапханәчеләр туплаган материаллардан «Теләче районы авыллары тарихы» дигән җыентык та дөнья күргән. Анда Теләче төбәгенең үткәне һәм бүгенге тормышы, иҗтимагый һәм мәдәни үсеше, сугыш һәм тыл ветераннары, гади хезмәт кешеләре хакында бәян ителә.

Бәйрәм тантанасы Теләченең авыл хуҗалыгында ирешкән уңышларны ассызыклаучы чыгышлар белән ачылды. Район җитәкчесе Нәҗип Хаҗипов республикада Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы игълан ителгәч, Теләчедә дә төрле милләт вәкилләренең тормыш-көнкүрешен, гореф-гадәтләрен барлау, өйрәнү һәм тарату өлкәсендә киң эш җәелдерелүен искәртте. Алар күргәзмәләрдә, осталык дәресләрендә, аралашу мәйданчыкларында чагылган. Теләче ягы Таһир Якупов, Нәфисә Васыйлова, академик Тәлгать Сиражетдинов, философия фәннәре докторы Яхъя Абдуллин, аш-су остасы Юныс Әхмәтҗанов, Г.Тукай исемендәге бүләк иялəре Фатих Хөсни һәм Мәхмүт Хәсәнов һ.б. күренекле шәхесләре белән данлыклы, аларны да туган төбәкләрендә һич тә онытмыйлар.

Концертта исә теләчеләрнең үзешчән сәнгатьтә дә сынатмауларын, осталыкларын күреп тагын бер сокландык.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотосы.

Палестина качаклары Калугада

Палестина территориясеннән эвакуацияләнгән Россия гражданнары Калуга өлкәсендә урнашачак, якын арада төбәккә якынча 130 кеше киләчәк. Бу хакта төбәк башлыгы Владислав Шапша хәбәр итте дип яза ТАСС.

«Палестина территориясеннән китәргә мәҗбүр булган Россия гражданнары Калуга өлкәсендә урнашачак. Качаклар белән эшләү штабы карары буенча, якын арада безгә якынча 130 кеше киләчәк», – дип язган ул Телеграм-каналында.

Шапша сүзләренчә, төбәк хакимияте кешеләрне урнаштыруда ярдәм күрсәтәчәк. Качакларны өлкә территориясендәге вакытлыча урнаштыру пунктларының берсенә урнаштырачаклар.

Качакларның күпчелеге – Палестина гарәпләренә кияүгә чыккан хатын-кызлар һәм аларның гаиләләре, балалары.

Каз йоны йолкыганда

Башкортстанның Тәтешле районындагы бер авылда элек бергә яшәгән, ләкин сентябрь аенда аерылган ир белән хатын әрәм булган.

«Башинформ» чыганагы буенча, 15 ноябрьдә 63 яшьлек ир-ат 53 яшьлек хатынын атып үтерә. Аннары ул ашыгыч хезмәтләргә шалтырата һәм үз-үзенә кул сала. Урынга килгән табиблар ир белән хатынның үлемен раслый. Фаҗига олы яшьтәге ир-атның көнчелеге аркасында килеп чыккан булуы ихтимал. Тикшерү эшләре дәвам итә.

Пенсионер ир-ат элеккеге хатынын каз йолкырга чакырган. Каз йолкыган чакта ир белән хатын талаша башлаган. Ир пистолет алган һәм хатынын атып үтергән. Үзе экстрен хезмәтләргә һәм дусларына шалтыратып барысын да сөйләгән, аннары үзенә кул салган.

Беренче «Караш» мәктәбе

Г.Кариев театрында Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе һәм Мәдәният министрлыгы ярдәме белән «Караш» инсценировка мәктәбе булып узды. Анда 17 егет һәм кыз драматургия серләренә төшенде. Куратор итеп күренекле драматург Анастасия Букреева чакырылган иде. Татар яшь тамашачы театрында репертуар кытлыгын хәл итүдән башланып киткән әлеге чара бер үк вакытта онытылып барган милли әдәбият җәүһәрләрен кабат әйләнешкә кертеп җибәрү максатын да күз уңында тотты. Катнашырга теләк белдергән яшьләргә язучыларыбызның йөзләп әсәре тәкъдим ителде, һәркайсы шуннан үзенә берәрсен сайлап ике-өч пәрдәлек инсценировка язып килергә тиеш иде. Уникe катнашучы бу эшне башкарып чыкты, калганнары исә баштан ук куркуга калды булса кирәк.

Татар китабы йортында үз инсценировкаларын тәкъдим иткән радио журналист Раил Садретдинов, К.Тинчурин театры актеры Илфак Хафизов, журналист Эльвира Фатыйхова, яңа гына мәктәпне тәмамлаган Ихтыяр Кыямов һәм экспертларның берсе Татарстан китап нәшриятендә балалар һәм яшүсмерләр өчен әсәрләрне укып әзерләүче Айсылу Галиева белән матбугат очрашуы булып узды. Театрның директоры Луиза Янсуар инсценировкага өйрәтергә тотынуларының тагын берничә сәбәбен әйтеп үтте. Шуларның берсе – татар классикасының онытылуы. Бу көннәрдә Кариев театрында Әмирхан Еникинең әсәрен сәхнәләштерәләр, бер үк вакытта программада глоссарий әзерләү турында да уйлыйлар, чөнки яшьләр гореф-гадәтләребезне онытып бара, диде директор. «Инсценировка ясаучылар бармак белән генә санарлык. Булганнары да режиссер, труппа белән килешеп эшләргә әзер түгел. Кайберәүләр әсәрләрен юләй да, куелмый, дип үпкәләп йөри. Драматург исә әсәрендә нәрсәнедер үзгәртергә дә әзер булырга тиеш, авторлык хокукларын да белеп торсын», дип чараның әһәмиятен ассызыклады Л.Янсуар.

Мәктәптә укырга теләк белдергән яшьләр быел биш номинация буенча «Алтын битлек» премиясен дәгъва кылган «Рөстәм маҗаралары» спектаклен карап автор һәм режиссер Айдар Әхмәдиев һәм Тимур Кулов белән очрашып сөйләшкән. Язучы Айгөл Әхмәтгалиева язь каләм тирбәтүчеләргә язу серләрен ачкан. Аның Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская турында әсәре буенча «Яратып туялмадым» спектаклендә дә булганнар. Л.Янсуар һәм Р.Гарипова бергәләп иҗат иткән «Сәйдәш. Йокысызлык»ны исә видеодан карап фикер алышканнар.

Катнашучылар арасында әле генә мәктәп тәмамлаган Ихтыяр Кыямов һәм Мәрьям Ибраһимованың булуы ана телебезнең киләчәгенә өмет уята. Шулай да журналист Эльвира Фатыхова катнашучыларның аз булуын билгеләп үтте. Бушлай укытудан файда алып калырга мөмкин иде, югыйсә. Хәер, «Караш» инсценировка мәктәбен ике елга бер тапкыр үткәрергә ниятләп торалар. Киләсенә өч кеше язылып та өлгергән инде. Раил Садретдиновның әйтүенә караганда, мәктәптә гомумән драматургиягә өйрәткәннәр. Инсценировка ясап кына калмыйча, киләчәктә үзегез дә яза алачаксыз, дигән фикер сеңдерергә тырышканнар. Анастасия Букрееваның драматург кына түгел, оста мөгаллимә булуы да катнашучыларның күңеленә бик хуш килгән.

Эксперт Айсылу Галиева исә «Караш» мәктәбенең хәзерге заман милли драматургия өлкәсендә торгынлыкны кузгатып җибәрүгә бер сәбәп булуына ышана. Юкса заманча сәхнә әсәрләребез бөтенләй юк, ди.

Матбугат очрашуында катнашучыларның барысы да бертавыштан Язучылар берлеге каршында да драматургия буенча осталык курслары оештырылсын иде, дигән теләкләрен җиткерде.

21 ноябрьдә Кариев сәхнәсендә «Караш-шоу» исеме белән инсценировкаларны презентацияләү чарасы узды.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

● Кеше туганда, аның баш миендә 14 миллиард күзәнәк була, һәм бу сан гомер буена бөтән артмый. Киресенчә, 25 яшьтән соң көненә 100 әр меңгә кими башлый. 40 яшьтән соң баш миенең деградациясе кисәк тизләнә, 50 дән соң исә нейроннар кибә һәм минең күләме кечерәя.

● Кайвакыт күбәләк, крокодилга куныл, аның тозлы күз яшен эчә, шул рәвешле үзендәге минераль элементлар кытлыгыннан котыла.

● Берләшкән Гарәп Әмирлекләре башкаласы Әбү-Дабида якындагы өч елда оча торган такси пәйда булачак. Американың Archer Aviation компаниясе җитештергән электр машиналарына берьюлы дүрт пассажир һәм пилот сыячак. Гади автомобиль 60-90 минутта үтә торган юлны аэротакси 10-20 минутта узачак, дип фаразлана.

Дастаннарда – тарихыбыз яши

Татарстан Фәннәр академиясендә өч көн дәвамында «Татар гыйлеме» Халыкара яшьләр фәнни мәктәбе булып узды. Ул быел «Дөнья рухи мәдәнияте контекстында эпик мирас» дигән темага үткәрелде. Фәнни мәктәп эшендә Казакъстан, Кыргызстан, Калмык республикалары, Мәскәү, Казан, Уфа, Стәрлетамак, Чаллы уку йортлары галимнәре, Татарстан Фәннәр академиясе, республиканың фәнни оешмалары һәм югары уку йортлары, гаммәви мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашты. Фәнни мәктәпне Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты үткәрде.

Яшьләр мәктәбендә катнашучыларны филология фәннәре докторы, ТР Фәннәр академиясенең вице-президенты Айнур Тимерханов сәламләде.

Академиядә яшьләр белән эшләүгә аерым әһәмият бирелә, аларның фәнне үстерүенә грантлар белән ярдәм итәләр. Узган ел гына да филологик фәннәр буенча диссертацион совет базасында 10лап докторлык диссертациясе якланган.

Фәнни мәктәпнең төп темасына килгәндә исә, татар халкында дастаннар киң таралган. Алар башта телдән-телгә күчкән, аннары аларны кулдан күчереп язма хәлдә таратканнар, моңлы озын кичләрдә дастаннарны көйләп укый торган булганнар. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре Лилия Мөхәммәтҗанова халкыбызның X гасырларда, ягъни Идел Болгарстаны чорларында ук, гарәп имлясында укый-яза белүе турында искә алып үтте. Гомумән, Идел Болгарстаны югары үсеш алган шәһәрләре, мәктәп-мәдрәсәләре, фәннәр алгарышы, алга киткән сәүдә эшләре белән аерылып торган. Анда шулай ук әдәбият та югары дәрәҗәдә үскән, шул исәптән Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы да иҗат ителгән. Урта Идел буе төбәкләрендә яшәүче татарларның язма мәдәнияте Алтын Урда чорында да танылган әдипләре, поэма-дастаннары белән яңа баскычка күтәрелгән. Казан яулап алынгач, беркадәр торгынлыктан соң, татарларның эпик традициясе кабат яңарган һәм үсеш алган. Татарларда язма иҗатка һәм әдәби мираска аерым ихтыяҗ булган һәм аңа гаять зур ихтирам тәрбияләнгән. Ә бу үз чиратында телдән сөйләнә торган иҗатка кызыксынуны киметкән. Бигрәк тә Урта Идел буе һәм Урал яны татарларында китаби эпос-дастаннарның үсеш алуы шуның белән аңлатыла. Һәм халкыбыз арасында бүген дә кайбер киң таралган эпос-дастаннарның фабулаларын сөйләп йөрүчеләр дә очрый. Лилия Мөхәммәтҗанова билгеләп үткәнчә, татар дастаннары күренекле галим Фатих Урманчеев исеме белән бәйле. Ул Казан фольклор мәктәбе кысаларында милли эпик мирасны киң һәм зур күләмдә өйрәнүдә әһәмиятле өлеш керткән. Аның җитәкчелегендә халыкның эпик мирасын системага салып өйрәнү башлана.

Әмма филология фәннәре докторы, Г.Ибраһимов исемендәге институт директоры Ким Миңнуллин дөнья халыклары эпик мирасының күп гасырлык тарихына карамастан, ул әле дә аз өйрәнелгән мәдәният феномены булып калуын билгеләрдә. Бу хакта Санкт-Петербург университетында узган Лихачев укуларында, соңгы культурология конгрессында, Бишкекта үткән дөнья халыклары эпосын өйрәнүгә багышланган фестивальдә әйтеп үтелгән. «Эпосны Җир цивилизациясе хәзинәсе дип атыйлар, чөнки ул – көнкүреш, тел һәм мәдәният үзенчәлекләрен иң бай һәм төгәл чагылдыручы тарихи чыганак», – диде галим. Ул шулай ук «Татар гыйлеме» Халыкара яшьләр фәнни мәктәбендә әйдәп баручы галимнәрнең Россия фәнни оешмалары һәм югары уку йортлары арасында элементләрне ныгытырга да ярдәм итәчәгенә дә ышаныч белдерде.

● Розалия Солтангәрәева.

Дастаннар арасында «Идегәй» иң киң таралганыдыр, мөгаен. Ш.Мәрҗәни исемендәге тарих институтының тикшеренүләр үзәге җитәкчесе Илнур Миргалиев «Идегәй»гә дастан итеп кенә карарга ярамавы турында искәртте. Анда халык хәтерендә сакланган тарихи вакыйгалар ята. «Әлбәттә, бу жанрда сәяси хроникалар язылмый, бу елъязма түгел, шулай да халык, дастанда булган вакыйгаларны, шәхесләр, аларның хезмәтләрен, хәл ителәсе мәсьәләләр, кешеләр арасында үзара килеп туган катлаулыклар, шулай ук сәяси проблемалар турында үз теле белән бәя биреп ачыкларга тырыша».

«Идегәй»дә бәян ителгән вакыйгалар Алтын Урданың таралу чорына бәйле. Ул вакытта Туктамыш хан, илне берләштереп, яңадан куәтләндергән. Бәлки, шулай дәвам иткән булыр иде, алда әчке мәсьәләләр килеп чыккан. Алар «Идегәй» дастанында бәяләнә. Дастан тагын Аксак Тимер темасын да күтәреп чыга. Идегәйнең дошманы туган Ватанына алып килүе, шәхси мәнфәгатен алга куеп илне җимертүе...

● Евдокия Хабунова.

«Дастан ул чорны трагедия итеп ача алган. Бер кешене генә каралтып калдырмаган, ә бәлки килеп туган хәлне фаҗига итеп күрсәткән. Бүгенге көндә фән дөньясы да дастандагы вакыйгаларның, шәхесләрнең чынбарлыкка туры килүен раслый, – дип ачыклап үтте И.Миргалиев. – «Идегәй» ул төзелгән дастан, димәк ки аның төп чыганаклары тарихны барлый. Фән моны фольклор дип кенә карамыйча, кулланырга, халкыбызга кайтарырга тиеш. Чөнки ул да халкыбызның бер тарихи чыганагы».

● Илнур Миргалиев.

Тел әдәбият һәм сәнгать институтының баш хезмәткәре Илсөяр Закирова институтта дастаннарны төрле яклап өйрәнү дәвам итүен белдерде. Алар фәнни мәкаләләрдә, монографияләрдә чагыла. Быел Лилия Мөхәммәтҗанованың «Эпическая культура татар: Дастаны» дигән яңа китабы дөнья күргән. Анда галимә дастаннарны эпик мәдәниятебезнең бер чагылышы буларак тәкъдим итә.

Филология фәннәре кандидаты, Тел әдәбият һәм сәнгать институтының бүлек җитәкчесе Илмир Ямалтдинов искәртеп үткәнчә, «Татар халык иҗаты» 25-томлыгының ике китабы дастаннарга багышланган. Аларның берсе 9 нчы томда басылып чыкты. 10 нчы том китабы дастаннарга багышланачак. Бу томнарның төзүчесе – филология фәннәре докторы Илсөяр Закирова. Басылып чыккан томлыкта героик, тарихи һәм мәхәббәт дастаннары урын алган. Анда 50дән артык дастан дөнья күргән. «Томлыкта Флора Әхмәтова тарафыннан чыгарылганнары да, архивта сакланганнары да кулланылды. Беренче тапкыр дөнья күргәннәре дә бар. Әлеге дастаннарның бер өлеше немец галиме академик Вильгельм Радловның Себердә яшәүче татарлардан язып алынса, икенче өлеше 1939 елдан башлап ТӘҺСИ фольклорчыларның татарлар яши торган төрле төбәкләрдә яшәүчеләрдән тупланган. Кайберләре берничә вариантта бирелә», – ди И.Закирова. Китапта дастаннарның әлегә фәнни әйләнешкә кермәгән вариантлары да күрергә мөмкин. 2022 елда И.Закированың музыка белгече Илгиз Кадыров белән бергә эшләгән «Татар халкының музыкаль-эпик иҗаты» дигән китабы та чыккан. Анда дастаннар, бәетләр, мөнәҗәтләр ноталары белән бирелгән. Авторлар яңа китап әзерләү белән мәшгуль.Ул җыентыкта дастаннар ноталары һәм назымнары белән бирелачәк. Назым – ул дастан эчендәге җыр. Ул музыка уен коралларына кушылып, көйләп башкарылган. Татарларда ятаган дигән музыка коралы да булган.

● Лилия Мөхәммәтҗанова.

Фәнни мәктәптә филология фәннәре докторы, М.Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогика университеты фәнни тикшеренү үзәге җитәкчесе Розалия Солтангәрәева, филология фәннәре кандидаты, Кыргызстан-Россия Славян университетының әдәбият тарихы һәм теориясе кафедрасы доценты Әминә Галимова, филология фәннәре докторы, Б.Городовиков исемендәге Калмык дәүләт университетының халыкара фәнни үзәге директоры Евдокия Хабунова чыгышлары да кызыксыну белән тыңланды.

Бишенче тапкыр оештырылган һәм лекцияләр, семинарлар, «түгәрәк өстәл» утырышлары, күргәзмәләр һ.б. үз эченә алган фәнни мәктәп Россия төбәкләренең фәнни һәм мәгариф оешмалары магистрантларын – яшь галимнәрне тагын да берләштерде. Фәнни мәктәптән алган рухлану алга таба да яшь галимнәр белән эшләүгә этәргеч бирер һәм аларда яңа идеяләр, инновацион проектлар барлыкка килүгә сәбәп булыр.

Сөембикә КАШАПОВА.

Автор фотолары.

КАҺАРМАН ӘДИП

(Язучы Гадел Кутуйның тууына 120 ел)

Миңа ул вакытта 10-12 яшьләр булгандыр. Күршедәге дустым Фәргәп Мөхәммәтҗановларга кергәч, ул миңа калын гына китап күрсәтте. Анда авылдашым, кыю танкист, гвардия капитаны Бәдыйги абый Хисамов турында язылган иде.

Күренекле татар язучысы Гадел Кутуй Бәдыйги абый белән дүрт тапкыр очраша. Аның сугышчан батырлыгы турында фронт газеталарында яза. Ә язучының «Тетрә, Берлин!» дигән очеркында якташыбыз турында мондый юллар бар: “Менә батыр танкист – гвардия өлкән лейтенанты Бәдыйги Хисамов. Командирлар аның турында:

– Кыю, хәйләкәр егет, – диләр. Мусатовлар, Сухаревлар һәм Хисамовлар белән бергә мәшһүр җырчы Җамбулның оныгы – атаклы танкист Кубис Җумабеков та Берлинга бара. Аның экипажында дүрт милләт вәкиле бар. Бу – очраклы хәл түгел. Ерткыч гитлерчылар оясын туздырырга СССР халыкларының мәңге какшамас дуслыгы бара!”

Бу турыда минем язып чыккалаганым да булды. Инде менә Фәргәп дустым белән очрашуга 54-55 еллар үткәннән соң, мин китапханәгә барып, язучы Гадел Кутуйның сайланма әсәрләр китабыннан «Тетрә, Берлин!» дигән очеркны эзләп таптым. Үзем дә белмичә, күпне күргән, сугыш михнәтләреннән, авырулардан 42 яшендә вафат булган Гадел Кутуй дөньясына кереп чумдым. Авылдашым Бәдыйги абый кебек, бу олы әдип тә миңа бик якын булып китте. Шушы елда язучы Гадел Кутуйның (Гаделша Нурмөхәммәт улы) тууына 120 ел тула икән. Ул 1903 елның 28 ноябрендә Саратов губернасындагы Татар Кынадысы авылында туган. Башлангыч белемне шунда алган.

Һәрбер язучының таланты ачылып китүгә сәбәпче хәлләр була. Гадел Кутуй тормышында да бар алар. Аның әнисе Динә апа шигъри җанлы хатын булган. Бәетләр, җырлар чыгарган. Булачак язучы аларны тыңлап үскән. Аннары мәктәпләр: Татар Кынадысында туган телне, әдәбиятне өйрәнү, 1912 елда әти-әниләре белән Алексеевск авылына күчкәч, андагы рус мәктәбендә Пушкин, Лермонтов иҗатлары белән танышу. 1917 елда гаиләләре Самарага күчкәч, ул әдәби атмосфераның эченә үк килеп керә. Әдәбиятка омтылыш яшь егетне Казанга алып килә. Казанда Гадел Кутуйның беренче шигыре 1923 елда басылып чыга.

Моннан йөз еллар элекке чор, үткән гасырның егерменче еллары, бүгенге кебек үк үзгәрешләр, элеккедән ваз кичү, яңа кыйммәтләр, яңа мөнәсәбәтләр тудыру заманы булган. Яңа чор, яңа омтылышлар. Шул омтылышлар белән канатланган яшьләр Россиянең төрле почмакларыннан Казанга агылган. Алар арасында кабатланмас талант иясе, кулдан төшми укыла торган әсәрләр авторы Гадел Кутуй да булган. Аның яшәешенә һәм иҗатына да замана тудырган шартлар йогынты ясап торган. Җәбер-кимсетүләр, ахыр чиктә үзен һәлакәткә китергән фаҗигалар кичерүенә карамастан, язучы дистәләрчә телләрдә, йөзләрчә басмаларда таралган «Тапшырылмаган хатлар» повестен, Бөек Ватан сугышының коточкыч дәһшәтле юлларын үтеп җиңү яулаган совет сугышчысының хисләрен йөрәкләрне тетрәндерерлек итеп тасвирлаучы «Сагыну» нәсерен язган. Галимҗан Нигъмәти Гадел Кутуйны татар шигърияте күгендәге биш йолдызның берсе, дип атаган.

Мещанлыкны, эшләмичә генә «матур» яшәргә теләүчеләрне фаш итүе белән әдипнең әсәрләре бүген дә актуаль булып кала. Тик бүгенгеләргә алдашу, ялкаулык, оятсызлык өстенә чиктән тыш шәфкатьсезлек һәм комсызлык та өстәлгән.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк Гадел Кутуй сугышка омтылса да, анда китү 1942 елның июнендә генә насыйп була. Фронтка киткәндә дә Кутуй язучы һәм журналист каләмен үзеннән калдырмый. 1944 елның көзенә кадәр хәрәкәттәге армиядә хезмәт итсә дә, аның шигырьләре, хикәяләре, хәбәрләре, мәкаләләре тылдагы һәм хәрби газеталарда чыга, бөтенсоюз радиосыннан да яңгырый.

Әдип сугышка гади солдат булып китә. Фронтның кырыс чынбарлыгы таләп иткән һәр тапшырылган эшне, һәр боерыкны намус белән үти. Гадел Кутуй сугышта бервакытта да тәвәккәллек-кыюлыгын җуймый, үзенең түземлеге, күңел хөрлеге белән башкаларга үрнәк була. Ул һәр сугышчан йөкләмәне нәкъ үзвакытында үти.

Ул, тәрбияче-оештыручы буларак, үзен сәләтле итеп күрсәтә һәм дивизия парторгы итеп сайлана. Ул фронтта үзен иҗат кешесе буларак таныта. Хатыны Галимәне, балаларын, гаиләсен, туганнарын, дусларын бик сагына, алар белән очрашу турында хыяллана.

1944 елның көзендә «Кызыл Армия» газетасына эшкә күчә, анда әйдәп баручы журналистка әверелә. Фронттан ике-өч айга ялга кайткан арада да «Рөстәм маҗаралары» дигән повесть иҗат итеп өлгерә.



● Бәдыйги Хисамов.

Бәдыйги абый Хисамов турындагы «Тетрә, Берлин!» дигән очеркны Гадел Кутуй 1945 елда Германиядә яза һәм ул шул елның 23 февралендә «Кызыл Татарстан» (хәзерге вакытта «Ватаным Татарстан») газетасында басылып та чыга.

Шулай булгач, Гадел Кутуй үзе кебек батыр сугышчы Бәдыйги абыйны һәм аларның танк экипажын бик яраткан, юкка гына алар белән дүрт тапкыр очрашмаган, озын-озак газаплы да, данлыклы да сугыш юллары үтмәгән инде.

«Без яшен тизлеге белән барабыз. Безнең кайбер подразделениеләребез бер тәүлек эчендә йөз илле километр юл уза. Безне туктатырлык көч-куәт юк. Без Шверземга бәреп керәбез. Позначь шәһәренә якынлаштык. Идел еракта калды инде. Висла, Нарта сулары да кичелде. Без Одер елгасына килеп җиттек.

Мәскәү, Ленинград шәһәрләрен тупка тоткан немецларны хәтерләп, Берлинга килеп җиттек без. Ул хәрабәләрне истә тотып:

– Тетрә, Берлин! – дибез», – дип яза Гадел Кутуй, горурланып!

Әмма Туган илгә кайту, җиңү тантанасын туганнары, дуслары белән бәйрәм итү Гадел Кутуйга насыйп булмый. Аның һәлакәтенә ул вакыттагы тума билгеләреннән булган нәрсәләр – һәркемнән шикләнү, иң тугрылыклы, иң намуслы кешеләргә ышанмау сәбәп булды дисәк тә, хата булмас. 1944 елда фронттан вакытлы ялга кайткан чагында, аны Татарстанның мәдәният министры итеп кую фикере туа. Хәтта өлкә комитетына аны министр итеп раслауга да чакыралар. Алгы бүлмәдә көтеп утырган Кутуй КГБ кешесенең «ул бит җидегәнче» дигән сүзен ишетә. Әлбәттә, шул сүздән соң аны расламыйлар һәм Кутуй гаять төшенке күңел белән фронтка китә. Моңарчы гел алгы сызыкта булырга тырышкан Кутуй, кара сакал миннән калмый икән инде, дип, үзен бөтенләй сакламый башлый. Юка шинельдән килеш каты салкыннарда танк өстендә көненә бик күп километр юллар үтеп, бик нык салкын тидерә һәм бетмәс-төкәнмәс авырулар белән газаплана башлый, ниһаять, госпитальгә эләгә, шунда инде сугыш беткәч, 1945 елның 15 июнендә Польшаның Згеш шәһәрендә 42 яшендә күкрәк авыруыннан вафат була. Каты авыру хәлендә дә ул, Берлинга һөҗүм башлангач, госпитальдән качып чыгып, шул соңгы сугышларда катнашырга теләп, редакциягә кайта. Ләкин инде көч юк, дәрман калмаган. Иптәшләре аны кире госпитальгә илтә.

Гадел Кутуй хәзер дә әдәбият сөючеләр күңелендә. Аның иҗаты бик бай, кызыклы һәм үзенчәлекле. Ул безгә һәрвакыт туган илне, кешеләрне, тормышны яратыгыз, яшәүнең кадерен белегез дип, әйтеп тора сыман!

Зөлфәт ХӘЙРУЛЛИН.
Автор сурәтләре.



Ренат ХАРИС

Өйдә тыныч... Тышта да офыклар ачык күренә... Җан тыныч... Ә дөнья болганчык – иртәгәсе көннәр билгесез-лек томаны артында... Радио-телевидение томанны ку-ерткалап та җибәрә. Җанга борчулы җилләр кагыла. То-ман артындагы чынбарлыкны күрәсе килә. Акыл шунда омтыла. Күрәзәчегә әверелә башлавыңны сизми дә кала-сың! Ә күрәзәчелектән пәйгамбәрлеккә ерак түгел, әмма ул араны кешелек тарихында үтүчеләр, би-и-и-ик аз булса да, булган. Алар – пәйгамбәрләр!..

Дөнья әдәбиятында пәйгамбәрләргә багышланган әсәр-ләр байтак. Ә шагыйрьләр нигә пәйгамбәрләр турында шигырь-поэмалар яза? Әнә Йосыф пәйгамбәр турында дөнья сәнгатендә 400дән артык роман, повесть, хикәя, сәнгать әсәре бар, диләр. Төрки әдәбиятларда бу теманы безнең Кол Галинең «Кыйсса-и Йосыф»ы башлап җибәр-гән. Сигезгә якын гасырдан соң мин дә «Йосыф кыйсса-сы» дигән балет либреттосы яздым... Пәйгамбәрләрнең язмышлары катлаулы, авыр һәм гыйбрәтле, аларның төп сыйфаты – бернидән дә курыкмыйча хакыйкать хакында турысын әйтү! Шагыйрьләр аларның әнә шул сыйфатына соклана. Ә турысын әйткән туганына да ярамаган, диләр. Шуны белә торып, һәр шагыйрь, күңеленнән, пәйгамбәр булырга хыяллана һәм моны яшерми дә... Кайбер ша-гыйрьләр үзләренең миссияләрен турыдан-туры пәйгам-бәрләрдән алган авыр, катлаулы, җаваплы, хәтта хәтәр эстафета, изге бурыч итеп саный.

Уйга чумып утырган бер болганчык мизгелдә туры Ту-кайның «Пәйгамбәр» дигән шигыре искә төште. Алып укыдым. Тукай аны 23 яшендә язган. Әлбәттә, ул – Лер-монтовның «С тех пор как вечный судия мне дал всеве-денье пророка...» шигыренең аңлатмалы, киңәйтелгән тәрҗемәсе!.. Минем бу шигырьнең төгәлрәк тәрҗемәсен күрәсем килде. Салих Батталның 60-70 еллар элегрәк эшләгән тәрҗемәсе дә канәгатьләндермәде. Лермонтов хәтеремә Пушкинның мәктәптә ятланган «Пророк» ши-гырен кайтарды. Аларны татар телендә яңгыратып ка-рыйсым килде. Эш барышында, кызып китеп, мин күңе-лемдә йөргән тагын берничә шагыйрьнең пәйгамбәрләргә багышланган шигырьләрен тәрҗемә иттем... Һәм үзем дә «Пәйгамбәр» дигән шигырь язарга баздым. Шуларны, ка-дерле укучылар, сезгә тәкъдим итәм.

Ренат ХАРИС.

Төркем-төркем килде безгә пәйгамбәрләр...

Гомәр ХӘЙЯМ

ПӘЙГАМБӘРЛӘР

Төркем-төркем килде безгә пәйгамбәрләр,
Дөньябызга якты вәгъдә итте алар.
Әмма йомдырылган килеш үз күзләре
Бер-бер артлы караңгыга китте алар.

Иоһан ГӨТЕ

ПӘЙГАМБӘР ӘЙТӘ

Пәйгамбәрен саклаганга күрә
Аллаһыга тотса ачу-үчен,
Гареш катламына, курыкмыйча,
Аркан ассын кемсә үзе өчен.
Мәңгелекнең төпсез упкынында
Ул беравык чайкалып та торса,
Ярсулары аның шул мизгелдә
Юкка чыгар – Аллаһы боерса!

Александр ПУШКИН

ПӘЙГАМБӘР

Җан сусавыннан интегеп,
Мин чүлдә сөйрәлә идем,
Алты канатлы серафим
Юл чатында миңа инде.
Төш кебек җиңел куллары
Күзләремә кагылдылар,
Сискәнгән бөркет күзедәй
Күзләр кинәт ачылдылар.
Ул колакларга кагылды, –
Аларга тавышлар тулды:
Күк гөмбәзе шаңгыравы,
Фәрештә канаты шавы,
Су хәшәрәте йөзеше,
Йөземнәрнең калтыравы.
Ул кагылды авызыма,
Йолкып ташлады гөнаһлы,
Вәсвәсә тулы телемне,
Гакыйль елан теле-угын,
Канга баткан кулын тыгып,
Авызыма урнаштырды.
Хәнҗәр белән түшне ярып,
Йөрәкне алды каерып,
Шунда утлы күмер кертте,
Йөрәк урнына беркетте.
Мәет булып яттым чүлдә.
Шунда Аллаһ сүзе килде:
«И, пәйгамбәр, калык, ишет,
үтә кодрәтем теләген:
җир, диңгез гиз, сүзең белән
яндыр кешеләр йөрәген».

1828

Михаил ЛЕРМОНТОВ

ПӘЙГАМБӘР

Күземә мәңгелек казый
Күрәзә биргәннән бирле
Мин кеше күзеннән ачу,
Һәм бозыклык укып йөрим.

Мәхәббәтне, дөреслекне
Саф гыйлем дип игълан иттем.
Якыннарым, шашып, миңа
Таш өере атып китте!

Көл сибеп башыма, качтым
Шаулы шәһәрдән, югалдым.
Чүлдә яшим, кошлар сыман,
Аллаһ җименә юанып.

Бакый васыятьне үтәп,
Җирнең барлык җанварлары
Буйсынды миңа. Йолдызлар
Тыңлый уйнатып нурларын.

Ашыгып, шаулы шәһәрләр
Аша үтеп барган саен
Картлар балаларга сөйли
Тәкәбберләрчә елмаеп:

«Күрегез, сезгә гыйбрәт бу!
Ул бик горур булды, тиле.
Имеш, Алла сүзен безгә
Җиткерә тик аның теле!

Күрегезче, нинди боек
Һәм ялангач, нинди арык,
Күрегезче, бөтен кеше
Аңарга җирәнеп карый!»

1841

Алексей ТОЛСТОЙ

* * *

Көрәшкә дип җыйнаганда, Ходай,
Күкрәгемә изге кул белән
Мәхәббәт һәм ачу урнаштырды
Һәм йөр, диде, туры юл белән;
Мәгърур сүзе белән рухландырды,
Зур көч-куәт бирде йөрәккә,
Әмма Ходай бирмәде кырыслык,
Ныклы ихтыярын – бигрәк тә.
Ачуымны мин туздырдым бушка,
Мәхәббәтемнән дә гарык мин.
Бер-бер артлы килгән һөҗүмнәрне
Кире кага-кага арыдым,
Дошман давылларына каршы мин
Көбә кими генә чыкканмын,
Һәлак булам шулай юктан мин.

1857

Александр БЛОК

ПӘЙГАМБӘР

Пәйгамбәр – иҗатның таҗы,
Күкләр күкрәү, яшен ише,
Күрәзәләрен киләсе
Чорга җиткерәсе кеше.
Кырыс Англия иленең
Соңгы буын төркемнәре
Белеп калырга дучардыр
Карт даһиның белгәннәрен.
Без – аларның балкышыннан
калган тонык таплар гына
һәм кирәкмәгән ватыклар
Җирнең яхшы чакларыннан.

1900

Николай ГУМИЛЁВ

ПӘЙГАМБӘРЛӘР

Алтарьларыбыз ауса да,
Пәйгамбәрләрне күрәм.
Киләчәк таңнары кебек
Күзләре якты, тирән.

Аларга ят җиңү чаңы,
Хаким сүзләре изә.
Таш йортлар кысанлыгына,
Төсләре китеп, түзә.

Без танымаган пәйгамбәр
Кайчак, батып сагышка,
Зәңгәр күз карашы белән
Нурлы күккә ябыша.

– Минем җаным изге, – ди ул, –
Исәр булсам да үзем,
Сагышлы уйларда күрдем
Гайсаның нурлы йөзен.

Алланың хыялы төрле,
Юмарт Аның куллары...
Шундый пәйгамбәрләр дә бар –
Изгелек рыцарьлары.

Дөнья куркыныч түгел, ди,
Туачак Таң кенәзе...
Кара манара рухлары
Тыңлыйлар көлемсерәп.

1905

Ренат ХАРИС

ПӘЙГАМБӘР

Лермонтов һәм Пушкин заманында
пәйгамбәрләр салган авыр эздән
бәһаләргә килдем чорыгызны...
Миндә – Тарих биргән сизгер бизмән.

Айлар, еллар йөрим арагызда,
үлчи алмыйм ләкин берни дә мин...
Танымаслык булган шәһәр, авыл,
сизелерлек булган һава тәме.

Бозык һава һәм болганчык мохит
адаштырган сезнең аңыгызны –
Гөнаһ, Савап урын алмашканнар,
сез аларны хәтта танымыйсыз...

Адәм белән Хава балалары
үзләренә яңа җенес эзли!
Содом белән Гоморра хәленә
калгансыз бит! Шуны сизмисезме?

Кыйтгаларга кыйтга йодрык селки,
сирәк, сәлам биреп, кул изәүләр...
Җир шарының меридианнарын
җыенасыз кебек өзгәләргә....

Тышкы ягы Җирнең эчке ягын,
күз дә йоммый, әзер юк итәргә!..
Аңлап булмый бөек ахмаклыкны –
кемнәр тели моны, ни этәрә?!.

Аллаһтан да өстен булмакчы сез –
пәйгамбәрләр сүзен ишетмисез.
Җәфалыйсыз кешелек анасын,
җимерәсез изге бишекне сез.

Пәйгамбәрлек итеп булмый монда,
кирәкми дә сезгә пәйгамбәрләр –
сез кыйнарсыз мине, «Ахырзаман
борын төбегездә!» дисәм әгәр.

Кыйнамыйсыз!.. Чөнки ышанмыйсыз...
Талашасыз күз йомып сез, кызып,
язмыш безне, бәлки, аяр диеп...
Алдыгызда инде соңгы сызык...

Атлыйм диеп аяк күтәргәнсез –
кая басасыгыз билгелеме?
Сезгә әйтәм: атлап үтәлмәссез
«бәлки»ләрнең хәтәр тилелеген...

Мыштым гына йөрим арагызда,
шакый-шакый акыл ишекләрен –
ярык кына булып ачылалар...
«Хуш киләсең!» сүзе ишетмәдем...

2023

Мәдәни җомга
24 ноябрь
№46, 2023

Михаил Худяков

(Дәвамы. Башы 45 нче санда).

Димәк, елъязмачылар үзләренә таныш булмаган Кашан атамасын Казан сүзе белән алмаштырган». (Шпилевский, с.185). Воскресение елъязмасында чыннан да Кашан атамасын Казан сүзе белән алмаштыру очрагы бар. Новгород һәм Устюг яугирләренең 1391 елдагы һөҗүме Казанга түгел, ә нәкъ менә Кашанга юнәлтелгән була. (ПСРЛ VIII, с.16; Шпилевский, с.176). Шуңа да урыс чыганакларының 1376, 1382 һәм 1398-1399 елларга бәйле рәвештә Казанны телгә алуларын асыл хакыйкать буларак кабул итеп булмый, «Бәяни Дастан әт-Тарих» һәм «Дастане Аксак Тимер» кебек татар чыганаклары Казанга нигез салынуны 1401-1402 елларга нисбәтли. «Казан» сүзенең ни аңлатканын һәр татар белә. Иң әүвәл бу атаманы калага биргәннәрме, әллә елгагамы (Казан суы) – хәзер әйтүе кыен. Урнашкан урынны казан рәвешенә охшатып, калага да шул атаманы бирүләре бик ихтимал. Ләкин Казанның төүге урынын ачыкламыйча болай дип тә раслап булмый. Татар риваятьләренә караганда, Иске Казан хәзерге каладан 45 чакрымераклыкта урнашкан булган.

Казанга нигез салу җәһәтеннән татарлар арасында да, урыслар арасында да күп санлы риваятьләр бар. Аларның һәммәсен, безнең фикеребезгә, өчкә бүләргә мөмкин: 1) «Казан» сүзенә аңлатма бирергә омтылган легендалар, 2) шәһәрне күчерү хакындагы һәм елан турындагы легендалар, 3) кирмән салу хакында легендалар. Бу риваятьләрнең берсе дә тарихи яктан әһәмиятле түгел. Алар халык иҗаты һәм фольклор җәһәтеннән генә кызыклы һәм халык авыз иҗатындагы күчмә сюжетларны өйрәнү ягыннан гына игътибарга лаек. Казан атамасын аңлаткан «казан» турындагы легенда беренче тапкыр Георги тарафыннан 1774 елда язып алынган; шәһәрне салганда, дип яза ул, бәкнең бер хезмәтчесе елгадан су алганда үзенең казанын төшереп җибәргән, шуңа шәһәр дә, елга да Казан дип аталган. Елан турындагы легендалар игътибарга лаеграк: аларда хәзерге Казан урынында еланнарның күп булганлыгы хакында сөйләнә, ә бер елан, имеш, канатлы булган һәм шәһәр тирәсендәге Елан тавында (Җылан Тау) яшәгән (хәзерге Зилант монастыре урнашкан Зилант тавы); шәһәр салучылар салам яндырып еланнарны үтереп бетерә, ә канатлы елан (аждаһа) Елан тавыннан очып киткән һәм бер риваятьтә Кабан күлендә, икенчесендә Черек күлдә батып үлгән. Канатлы һәм куркыныч еланнар турында легендалар Казан иленең бүтән төбәкләрендә дә сөйләнә: 1) Зәй тамагында болгарларның бер каласы булган, ләкин «Бараш исемле аждаһа бу шәһәрнең кешеләрен җәберли икән, түзәр хәлләре калмагач шәһәр кешеләре торган урыннарын ташлап бүтән җирдә яңа шәһәр корган һәм аңа Буләр дип исем кушкан» («Дастане Аксак Тимер» – Шпилевский, с.57). 2) Рождественский-Ямаш авылы янындагы Елан чишмәсенә нисбәтле, «анда тау куышында канатлы зур елан яшәгән, ул тирә-яктагы хайван, җәнлекләрне генә түгел, кешеләрне дә ашаган, түзәр хәлләре калмагач тирә-як авылларның кешеләре, тау куышын салам һәм куаклар белән томалап, аны яндырганнар (С.Мельников «Рождественское-Ямаши» (Каз. Губ. Вед. 1856, N 30). 3) Чуриле авылына бәйле, Казанда еланнарны кырган чакта канатлы аждаһа еланнарны үтерүче бер батыр артыннан куып китә дә «Алты кутар» дигән ерганак янында аны алтыга ботарлый. (Е.А.Малов. «Городище Старая Казань и г.Арск» (Записки Арх. О-ва, т.V). 4) Алабуга шәһәре янындагы Шайтан шәһәрчеге белән бәйле. Аннан Казанны алыр алдыннан «утлар чәчеп зур гына елан очып чыкты, һәм көнбатышка юнәлде, һәм безнең күздән гаип булды» (ПСРЛ XIX, с.68). Шәхсән безнең үзебезгә дә Алабуга өязенең Котловка авылында шуңа охшаш хикәят язып алырга туры килде. Бу авыл кешеләре әле дә бирердә бүрәнә калынлыгы зур еланнарның яшәвенә ышана икән. Казан урынында «елан оясы» булуы хакындагы риваятьне беренче тапкыр «Казан елъязмачысы» авторы кәгазьгә теркәгән. (ПСРЛ XIX, с.10-11). Татар каләм ияләре дә, урысларныкы да еланнар турындагы әлеге легендаларга аллегорик мәгънә сала, мөселманнар Казаннан куылган еланнарда мәҗүсилекне күрсә, христианнар әлеге еланнарда үзләре тарафыннан кысрыкланган исламны күзаллаган.

Авыздан-авызга күчкән риваятьләр арасында кирмәнгә нигез салу турындагысы бар: аның астына беренче очраган кешене күмәргә тиеш булалар, әмма ул кеше хан улы булып чыга, осталар, аны җәлләп, нигезгә эт күмеп калдыра, шуның нәтиҗәсендә Казан киләчәктә этләр кулына калачак, дигән фараз ясала. (Георги, «Bemerkungen eines Reisenden in Russichen Reich», 1975, II, с.813-815). Моңа охшаш легендалар бүтән төбәкләрдә дә таралган (мәсәлән, Түбән Новгородтагы Көянтә манарасы хакында) һәм алар кирмән салганда кеше корбан итәргә кирәк, дигән борынгы ышануларның кайтавазы; шик юк ки, без бирердә Казанның үзеннән дә борынгырак, күп вакытлар үткәч кенә аңа тәгаенләнгән легенда белән очрашабыз.

Хәзерге Казан чикләрендә беренче утрак урынны, мөгаен, «иске шәһәрлек» дигән урында тәгаенләргә кирәк. Ул күп тапкырлар «Царственная Книга»да, елъязмаларда, «Казан елъязмачысы»нда, 1566-1568 елларга нисбәтле битекче кенәгәләрдә телгә алына. Казанга һөҗүм итәр алдыннан урыс гаскәрләренең урынлашуын тасвирлаганда, «Царственная Книга» М.П.Головин отрядын «Казан» буйлап югары, иске шәһәрлек кырында» дип билгели (Царств. Книга, с.299, Никон.Лет., VII. с.173, Львов., IV, с.412). «Казан елъязмачысы»нда болай әйтелә: «иске шәһәрлектән түбәнрәк аскы капкадан, аннары хәзер Никола Чудотворец храмы торган Збойлы капкасы яныннан, Черек күлләр артыннан алгы полкның ертаулы

КРЕМЛЬ КАЛКУЛЫГЫ

Казан кирмәнендә төрле биналар булган. Алар арасында безнең игътибарны бигрәк тә хан сарае җәлеп итә. Ул Кремль калкулыгының төньяк очында урнашкан була. Хәзерге вакытта бу урында губернатор сарае. Хан сарае үзара тоташкан берничә таш һәм агач бинадан гыйбарәт булып, агач койма белән әйләндереп алынган, – «таш пулатлар һәм мәчетләр арасында бик тә нык итеп салынган, биек койма эчендә» (Курбский, с.27). 1566 елга нисбәтән Битекче кенәгәсе җимерелгән Хан сараен болай сурәтли: «Введенья Пречистые (сарай чиркәве) сарае кечкенә, яшәр өчен җайлы бүлемнәрдән торган.

Урыслар бушап калган Хан сараена урнашмаган һәм аны арсенал итеп файдаланган. XVIII гасырда хан сараеның исән калган биналары 1730 елларда корылган комендант йортына нисбәт ителгән. XVIII гасырның ахырындагы планнарда мондый биналар теркәлгән: 1) губернатор сарае урынында һәм 2) сарай чиркәве белән Тайницки капка арасында; проф. С.М.Шпилевский аларны Битекче кенәгәсендә әйтелгән ике пулатның калдыклары дип фаразлый (Шпилевский, с.459). Хан сарае Казанның яңа хуҗалары тарафыннан ташландык хәлгә

Казан кирмәне, XII гасыр. Фиринат Халиков картинасы.

һөҗүм итте». 1566-1568 елларга нисбәтле битекче кенәгәләрендә «иске шәһәрлеккә каршы Тула острог капкасы» һәм «шул ук иске шәһәрлеккә каршы острогтагы капкасыз маш» телгә алына. («Писцовая книга», с.49). Шул рәвешле Иске шәһәрлек урыны түбәндәгечә билгеләнә: «Казан (елгасының) югары агымында», «Збойлы дигән түбән капка янында, ул урында хәзер Никола Чудотворец храмы (Параскева-Пятница чиркәве һәм «Тула капкасына каршы», ул исә Никола Тульский чиркәвеннән (хәзер Казан монастыре) ерак булмый. Тәгаен сүз хәзер Казан монастыре урнашкан калкулык хакында бара. Соңрак, XVIII гасырда, Иске шәһәрлек дип Федоров калкулыгы саналган. Ул исә Казан суының тагын да югарырак төшендә. 1739 елда Пестриков төзегән Казан тасвирламасында бу калкулыкка салынган Федоров монастыре «Иске Казан шәһәрлегендәге ирләр монастыре» дип билгеләнә. Шушы тасвирлама проф. Н.П.Загоскинга һәм бүтән тикшерүчеләргә Иске шәһәрлекнең урыны Федоров бугорында дип расларга сәбәп булган. Ләкин без әлеге урынның хәзер Казан хатын-кызлар монастыре урнашкан калкулыкта булуын дәлилләдек.

янындагы элек Хан сарае булган урында ике иске пулат... агач йорт... Хан сарае каршында тагын иске пулат, янәшәдә тагын бер пулат» (Писц.Книга, с.34). Шулай итеп Казан ханлыгы тар-мар ителеп 14 ел үткәннән соң Хан сарае урынында ике таш пулат һәм бер агач йорт сакланган, алардан кала «сарай каршында» таш бина һәм шундый ук бина «Сарай янында». Битекче кенәгәсендә тагын «Хан сарае» янәшәсендәге пулат». (Писц.Книга, с.8), «Хан сарае янәшәсендәге кече пулат» (Писц.Книга, с.9) һәм «Хан сараена каршы пулат» (Писц.Книга, с.9) телгә алына, ләкин алдан саналган пулатларга боларның ни катнашы бар, ачыклавы кыен. Мөгаен, бирердә бер үк пулатлар турында сүз барадыр. «Казан елъязмачысы» да хан сарае янында берничә бина булуын хәбәр итә: 1551 елда урыс воеводасы Хан сарае кырындагы пулатларның берсенә туктаган (ПСРЛ XIX, с.77). Шулай итеп, хан сараеның таш пулатлардан һәм агач биналардан гыйбарәт булып, койма белән әйләндереп алынуы аңлашыла. Аерым-аерым алар артык зур булмаганга охшый, Битекче кенәгәсе агач йортның аркылысы 4 сажин булуын хәбәр итә. Димәк, Хан

китерелә, ләкин татар чорының таш биналары әле тагын өч гасыр дәвамында вакыт сынавына һәм афәтләргә бирешми. XIX гасыр башында алар әле исән була. Әгәр дә урындагы түрәләр әмере белән сүтелмәсә, алар әле бүгенгә кадәр сакланыр иде. К.Милкович язуынча, 1804 елда кирмәндә элекке Казан ханнары сараеның диварлары һәм калдыклары күренеп торган («Историографическое описание о Казанской губернии» К.Милковича. Известие О-ва Арх.Ист. и Этн., XIV, вып.5, с.502, прим. 2) 1815 елда «Казанские известия» газетасында «15 ел элек сүтелгән Сөембикә сарае» хакында сүз бар (Загоскин, с.99). Фукс яза: «1807 елда мондагы кальгада татар архитектурасының соңгы калдыгы булган Хан сарае сүтелде» (Фукс «История Казани», изд-е 5, Казань, 1904, с.1, прим. 1). Второв 1830 еллар ахырында яза: «Сөембикә манарасының төньяк-көнбатыш капкалары артында әле күптән түгел генә Сөембикә сарае дип аталган бинаның хәрабәләре бар иде, алар инде хәзер юк» («Памятники древности в Казанской губернии» (Журн.Мин. Вн. Дел., 1840, т.37). Н.П.Загоскин фаразлавынча, комендант йортының корылмалары арасында татар дәверенең таш биналары

китабыннан өзекләр

губернатор сараена нигез салганчыга, ягъни 1840 еллар башына кадәр сакланган булырга мөмкин: «Иске комендант йортының какшаган стеналары хәзерге Кремль сараен салганда (1845 елның язында) сүтеләләр. Димәк, Казан ханнары сараеның соңгы калдыклары бу гасырның (XIX) 30 нчы еллар ахырында яки 40 нчы еллар башында гына юкка чыгарыла, дип расларга хакыбыз бар» («Спутник по Казани», с.99).

Кызганычка күрә, бүгенгә кадәр хан сараеның эзләрен табу омтылышы булмады. Татар Казаны әлегә кадәр җир астында һәм үзенең тикшерүчеләрен көтә. Җирле археологлар татар Казанына карата аңлап булмаслык битарафлык күрсәткәннәр. Казан университетына нисбәтле Археология, Тарих һәм Этнография җәмгыяте 45 еллык яшәү дәверендә Болгарда, Биләрдә һәм бүтән төбәкләрдә тикшеренүләр үткәрде, ләкин XV-XVI гасырларда гөрләп торган татар шәһәре урынына утырган Казанның үзе белән аз гына да кызыксыну сизелмәде. Кремльнең кеше кулы кагылмаган туфрагы татарның күп санлы борынгы әйберләрен саклый һәм тикшерүчеләрне зур табышлар көтә. 1861 елда кафедраль Соборның болдырын үзгәртеп корганда очраклы рәвештә килеп чыккан табылдыклар да моңа дәлил була ала. Анда таш биналарга күпертеп сылап ясалган бизәкләрнең кисәкләре, Болгарныкына охшаган савытлар, берничә төрән, Мәскәү акчаларыннан торган хәзинә һ.б. әйберләр табыла. Бу табылдыкларның бер өлеше Казан университетының География кабинеты музеенда саклана. Кремль туфрагының мәдәни катламы калын, без моңа Илбуга һәм Төмән капкалары янында очраклы рәвештә ишелгән җирне күреп шаһсән ышандык. Казан кремлендә археологик тикшеренүләр өчен иң уңайлы урын нәкъ менә хан сарае торган төштә – губернатор сараеның ишегалдында һәм бакчада, бу җир тарихи яктан аерата зур кызыксыну уята.

Хан сарае янәшәсендә таш мәчет булган. Урыслар аны, хан сарае кебек үк, корал саклау өчен файдаланалар: Битекче кенәгәсендә туплар һәм тимер әйберләр өчен бина телгә алына: «Иске хан сарае янындагы мәчеттә» (Писц.Книга, с.7), шулай ук анда дары да саклана: «Благовещениегә (ягъни Кафедраль соборга) каршы мәчеттә» (Писц. Книга, с.8). 1861 елда Кафедраль соборның болдырын үзгәртеп корганда табылган күпертеп сылап ясалган бизәкләр әлеге мәчетнең собордан ерак булмавы турында сөйли. Ул Сөембикә манарасы белән хәзерге собор арасында торган дип фаразларга мөмкин. Риваять буенча, Сөембикә манарасы мөселман изгесе җирләнгән урында салынган; бу урыннан хәзерге Тайницки капка тирәсендәге чишмә янына чыга торган җир асты юлы башланган. Икенче риваять буенча, Сөембикә манарасы Сафа Гәрәй хан кабере өстенә корылган. Татарлар, Болгардагы Кече Манара тирәсендәге төрбә хәрабәләренә һәм изгеләр каберенә килгән кебек үк, мөселманнар өчен изге булган бу урынга да дога кылырга киләләр. Казанда чыннан да суфи шәехләр Ибраһим улы Касыйм, Бохарадан Фәйзулла әфәнде җирләнгән, һәм алар мөселманнар тарафыннан изгегә санала.

● Казан кирмәне, XIII гасыр. Фиринат Халиков картинасы.

Татарлар дога кылырга килгән кабергә шушы шәехләрнең берсе җирләнгән, дип фаразларга мөмкин. Димәк, татар Казанында Сөембикә манарасы янында изге кеше җирләнгән төрбә яисә зират булган, дип уйларга нигез бар. Ә мәчет бу урыннан ерак булмаган.

Хан каберләре өстендә таш төрбәләр корылуы хакында мәгълүмат безгә килеп җиткән. Казан мәчетләре турында язганда, кенәз Курбский «монда ук үлгән патшалар күмелгән» дип өсти (Ист. кн.вел.Моск., с.17). «Казан ельязмачысы» «үлгән патша (Сафа Гәрәй) җирләнгән мәчет» турында телгә ала (ПСРЛ XIX, с.78).

Дәүләтнең атаклы кешеләреннән Ширин бәкләрнең сарае да хан сараеннан ерак булмаган. Шириннәрнең соңгы бәге исеме белән сарайга якын торган кирмән капкасы Нургали (Мөрәле) капкасы дип аталган. Димәк, Шириннәрнең сараен шушы капка тирәсендә эзләргә кирәк.

Урыслар цейхгаузга әйләндергән таш пулат та Шириннәр сараеның бер өлеше булган, күрәсең, Битекче кенәгәсендә «Муралеевски палатада» (Писц. книга, с.9) тәгәрмәчләр һәм ватык туплар саклануы язылa. Ләкин бу хәбәр тәгаен Ширин бәкләрнең сараен түгел, ә аның янындагы мәчетне күздә тота булса кирәк. Нургалинең таш мәчете Казан алынганда исән кала һәм ул Битекче кенәгәсендә искә алына: «Илант монастыре ишегалдында Нургалиныкы (Мөрәленеке) булган мизгит (мәчет)» (Писц. книга, с.34). Бу мәчетне хан сарае янәшәсендәге мәчет белән тәңгәлләштерергә ярамый, чөнки Зилант монастыре ишегалдының хан сарае калдыклары белән кафедраль собор арасында булуы мөмкин түгел. Мөгаен, Нургали мәчете Кремль калкулыгының төньяк-көнбатышында, Тайницки капка белән Хәрби мәктәп тирәсендә торгандыр. «Благовещениегә (кафедраль соборга) каршы мәчет» дигәндә Битекче кенәгәсе аны күздә тота, ә «иске хан сарае ишегалдында» дигәндә урыслар туп саклау өчен тоткан Хан мәчете турында сүз бара. Нургали сараеның һәм мәчетенең хәзерге кафедраль соборга каршы урнашкан булуын раслаганда янә Битекче кенәгәсенә таянабыз. Ул Нургали пулатын («Муралеевская палата») «Благовещениегә каршы пулат» белән тәңгәлләштерә (Писц.книга, с.9). Ширин бәкләр салдырган таш бина ике катлы булган, икенче катка тышкы яктагы тимергә төрелгән агач баскычтан менеп йөргәннәр. Битекче кенәгәсе «Благовещениегә каршы пулатның тимергә төрелгән күтәртмәсе черегән», дип хәбәр итә (Писц. книга, с.9).

Тагын бер таш бина – урыслар арсенал иткән «Хан сараена каршы» булган пулат хакындагы хәбәрдән аның аерым бинамы яки алдан саналганнарның берсеме икәнлеген ачыклавы кыен. 1566 елда исән калган таш биналарның саны 5тән ким булмаган: 2 пулат хан сарае урнашкан төштә (монда бер агач йорт та була), Нургали мәчете, хан сараеннан читтәрәк тагын ике пулат.

Хан сарае тирәсендә яшерен урын – кирмәннән Казан елгасы ярындагы чишмә янына чыга торган җир асты юлы булган. Чишмә Нургали һәм Илбуга капкалары арасында типкән. Проф. Н.П.Загоскин болай яза: «Әгәр дә без Казан кремленең Сөембикә манарасыннан Казан суына төшә торган юл белән Тайницки (борынгы Нургали) капкасыннан чыксак, елга ярына төшеп уңга борылсак, агымга каршы берничә дистә сажин атласак, «Тайницки кизләү» дип аталган чишмәгә барып чыгарбыз. 1552 елда шәһәрне урыслар басканда, чолганышта калган казаннар яшерен җир асты юлыннан су алыр өчен шушы чишмәгә төшкән. Чолганыштагыларны бердәнбер яхшы сыйфатлы судан мәхрүм итәр өчен урыслар аны шартлаткан. Әле бу гасырның (XIX) уртасында чишмә ташлар белән әйләндереп алынган иде, ләкин хәзер исә әлеге тарихи чишмә ташландык хәлдә һәм елдан-ел суы саега бара; хәзерге Казан обывательләре арасында нигәдер әлеге чишмә суы кыяр тозлар өчен яхшы сыйфатлы, дигән ышану яши, шуңа һәр җәй ахырында суны моннан күпләп ташыйлар. Мондагы мөселманнар чишмәне изгегә саный, суын дәвалану өчен файдаланалар, татарлар бирегә еш кына намаз укырга килә. Әле 1829 елда гына «бушлык»ның, ягъни кремльдән кизләүгә илтә торган яшерен юлның кайда икәнлеген белгәннәр. Дөрес, аның керү-чыгу юллары томаланган була («Спутник по Казани», с.104-105). «Царственная книга» да яшерен җир асты юлы турында җентекләп яза: «Һәм патша Казаннан яңа качып чыккан Камайны үз хозурына чакырды һәм шәһәрдә суны кайдан алулары турында сорады, чөнки Казан елгасына аларның юлын кистеләр бит инде. Шул турыда ул көннәрдә патша хозурына качып чыккан әсирләрдән дә сорады. Һәм алар әйтте: Нургали капкасы янындагы Казан елгасы ярында типкән чишмәгә аларның яшерен юлы бар; алар җир астыннан йөриләр, диделәр». Болак тамагында торучы саклаучы полкның командиры кенәз Василий Серебряныйга, астан казып кереп, әлеге яшерен юлны шартлатырга әмер бирелә. – «Алар ун көн эчендә татарлар суга йөри торган басма астына кадәр казып керде, һәм кенәз Василий белән иптәшләре, татар тавышларын ишетеп, аларның үз өсләреннән су алырга йөрүләрен аңлаганнан соң патшага бу турыда хәбәр итте». 4 сентябрьдә җир асты юлы шартлатыла. Әлеге җир асты юлына нисбәтле рәвештә Нургали капкасын урыслар Тайницки капка дип атаган. Чыннан да, кирмәннән, хан сараеннан башланган яшерен юл, камалышта калучыларның соңгы качу урыны буларак, дивар астыннан үтеп Казан елгасының ярына чыккандыр. Казанны урыслар алганнан соң татар гаскәренең калдыклары хан сараеннан нәкъ шул яшерен юл чыккан юнәлештә Казан елгасының теге ягына кача. Ләкин яшерен юлны 4 сентябрьдә шартлату нәтиҗәсендә алар каладан атылып чыга («с града метатися»), ягъни дивардан аска, Казан ярына, сикерәләр (Царств. Книга, с.307, Курбский, с.30).

Яшерен юлны 4 сентябрьдә шартлатуның урыслар өчен әһәмияте шунда була да инде. Аларның чын максаты, «Царственная Книга»ны төзүче хәбәр иткәнчә, казаннарга су алу юлын бүлү түгел, ә камалучыларның чигенү мөмкинлеген юк итү була. Казан исә эчәр суга интекмәгән, шәһәр эчендәге мул сулы күлләр (Ак күл, Мунча күле һ.б.) казанлыларның ихтыяҗын канәгатьләндергән.

(Дәвамы киләсе санда).

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА тәрҗемәсе

Рафис КОРБАН

АЛИШ

Урамда яз. Сугыштан соңгы беренче яз. Кояшлы, аяз матур көн. Карлар да инде эреп бетеп бара. Табигать җанланган. Агач башларында кара каргалар, чәүкәләр каркылдаша.

Гөрләвекләр дә агудан туктады югыйсә, бөтен киеме манма булырлык суны каян тапкандыр, урамнан чалбар балаклары, пәлтә итәкләре юешләнеп беткән Алмаз кайтып керде.

– Кайда йөрдең? Каян гына таптың шундый суны? Бер коры җебе дә калмаган бит чалбарыңның, улым, кайда киптерәбез инде хәзер боларны? – диде Оркыя, улының пәлтәсен өстеннән салдыра-салдыра.

– Черек күлгә кергән идем, әни, мин әле аның бозы каты дип торам, ул инде эреп беткән икән, ике адым атлауга бот төбеннән юеш карга төшеп баттым.

– Әй җүләрем, бу вакытта боз була димени инде? Әле ярый бөтенләй батмагансың. Әйдә, тиз чишен, сыгып элеп куярга кирәк чалбарыңны. Әле ярый казан асты учагын яккан идем, син кайта дип кыстыбый пешерергә.

– Кыстыбый?! Каян алдың бәрәңгесен, әни? Үткән атнада ашка турап салырга да калмады бәрәңге дигән идең бит.

– Калмаган иде. Атна арасында авылдан Закирә апаң белән Илсөяр килде. Күп итеп бәрәңге, балык алып килгәннәр. Гали җизни Актачыда бәке астыннан тоткан балык, ди. Сиңа да калды, иртәгә уха итеп пешерербез, – диде Оркыя. Улының өстеннән киемнәрен салдырып, мич артына кертеп, кер киптерер өчен этиләре махсус тарттырып калдырган чыбыкка элеп куйды. Чыбыкта инде абыйсы шикелле үк суга батып кайткан Айвазның чалбары да кибә иде. Анысы кайда юешләнеп йөргәндер инде, абыйсы кайтып кергәнне күргәч, күрше бүлмәдә ни беләндер шөгыльләнеп утыручы малай алар ягына чыкты да, абыйсын килеп кочаклап алды.

Оркыя һәм учак алдында табак белән каплап куелган бәләкәй табаны чыгарып, өстәл өстенә куйды. Коридор башындагы юынгычта кулларын чылаткан малайлар өстәл артына килеп утырырга да өлгермәде, ишеккә шакыдылар. Барысы да куркып ишеккә борылды. «Кем булыр икән?» дип уйлады Оркыя, шомланып.

– Әни, эти кайтты микән әллә? – диде Алмаз һәм сикереп, ишеккә таба йөгерде. Айваз да абыйсы артыннан барырга дип урыныннан торды.

– Улым, тукта, ашыкма әле. Кем йөри икән бу вакытта?– дип, Оркыя тәрәзәгә карап куйды. Кич булып килә иде. Тагын шакыдылар.

Оркыя батырлыгын җыеп:

– Кем бар? – дип сорады.

– Ачыгыз әле, ирегез турында хәбәр белән килдем, – диде тавышы таныш булмаган ниндидер ир кеше.

Сугышның беренче елында ук хәбәрсез югалган, инде сугыш беткәнгә дә бер ел булса да кайтып күренмәгән ире турында нинди хәбәр алып килергә мөмкиннәр, дип, Оркыя куркып калды. «Теге оешмадан килделәр микән әллә?» дип уйлап куйды, ишек янына барып баскач та, ачаргамы, юкмы, дип, икеләнеп торганда, шаку тагын кабатланды. Урыннарына барып утырган малайларына карап алды да, ул кабаланып ишекне ачты. Ишек төбендә кыршылып беткән иске генә пәлтә, аягына кирза итекләр кигән, гәүдәгә чандыр, киң җилкәле булса да, гаҗәеп ябык, утыз-утыз биш яшьләр тирәсендәге кара чәчле бер кеше басып тора иде.

– Сез кем? Иремне каян беләсез? Исәнме ул? Исәнме? Әйтегез тизрәк! – дип, үзендә кыюлык җыеп, Оркыя ирнең пәлтә җиңенә барып ябышты.

Ир хатыннан мондый кыюлык көтмәгән иде, ни әйтергә дә белмичә беркавым басып торгач:

– Өйгә керергә рөхсәтме? – дип сорады.

Оркыя аны ишектән эчкә үткәрде. Ир кереп, өстәл артында утырган малайлар янына килде.

– Алишның «Ике улым бар» шигырендәге батыр малайлар менә нинди икән! – дип, аларның башларыннан сыйпады һәм кесәсеннән ике шакмак шикәр чыгарып учларына салды.

– Йә, сөйләгез инде, исәнме безнең этиебез? – диде Оркыя, малайлар янына килеп утырган кешедән ире хакында яңалыкны тизрәк ишетергә теләп.

Кунак Алиш турында турысын әйтергә уңайсызланды бугай:

– Үлми торган әсәрләр язып калдырган Алиш, – диде һәм кесәсеннән бәләкәй генә ике дәфтәр чыгарды. – Менә бу дәфтәрләрдә Муса Җәлил белән Алишның үлмәс әсәрләре.

Оркыя дәфтәрләрне кунакның кулыннан йолкып диярлек алды да, дөньясын онытып, аларны актара башлады. Кунак үзенең кем булуы, бу дәфтәрләрнең аның кулына ничек килеп керүе хакында сөйләде. Һушы киткән хатын аның бер сүзен дә ишетмәде. Ишетсә дә, хәтерендә калдырырлык хәлдә түгел иде.

– Нигъмәт исемле кеше мин. Нигъмәт Терегулов. Алиш, Җәлилләр белән бергә пленда булдым. Легионда фашистларга каршы көрәш алып бардык. Җәлилне, Алишны, әле тагын бик күп егетләрне фашистлар җәзалап үтерделәр. Алла саклап, мин исән калдым. Җәлил һәм Алиш белән бер төрмәдә утырган Габбас Шәрипов дигән кеше гаепсез дип табылып, төрмәдән чыгарылганда, аларның шигырьләрен яшереп үзе белән алып чыккан. Безгә аның белән Франциядә очрашырга туры килде. Алишның шигырьләрен берничә дәфтәргә күчереп, кайсыбыз исән-сау илгә кайта алсак, кайтарып тапшырырга дип,бер-беребезгә бүлештек. Башкалар кайта алмаган, күрәсең, менә мин кайтарып җиткердем, сезгә тапшырам. Җәлилнекен дә калдырам. Аның гаиләсе Казанда түгел икән. Мәскәүгә үк барып эзли алмыйм. Язучылар союзына бирерсез инде. Васыятендә шулай язган Муса.

Кунак шуларны сөйләде дә, тагын бер тапкыр малайларның башларыннан сыйпап алды.

– Менә бит, үз эшен дәвам итәргә ике батыр калдырган Алиш. Үзләре белән горурланып шигырь дә язган, – диде дә,– Ике улым бар, – дип, күңеленнән бикләп куйган шигырьне укырга тотынды:

Һәрбер эшне җитез эшли торган
Корыч кебек ике улым бар.
Ике кулым кебек, үсеп килгән
Булышчым бар, ике улым бар.

Ике күзем минем үткен күрә,
Кай тирәгә дошман посканын.
Ике күзем кебек ике улым
Сизгер саклар илнең постларын!

Шуышмасын дошман тирә-якта,
Колакларым яхшы ишетә.
Мин үлсәм дә, ике улым кала,
Алар ишетер икесе ничек тә.

Ике аягым минем чыдам булды
Ерак походларга чыкканда.
Аякларым кебек ике улым да
Сынатмаслар әле ятларга!

Әтиегезнең шигыре бу. Сезгә багышлап язган. Әтиегез кебек батыр булып үсегез!

Шулай диде дә, кунак китәргә җыенды.

– Чәй дә эчмәдегез, – диде Оркыя. – Кыстыбый пешергән идем, улым кайта дип. Суворов мәктәбендә укый Алмазыбыз. Әтисе кебек туган илне саклаучы булырга җыена. Ялларга өйгә кайтып йөри.

– Бик әйбәт. Илгә батыр солдатлар кирәк, – дип, ул торып басты.

– Гафу итегез инде, югалып калдым. Исемегезне дә оныттым хәттә,– диде Оркыя, уңайсызланып.

– Нигъмәт атлы мин, Нигъмәт Терегулов. Уфадан килдем. Әле тагын берничә көн булам Казанда. Бәлки, тагын килеп чыгармын. Кирәгем чыга калса дип, Казанда тукталган адресымны язып калдырам,– дигәч, ул Азмаздан кәгазь белән карандаш китереп бирүен сорады.

Алмаз нишләргә икән, дигәндәй аптырап әнисенә карап алды. Оркыя үзе ашыгып барып, түрдә торган шкафтан кәгазь белән каләм алып килде дә:

– Менә, языгыз, – дип, кунакка сузды. Ир Казанда тукталган җиренең адресын язганнан соң, кәгазьне Оркыяның кулына тоттырып:

– Хәзергә сау булыгыз, – дип, ишеккә юнәлде.

Оркыя кунак артыннан ишекне ябып, ачкычны борып бикләде дә, уллары янына килеп, өстәлдә яткан дәфтәрләрне кулына алды. Болар, берсе шактый калынрак, икенчесе юка кына, бәләкәй ике дәфтәрчек иде. Калын дигәне Җәлилнеке булып чыкты. Төрле кәгазьләрдән төпләнгән блокнот кебегрәк бу дәфтәр тышлыгына латин хәрефләре белән язылган «Taschenbuch»дигән сүзне укыды.

– «Сүзлек» дип язганнар! – дип куйды Алмаз. – Әни, немецча язганнар монда, «немецча, төрекчә, урысча сүзлек», дигәннәр! Гарәп хәрефләре белән Муса Җәлил дип тә язылган. Өстә 1943 дигән.

– Кырык өченче елда исән булганнар икән әле, бәгырькәйләр. Кырык беренче елда ук хатлары килми башлады бит инде этиегезнең.

Шулай дигәч, Оркыя Җәлилнең дәфтәрен улына биреп, Алишныкын үзе укырга җыенды. Дәфтәр уч төбе хәтле генә, юка һәм нибары унлап шигырь язылган иде. Берсе дә Алиш кулы түгел, кемдер күчереп язган икәнлеге күренеп тора. Кунак та шулай диде бугай шул.

– «Ике улым бар» ... Монысы Терегулов укыган шигырь икән... Яттан сөйләде...

Икенче шигырь «Өченче күз» дип атала иде.

Саргаешып каен яфраклары
Өченче кат җиргә коела.
Өч кенә ел үтте микәнни соң?
Ун ел үткән кебек тоела... –

Шул вакыт Оркыяның тавышы калтыранып китте. Күзләрен яшь томалады. Ул, укудан туктап, дәфтәрне улына бирде. Шигырь укуны Алмаз дәвам итте:

Ил бәйрәмен инде өченче кат
Тоткынлыкта, читтә үткәрәм.
Бер файдасыз, дуслар, үтә гомер,
Бушка үтә – үтә, әй, әрәм!

Алмаз туктап әнисенә карады. Ул мышык-мышык килеп елый иде.

– Әни, елама. Син елагач, минем дә елыйсы килә, – диде Алмаз.

Ул арада боларны шыпырт кына тыңлап утырган бәләкәй Айваз үкереп үк еларга тотынды. Оркыя улы Алмаздан Җәлил дәфтәрен алып, аның шигырьләрен карарга кереште. Беренче битен ачып, укырга да тотынды:

Буран.

Күз ачкысыз каты буран чыкты
Юл табалмый, атлар туктады.
Кар пәрдәсе аша күренеп кала
Ерак түгел авыл утлары...

Ул кычкырып укудан пышылдап кына укуга күчте. Дулкынланудан, аның тавышы калтырый иде. Шулай да шактый озын гына шигырьне йөгертеп укып чыкты да, «Кара син аны, пленда да гашыйк булу турында язган, мутлыгын анда да ташламаган бу җүнсез», – дип куйды.

Шунда Оркыя торды да, ишек катында эленеп торган пәлтәсен барып кия башлады.

– Әни, кая барасың? – диде Алмаз.

– Сезнең белән елашып утырып булмый, мин Кадрия апаңнарга барып кайтам әле, – диде Оркыя.

– Мин дә барам. Минем дә Ләйлә белән Аданы күрәсем килә! – диде малай.

(Дәвамы киләсе санда).

(Ахыры. Башы 44, 45 нче саннарда).

Даннан мәхрүм татарлар

ЗӘЙНЕТДИНОВ КӘЛИМУЛЛА ВӘЗЫЙХ УЛЫ

Зәйнетдинов Кәлимулла Вәзыйх улы 1923 елда Кама Тамагы районының Иске Казый авылында туа, 1942 елның 1 маенда Теньки комиссариаты аша сугышка озатыла. Көньяк һәм Төньяк-Кавказ фронтларында 9 нчы армиянең 11 нче укчылар корпусында 19 нчы укчылар полкында снайпер-мәргән, өлкән сержант булып яу йөри. Өч тапкыр яралана, Кызыл Йолдыз һәм Кызыл Байрак орденнарына лаек була.

1942 елның 18 июленнән башлап 1943 елның 5 гыйнварына кадәр Төньяк Осетиянең Моздок шәһәрен азат иткәндә Зәйнетдинов 200 дән артык гитлерчыны үзенең снайпер винтовкасыннан атып юк итә. Яраланганнан соң госпитальдә дәваланырга туры килсә дә, кабат үз постына әйләнеп кайта һәм шәхсән үзе юк иткән гитлерчылар санын 226 га җиткерә. Ә бит бер дә уен түгел, ул дошманның 37 офицерын, 26 снайперын, 4 пулеметчыны, 4 җайдакны, 6 автоматчыны, 149 пехотачы солдатны сафтан чыгарган бит! Аннан тыш, ул әле 46 кызны снайпер булу серләренә өйрәткән.

1943 елның 27 июнендә аны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итәләр, ләкин аны тагын да шул Кызыл Байрак ордены белән генә йомып куялар. Полкташлары аны 1944 елның 22 июнендә һичьюгы Ленин орденына тәкъдим итеп караса да, штабтан янә Кызыл Байрак ордены гына әйләнеп кайта. Ә югыйсә, Севастополь өчен һөҗүм барышында Зәйнетдинов шәхсән үзе юк иткән гитлерчылар санын 251 гә кадәр җиткерә бит!..



ГЫЙМАЗЕТДИНОВ САЛИХ ЗАҺРЕТДИН УЛЫ

Гыймазетдинов Салих Заһретдин улы 1919 елда Казан каласында туган һәм 1939 елның 18 мартында Сталин район комиссариаты тарафыннан Кызыл армиягә чакырылган. Немец фашистлары белән яуга 1941 елның 22 июнендә керә. Төньяк, Төньяк Кавказ һәм 3 нче Украина фронтлары аша үтә. Диңгез пехотасының 83 номерлы аерым Новороссийск укчылар бригадасында, аерым разведка ротасында старшина дәрәҗәсендә хезмәт итә, Кызыл Йолдыз орденына лаек була.

1944 елның 21 августында Днестр култыгын беренчеләрдән булып кичә һәм дошман туктаусыз атуга карамастан, Карловка авылына бәреп керүгә, анда гитлерчыларның бер ут ноктасын юк итүгә ирешә. Икенче көнне дошман обозын тар-мар итүдә катнаша. Кул сугышы барышында яраланса да, коралыннан атудан туктамый. Ә инде үзенең патроннары беткәч, бер трофея автоматы белән һаман гитлерчыларны юк итә. Граната шартлаудан аты вафат булса да, Гыймазетдинов бер немец офицерын атып үтереп, аның атын эләктерә. Бер яу барышында гына да ул дошманның 3 офицерын, 6 пулеметын, 18 олавын, бер туп һәм 70 кә якын сугышчысын юк итә. Ул гына да түгел, әле 12 пулемет, 3 офицер һәм 230 гитлерчыны үз кулына төшерә.

1944 елның 31 августында аны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итәләр, ләкин каһарманлык бәясе татар егетенә Кызыл Байрак ордены булып кына кайта.



Михаил ЧЕРЕПАНОВ.
«Миллиард татар» челтәреннән.
Вахит ИМАМОВ тәрҗемәсе.

● Фәйзрахман Әминев. Автопортрет.

● Кызыл киемле кыз портреты.

Фәйзрахман Әминев– милли иҗат

(Татар рәссамы, акварелист, иллюстратор һәм график Фәйзрахман Әминевның тууына 115 ел)

Ул Пермь губернасына караган Көңгердә 1908 елның 10 августында дөньяга килгән. Аның әти-әнисе чыгышлары буенча – татар җирлегеннән, әтисе Габдрахман – Яшел Үзән районының Танай, ә әнисе Зиһнекамал – Кайбыч районының Кече Кайбыч авылыннан. Гаиләдә аннан кала тагын 4 ир-бала үскән. Бу хакта рәссамның өлкән улы, шулай ук киңкырлы иҗатка ия рәссамыбыз, профессор Фәйзулла Әминев бәян итте.

Ул: «Әтием хакында күп язылган инде...» – дисә дә, минемчә, аның бар иҗат эшләре дә тупланган, ким дигәндә 400 ләп битле саллы китапның дөнья күргәне юк әле. «Анысы шулай, – дип дәвам итте сүзен хөрмәтле Фәйзулла әфәнде. – Әйе, әтием иҗаты буенча монография тибындагы ике басма гына нәшер ителде... Аның күп эшләре үземдә кадерләп саклана һәм аларны аның иҗатын үз итүчеләр күргәндер, истә калдыргандыр, дип өздереп кенә әйтә дә алмыйм... Әсәрләре безнең остаханәдә дә бар. Әти иҗат иткән остаханә хәйран зур – 114 кв.м, анда әле совет чорында язылган гаять күләмле Ленин портреты да эленеп тора. Ул – киндер өслегендәге сурәт. Әмма инде совет җырлары җырланып бетте, һәм әтинең бу әсәре дә шул сәбәпле остаханә диварында...»

Әлбәттә, Фәйзрахман Габдрахман улы совет елларында үскән, аның рухи дөньясы шул чорда ныгыган. Аның тормыш юлына тагын бер тапкыр күз салсак, Әминевлар гаиләсе 1922 елда Пермьга күченгән. Билгеле, һәр кечкенә бала кебек, Фәйзрахман да 3-4 яшеннән төрле рәсемнәр ясарга керешкән. Шәһәрнең татар-башкорт мәктәбендә укыганда ук ул үз рәсемнәрен башкаларга караганда күпкә остарак ясавы белән дә аерылып торган. Мәктәптә еш кына «шәхси күргәзмәләр»ен дә ачкан.

Җиде сыйныф тәмамлагач, 1927-1930 елларда Пермь сынлы сәнгать техникумында укыган. Аннары ике ел шушы каланың дәүләт опера һәм балет театрында рәссам-бизәүче булып эшләп алган. 1933 елда Ленинградка киткән, 1933-1937 елларда шундагы Сынлы сәнгать, сынчылык һәм архитектура институты каршындагы эшчеләр факультетында гыйлем туплаган. «Әтием аяк киеме тегүчеләр нәселеннән иде бит, – дип ачыклады Фәйзулла Фәйзрахман улы. – Хәтерләсәгез, Сталинның атасы да аяк киеме теккән. Сталин ул чакта бу һөнәр ияләрен бик үз иткән. Укырга кергәндә: «Без сине шушы факт аркасында гына да укырга кабул итәбез», – дигәннәр әтигә». Сәләт иясе 1937 елда шушы институтның сынлы сәнгать факультетында укый башлаган. Бөек Ватан сугышы елларында янә Пермьга кайтып, Ф.Э.Дзержинский исемендәге оборона заводында эшләгән. Рәссамның 1940 елларда иҗат иткән «Солдат» портретында тамашачы йөзе борчулы, уйлары авыр булган ир-ат сурәтен күрә. Билгеле, бу күп хәрбиләрне борчуга салган еллар...

Ф.Әминев югары белем алуын 1945 елда гына дәвам итә алган. Үз осталыгын профессор Р.Френц остаханәсендә чарлаган. 1948 елдагы диплом эшен Фәйзрахман Габдрахман улы милли бәйрәм, татар халкы йоласы белән бәйләгән. Бүген аның «Татар бәйрәме Сабантуй» хезмәте, шул еллардагы иң яхшы диплом эшләренең берсе буларак, Россия Сынлы сәнгать академиясенең Фәнни-тикшеренү музеенда саклана. Останың шушы темага багышланган тагын бер якты

● I ранг капитаны Җанбулат Төхфәтуллин портреты.

● Ак күлмәкле ал алкалы кыз портреты.

● Хатын-кыз портреты.

● Хирург профессор Ф.Х. Кутушев портреты.

● Динара Ширинская портреты.

хезмәте дә бар. Ул да «Татарларның уңыш бәйрәме – Сабантуй» (1950) дип атала һәм аның күләме – 154х245,5 см. Иҗатчының мондый хезмәтләре булуы аңлашыла да, рәссам югары уку йортында фундаменталь сынлы сәнгать техникасына төшенгән ич.

1948 елда СССР Рәссамнар берлеге сафына кабул ителгәндә ул инде Ленинградта яшәп иҗат иткән. Рабига белән гаилә коргач, 1948 елда бу гаиләдә уллары Фәйзулла, 1949 елда Фәһим туган. Фәйзулла Әминев – бүгенге көндә һөнәри рәссам, акварелист, күп еллар буе студентларга белем биргән профессор. Фәһим Әминев исә сәнгать өлкәсендә түгел, ул – инженер.

1950 елларга кадәр оста тематик картиналар, авыл пейзажлары һәм портрет серияләрен иҗат иткән, гомумән, аның иҗатындагы портретлардагы йөзләр, мөлаем образлар тышкы һәм эчке матурлыклары белән үзләренә тартып тора. Арада милли киемле гади хезмәттәге татар хатын-кызлары, татар ир-атлары, зыялыларыбыз сурәтләре дә күп, киндерләрдә бу тормышта үзләрен сайлаган һөнәрләрендә тапкан, олуг мәртәбәләргә, зур дәрәҗәләргә ирешкән шәхесләрне дә күрәбез. «Әтием Н.И.Фешин иҗатының фанаты иде. Ул даһи Фешинның бар әсәрләрен дә бик ошатты», – ди Фәйзулла Әминев. Бу аңлашыла да, Н.Фешин портретларындагы сәнгати җанлылык бик күпләрне тагын да тырышыбрак язарга өнди. Мондый җанлылык Әминев ясаган сурәтләрнең һәркайсында да күзгә ташлана.

1952-1953 елларда ул Ленинградның В.И.Мухина исемендәге Югары сынлы сәнгать-сәнәгать училищесында студентларга белем биргән, ә менә 1953 елдан алып инде үз иркендәге һөнәри рәссам булып киткән.

Фәйзрахман Габдрахман улы ул елларда аеруча популяр булган темаларның берсен – каһарманлык темасын сайлап, әйтик, «Салават Юлаев», «Муса Җәлил», «Иптәшләр хушлашуы» картиналарына да теләп алынган.

Аннары рәссам инде безгә бик таныш булган акварель серияләрен иҗат итә башлаган, алар Г.Тукайның «Шүрәле», «Су анасы», «Кәҗә белән сарык» әкиятләренә багышланган, ә график битләрдә ул Тукайның «Таз» шигырен тасвирлаган. Аның әкиятләр белән бәйле акварельләре тирә-юньдәге гүзәллекне тулырак кабул итәргә өнди. Ә шулай да аларны тәүге күрүчеләр 1967 елда Ленинградта нәшер ителгән «Шурале» китабын укучылар булган, рәссамның кабатланмас иллюстрацияләре белән бизәлгән «Водяная» китабы да соңрак, бары тик 1978 елда гына басылган.

Оста Г.Тукайның берничә портретын да башкарган. Шулар арасыннан берсенә гарәпчә язмалар өстәгән, ә менә 1960 елда иҗат ителгән Тукай портреты шагыйрьнең без күреп, күнегеп беткән портретларыннан бераз аерыла, дөньялыкта ук изге җан – һәрчактагыча сыйфатлы кием-салымнан, йөзе дә тыныч, әмма ул һич кенә дә үтә ябык итеп тасвирланмаган, киресенчә, шагыйрь тук тормыш алып баручы инсан кебек, аның йөзе дә түгәрәкләнеп тора...

«Әтиемнең туган йорты», «Яз», «Казан артындагы Танай авылы» эшләре шулай ук – үз туган ягын данлау мисаллары. Аның дус-ишләре, Ленинград рәссамнары: «Фәйзрахман остаханәдә дә башына татар түбәтәен киеп кенә йөри иде, рәссам гаҗәеп дәрәҗәдә зыялы, тыйнак, тыныч, кунакчыл холыклы иде!» – дип искәртә.

Ф.Әминевның татар җырларына багышланган әсәрләре дә бар. Әйтик, 1971 елда ясаган тагын бер эше «Су буе. Җыр» дип атала. Татарның моңлы көйләренә, җырларына булган ихлас мәхәббәтен ул шушы рәвештә дә теркәгән. Әлеге эшендә татар милли киемен кигән ханым суга барырга дип капкадан чыгып килә, ул үзе бер матур булса, аның янәшәсендәге табигать күренешләре әкияти матурлыкта, гаҗәеп җете!

Фәйзрахман Әминевның үзе исән чакта ачылган шәхси күргәзмәләре күп түгел, аларның беренчеләре 1972 елда, рәссамга 63 яшь тулгач кына, Оренбург, ТАССР сынлы сәнгать музейларында узган, 1976 елдагылары – Ленинградта, Рәссамнар берлегенең Ленинград бүлегендә һәм ТАССРның дәүләт сынлы сәнгать музеенда Г.Тукайның тууына 90 ел тулуга багышлап ачылган. 1978 елның ахырында һәм 1979 елның башында Мәскәүдә, А.А.Фадеев исемендәге әдәбиятчылар үзәк йортында аның «Ф.Г.Әминев. Сәнгать. Графика. Татар әдәбияты классигы Г.Тукайга багышлана» күргәзмәсе дә, 1979 елда янә Казанда ачылган күргәзмәсе дә зур уңыш белән үткән.

Ул – ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1972) һәм РСФСРның атказанган рәссамы (1984) дигән мактаулы исемнәргә лаек зат.

Бу шәхесебез 76 яшендә 1984 елның 20 ноябрендә Ленинградта дөнья куйды. Фәйзулла Фәйзрахман улы кадерле әтисенең әйтеп калдырган васыятен үтәп, аның 150 әсәрен Пермь сынлы сәнгать галереясына һәдия иткән. ТР дәүләт сынлы сәнгать музее фондында да бу останың егермедән артык сынлы сәнгать һәм графика әсәре саклана. Ф.Г.Әминевның картиналары М.В.Нестеров исемендәге Башкорт дәүләт сынлы сәнгать, Оренбург сынлы сәнгать музейларында, ТР Милли музеенда, Г.Тукай дәүләт әдәби-мемориаль музей комплексында, Пермь дәүләт сынлы сәнгать галереясында, А.Нәваи исемендәге дәүләт әдәбият музеенда, Санкт-Петербургның дин тарихы музеенда һәм Россиядәге һәм чит илләрдәге шәхси тупланмаларда да бар.

«Әтием гомер буе бөек шагыйребез Габдулла Тукай әсәрләрен үз итте, татар милли темасына алынып, гомер буе шушы юнәлештә булды һәм нәкъ шушы эшләре өчен ул 1979 елда Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясенә кандидат итеп тә теркәлгән иде, ләкин премия бирергә берникадәр генә вакыт кала аңа нинди карар кабул ителәчәге хакында әйттеләр. Ул елны әлеге премияне концерт программалары өчен яшь җырчы Р.Ибраһимовка тапшырдылар. Шушы хәбәрне ишеткәч, әтием нык чирли башлады һәм берничә елдан соң үлеп тә китте. Бик кызганыч, ә бит безнең әти бу премияне алырга бик лаек иҗатчы иде», – диде Фәйзулла Әминев әңгәмә барышында. Талантлы рәссамыбыз Ф.Г.Әминев кандидатурасы 1980-1984 елларда да шушы мәртәбәле премиягә янә тәкъдим ителгәндерме?.. Мин бу хакта аның улына сүз катмадым, чөнки бу «Шушы аяныч хәл әтинең башына җитте дә инде...», – дигән нәсел дәвамчысының күңел ярасын зурайту гына булыр иде...

Татарстан Мәдәният министрлыгы әлеге гаять дәрәҗәдә талантлы рәссамыбызның иҗатына багышланган бинһаә яхшы кәгазьле, калын китап нәшер итүгә алынырга тиештер, дигән өметтә калабыз. Моңа ихтыяҗ бар һәм булачак та! Һәм Ф.Г.Әминевның ничәмә-ничә буын сокланган күп кенә әсәрләреннән торучы яңа күргәзмәсен күрер көннәр дә килеп җитсә, тагын да яхшырак булыр иде...

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

● Ф.Әминевның Тукай әсәрләренә иллюстрацияләре.

Мәдәни җомга
24 ноябрь
№46, 2023

МИНЕМ

1960 елның 9 октябрe. Кичке тугызда Украинаның Хмельницки шәһәре аэродромыннан хәрби транспорт самолеты (ТУ-104 нең хәрби модификациясе) күтәрелә. Бортта алты кеше: командир В.Иванов, икенче пилот В.Хомяков, бортинженер, штурман, радист һәм бер десантчы старшина. Максатлары – мөһим задание белән җибәрелгән десантчыларны хәрби частька алып кайту. Самолет очып китәр алдыннан җентекләп тикшерелгән. Һава шартлары уңай. Берминди хәвеф-хәтәр көтелми кебек. Әмма...

Илле метр биеклектә һава лайнеры, кинәт өермәгә эләгеп, идарәсен тулысынча югалта. Өермә кузгала. Акрынлап аска таба төшеп барган очкычны куе тузан, балчык, кирпеч кисәкләре, түбә-тамыры белән йолкынган агач-куак сырып ала. Азаплана торгач, радист килеп туган хәл турында идарә пультына хәбәр итүгә ирешә. Аста карга төренеп утырган Тартаки авылы йортлары шәйләнеп кала. Сүз дә юк: экипажның беренче бурычы – самолетны мөмкин кадәр горизонталь тоту һәм торак пункттан ераккарак алып китү. Бөтен команда штурвалга ябыша. Гаять зур көч куеп, техника «корсагына» утыртыла. Лайнер 2-3 чакрым чамасы иген кырын сөреп бара. Команда авыр тән җәрәхәтләре ала: аяк-куллар, умырткалар сына һәм баш миләре селкенә... Командование ашыгыч рәвештә коткаручылар командасы юллый. Ләкин 4 кенә кеше исән кала – экипаж командиры капитан В.Иванов, икенче пилот В.Хомяков һәм аларны куркынычсыз урынга өстерәп киткән санитарлар. Калган экипаж, коткаручылар белән бергә, лайнер шартлау сәбәпле, һәлак була. Шартлаудан барлыкка килгән дулкын нәтиҗәсендә якындагы авылның барлык йорт тәрәзәләре коелып төшә, күп кенә өйнең түбәсе кубарыла...

Исән калганнар сүзенә башта ышанмыйлар. Соңрак, «кара тартма»га язылып калган мәгълүматларны анализлагач кына, шик калмый.

Хмельницки шәһәре госпиталендә авырулар янына СССР Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары А.Косыгин килә һәм биш кешенең Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителүе турында хәбәр итә. Ләкин лаеклы бүләк каһарманнарга 40 елдан соң гына килеп ирешә. Виктор Хомяков СССР Югары Советы Президиумының Почет грамотасын һәм «Алтын Йолдыз» медален 2001 елда, Урал-Идел буе хәрби округы вәкиле кулыннан, Магнитогорск шәһәре хәрби комиссариатында ала. Россия Федерациясе оборона министры Боерыгы нигезендә, аңа, майор һәм подполковник дәрәҗәләрен «сикертеп», «полковник» дәрәҗәсе бирелә. Ни кызганыч, Ленин ордены тапшырылмый. Мондый бүләккә командир гына лаек була, дигән сылтау табыла. Гәрчә бу гамәл «Советлар Союзы Герое турындагы Положение»га каршы килсә дә.

Гаҗәп хәлләр моның белән генә дә бетмәгән икән әле. Кыю очучы бүгенге көнгә кадәр Геройга тиешле ташламалардан файдаланмый! Чөнки, Чаллыда яшәсә дә, хәрби исәптә Магнитогорск шәһәрендә тора икән. Соңарып бүләкләнүенең сәбәбен дә шуңа сылтаганнар: Виктор Афанасьевичны, янәсе, түрәләр таба алмыйча интеккән.

* * *

Виктор Хомяков 1934 елда Чиләбе өлкәсенең Магнитогорск шәһәрендә туган. Әтисе Афанасий Филиппович (1876 елгы) Октябрь революциясендә, Гражданнар сугышында катнашкан. 1934 елда кулаклар тарафыннан үтерелгән. Әнисенең ерак тамырлары татар милләтенә барып тоташа. Әзербәйҗанда туса да, саф татар исемле Алсу Гариф кызы (1910 елгы) гомер буена Апшерон районында сыер савучы булып эшләгән һәм 1983 елда вафат булган.

Хомяковлар гаиләсе Уралда, Магнитогорск шәһәрендә яши. Сугыш башланыр алдыннан Виктор туганнан-туган апаларына – Гомель өлкәсендәге Круки авылына күченеп килгән була. Шунда беренче сыйныфка укырга керә. Сугыш башлангач та авылга нимес гаскәре бәреп керә. Викторлар яши торган йортка бер нимес офицеры урнаша. «Обер-лейтенант үзе әлләни усал кеше түгел иде, – дип, хәтер йомгагын сүтә Виктор Афанасьевич. – Балаларны конфет-печенье белән сыйлый, ә аның хатыны дөньядагы иң усал кеше булып тоела иде».

«Югары раса» вәкиле саналган фрау камчысын бер дә кулыннан төшерми. 1943 елның кышында партизаннар аның башына җитә. Бу вакыйгадан соң обер-лейтенант кайгыга бата һәм фронтка җибәрүләрен сорап гариза яза. Ә бераздан авылга карательләр отряды килеп җитә. Иң беренче итеп, полицайлар, шул ук авыл кешеләре (!) партизаннар отряды командиры Панас абыйның (Афанасий) кызын паяльник белән көйдереп үтерә. Балаларның күпчелеген урманга качырып өлгерәләр. Калган барлык балалар һәм аналар концентрацион лагерьга озатыла...

Виктор, дошман оккупациясендә җан асрап, 1941-1943 елларда Сидор Ковпак җитәкләгән партизан берләшмәсенә керүче Панас абый отряды сафында байтак хәрби операцияләрдә катнаша. Өч-дүрт өлкән кеше һәм ике-өч баладан торган төркем ясап, нимес тылында йөриләр, эшелон һәм күперләрне шартлаталар, дошманны кыралар... Ә бер атыш вакытында, 1942 елда малай авыр яралана (төрле елларда аның аягыннан алты данә кыйпылчык алынган).

Чираттагы рейдка чыккач, алар төркеме чолганышта кала. Нәни партизаннарны кулга алып, Освенцим (Польша) концлагерена озаталар. Яшь Хомяковның тәненә кызган тимер белән 92920 саны сугыла. Ике атнадан әсир балалар (җиде җан) «сатып алучы» – урта яшьләрдәге бер нимес бюргеры кулына күчә. Виктор Афанасьевич хәтеренә «Лунатик Бауэр» кушаматлы булып кереп калган алпавытның кызы Эльза да әтисе кебек явыз садист була. Әсир балалар аның Мюнхен янындагы фермасында җан асрый. Кол хезмәтенең бөтен газабын үз җилкәләрендә татырга туры килә – тиз арада ачлыктан күбенгән капкорсаклы, тире һәм сөяктән генә торган «тере скелет»ка әвереләләр. Хуҗа әсирләр рационын һәрвакыт энә күзеннән үткәрә, пычкы чүбеннән һәм камылдан пешерелгән ипи генә ашата.

«Карл Бауэр үзе дә, аның кызы Эльза да, бакчада уңыш җыйганда кишер яки кәбестә алып каба күрмәсеннәр, дип безне һәрдаим күзәтеп торды, – ди Виктор Афанасьевич, ул чорларны кабат хәтерендә яңартып. – Ул яшелчә уңышын шәһәр кибетләренә илтү аеруча газап була иде: дилбегә тоткан килеш, арбада баскан көе барырга кирәк. Чүгәләү, утыру катгый рәвештә тыела. Аты да ят кешеләрне таныган кебек. Без якынлашуга, тешли, тибенә башлый. Бервакыт шәһәр кибетенә 20 литр сыешлы зур пыяла шешә илтә киттем. Май алып кайтырга идеме икән. Бераз баргач, ат, гадәтенчә, дулый башлады. Янәшәдән атлап барам. Тынычландырып кына булмый бит! Ботыма шундый каты итеп китереп типте – 5-6 метрга очтым. Ярый әле шешәне кочаклаган идем. Ватылса, баш беткән иде...»

Ярты ел шулай газаплангач, Виктор, Николай (Канола) исемле чегән малае белән, бюргер фермасыннан качып китә. Тик мондый кыяфәттә ерак китеп буламы соң?! Тиздән алар тотыла һәм даны чыккан хәтәр Дахау концлагерена озатыла.

ОЧАСЫМ КИЛӘ...

кебек (Германиядә яшәвенә карамастан!) чапан, түбәтәй, хром читек киеп, кәкре таякка таянып йөргәнлеген хәтерли: «Аңа безнең хуҗа: «Шәрифулла әфәнде», – дип дәшә иде бугай. Хуҗабыз әйтүенчә, төрле шәһәрләрдә, концлагерьларда булып, андагы татар тоткыннары белән танышып, булдыра алганча ярдәм итеп йөри торган милләт җанлы әфәнде иде ул...» Виктор Афанасьевичның бу истәлекләрен тыңлап утырганда, ни өчендер, атаклы Шәфи Алмас образы күз алдына килеп баса. Кем белгән?..

Сугыш тәмамланганда Виктор Афанасьевич әле шунда – Америка гаскәрләре зонасында була. Туган якка кайтырга теләгәнен белгәч, союзниклар да, хуҗасы Валь-Вәли дә: «Кайтырга уйлама, утыртачаклар», – дип үгетләп карыйлар. Ышанмый шул бала...

Яшь әсирләр төркеме Брестка

Анда аларны 23 нче блок-сарайда тоталар. Бер сарайда – 200 кеше! Ике катлы агач ятакта йоклыйлар, башлыча таш чыгаруда эшлиләр. Шул чак истәлеге – әле бүген дә аяк-кулларында аермачык күренеп торган дагаланган нимес итеге эзләре.

Лагерьда ул Николайдан чегән телен өйрәнә, олырак әсирләрдән урыс теленнән дәресләр ала.

Ел ярым чамасы үткәч, концлагерьга яңа «сатып алучы» килә. Яңа хуҗа, гөнаһ шомлыгы, нимес фамилияле яшь кенә татар кешесе булып чыга! Валь Фридрих кебек исендә калган (исемен Вәли дип фаразлый). Виктор Афанасьевичның әйтүенә караганда, хуҗаның этисе Казан татары, Беренче бөтендөнья сугышында әсир төшеп, Германиядә яшәп калган икән. 7-8 баладан торган төркем («Арабызда Казаннан Чулпан исемле татар кызы да бар иде», – дип искә ала В.Хомяков) бөтенләй икенче мохиткә килеп эләгә. Хуҗа аларны үз балаларыдай тәрбияли...

«Ни хикмәт, бу гаиләдә яшәгәндә, кайдадыр безнең туган илдә, башка дәүләтләрдә канкойгыч сугышлар барганлыгы бөтенләй онытылган кебек була иде. Кай тарафка карама – купшы киенгән байлар, чыр-чу килеп уйнаган балалар... Безнең хуҗа янына да кунаклар еш килә иде. Кич утырып безнеңчә – татарча гәпләшәләр...»

Әлбәттә, балаларга яңа шартларга ияләшү җиңел булмый. Ризыкны да чамалап кына ашарга мәҗбүрләр – юкса, ачлыкка ияләшеп килгән нәни организмга мул ризык авырга

№ 37 (21 сентября 2016 года)
ЧАС ИНТЕРВЬЮ
ВЛЮБЛЁННЫЙ В НЕБО ПОЛИГЛОТ
«МОСКВИЧ-401» И ВОЕННАЯ АКАДЕМИЯ
АВТОПОРТРЕТ

туры киләчәк! Хуҗа кеше яңа эшчеләре белән озаклап сөйләшеп утыра, балаларның кайсы яклардан булуы, туган-тумачалары кем икәнлеге хакында кызыксына. Хуҗа аеруча Чулпан белән татарча аралашырга ярата. Үзе Германиядә туып-үскән булса да, ата-бабаң Ватанына, туган туфрагына битараф калып булмыйдыр шул...

«Безгә кулдан килердәй эш кенә бирә, үз балаларыдай ашата иде...» – дип, Виктор Афанасьевич фашистик Германиядә мондый кешегә тап булуны могҗизага тиңли.

Алар хезмәт иткән нимес фамилияле татар, аның янына килеп йөргән милләттәшләребез турында да беләсе килә. Ләкин еллар үзенекен иткән: 10 яше дә тулмаган вакытта булган вакыйгалар Виктор Афанасьевич хәтерендә бик аз калган инде. Шулай да бер олы гына кешенең, элекке татар байлары

китерелә, «нимесләргә хезмәт иткән» малайны «Ватанга хыянәт иткән өчен» 10 елга ирегеннән мәхрүм итәләр!.. Күпмедер күләмдә аңа бәхет елмая дияргә мөмкин – нибары 5 ел гына утыра. Бу чор эчендә аңа ГУЛАГның төрле лагерьларында булырга туры килә: Чиләбе өлкәсенең Копейск шәһәрендә, Ванино, Советская Гавань, Петропавловск-Камчатски, Чукотка, Сахалин һәм Колымада... Ни гаҗәп, (бәлки, балалыгы белән аңлап та бетермәгәндер) совет лагерьларында шартлар яхшы иде, дип искә ала Виктор Афанасьевич: аларны дүрт сәгать эшләтәләр, шул кадәр үк мәктәптә шөгыльләнәләр. Тоткыннар ике ашханәдә туклана: бушлай һәм түләүле.

– А.Солженицынның «Архипелаг ГУЛАГ» дигән язмасын укымаган кеше сирәктер. Анда язылганнарның яртысыннан артыгы ялган, уйдырма! Кешене алай ук җәберләгәннәрен күргәнем дә, ишеткәнем дә булмады. Яшәү һәм эшләү өчен бөтен шартлар да диярлек бар иде. Минем кебек яшьләргә дә, өлкән «политический»ларга да. «Вертухай»лар да кешене мыскылларга гына тора иде, диясем килми. Безнең надзиратель, мисал өчен, безгә кул белән кагылып та карамады. Хәтта аты-юлы белән пычрак сүзләр дә әйтми иде. Көн саен диярлек, безне үз ирегебездә калдырып, шәһәргә барып йөрде. Гадәттә, безне җыя да: «Мин киттем, тәртип булсын...», – дип кенә әйтә торган иде. «Сез югында качсак?» – дибез тегеңә. Көлә генә: «Качып карагыз, кая барырсыз икән?» Дөрестән дә, әйләнә-тирә – үтеп булмаслык калын урман, диңгез, төпсез сазлыклар... Хәзерге армиядә гауптвахта булган кебек, анда да карцер бар иде. Тик карцерга бит тәртип бозган өчен генә ябалар. Сәбәпсезгә каныкмасыннар дисәң, «субординация»не сакларга кирәк, үзеңнән өлкәннәр сүзеннән чыкмаска. Ашарга да җитәрлек. Түләүле ашханәдә дә, бушлай ашата торганында да кисмәк белән тозлы балык, икмәк, шикәр болгаткан су була иде. Теләгән кадәр аша. Башка төрле ризыктан да өзмәделәр, шөкер...

– Кем белә, бәлки миңа гына шулай җайлы туры килгәндер? – дип куйды Виктор Афанасьевич.

Лагерьда хөрмәтле кешеләр исәбендә йөргән Виктор Афанасьевич читек каю белән шөгыльләнә, заказлар һәрвакыт күп. Ул Советская Гавань лагерендә соңрак Сталинның шәхси боерыгы белән иреккә чыгарылган Иван Юмашев белән таныша. Атаклы диңгезче, адмирал, Советлар Союзы Герое, СССР Хәрби-диңгез флоты Башкомандующие, Хәрби-диңгез академиясе башлыгы И.Юмашев, иреккә чыккач, Викторның әнисе Алсу Гариф кызын эзләп таба һәм 1952 елда егетнең азат ителүенә ирешә.

Совет лагерьларында чакта Виктор вакытын заяга үткәрми: күп укый, бик яхшы билгеләргә генә кичке мәктәпне тәмамлый. Үрнәк укучының рәсеме Мактау тактасына куела. Суд органнары карары нигезендә, ул хаксыз хөкем ителгән дип табыла. Иреккә чыгарылган яшь тоткынга, компенсация рәвешендә, «Москвич 401» автомобиле һәм 65 мең сум акча бирелә. Шоферлар әзерләү курсында укып, машина йөртү хокукы да ала әле ул. Советская Гаваньнан Магнитогорскига, аннан әнисе янына, Әзербайҗанга үз машинасында кайтканын гыйбрәт итеп сөйли:

– Әни янына кайттым да: «Менә, – дим, – әни, машинаны синең исемгә яздырдым». Әнинең коты очты. «Кайдан алдың? Урладыңмы?» – дия-дия кара кайгыга батты. Дөрестән дә, ГУЛАГтан шулкадәр акча, машина алып кайттым, дигәнгә кем ышансын?! Тиешле кәгазьләрне күрсәткәч тә тынычланмады әле. Совет Армиясенә чакырып повестка килгәч тә, миңа күрсәтергә куркып йөргән. Бөтенләй язу танымый иде шул. Почтальон «повестка китердем», – дигәч, бөтенләй куркып калган. Билгеле сәбәпләр аркасында, кешеләргә дә укытмаган...

1953 ел. В.Хомяков Совет Армиясе сафларына чакырыла. Яшь сугышчы курсын Винница өлкәсенең Жмеринка шәһәрендә, 05815 нче хәрби частьта үтә. Яшь солдатның сәләтен күреп алган җитәкчелек аңа Н.Жуковский исемендәге Хәрби-һава академиясенә керергә тәкъдим итә. Академияне 1959 елда тәмамлап, Виктор Афанасьевич лейтенант дәрәҗәсе һәм икенче класслы очучы белгечлеге алып чыга. Академиядә укыганда спорт белән актив шөгыльләнә. Ул – самбо, каратэ буенча спорт мастеры, 1955 елда СССРның халыкара класслы спорт мастеры югарылыгына ирешә. Тагын бер ел үткәч, үз авырлыгы буенча Россия чемпионы исемен яулый.

В.Хомяков икенче класслы очучы буларак хезмәт итә самолет Ровно, Львов һәм Украинаның башка шәһәрләренә, Свердловск өлкәсенә оча, йөзәр кешедән торган десант илтә.

Тик озак очарга язмаган икән шул Виктор Хомяковка. 1960 елның 9 октябрендә әле тиешле биеклеккә менеп тә өлгермәгән очкыч җиргә кире төшәргә мәҗбүр була һәм шартлый...

* * *

Бу шәхеснең ихтыяр көченә гаҗәпләнәсе генә кала. Ел ярымнан артык Хмельницки шәһәре госпиталендә, Мәскәүнең Н.Бурденко исемендәге клиникасында ята ул. Беренче төркем инвалидлык алгач та сынмый, сыгылмый. Уралга кайта. Башта Магнитогорск металлургия комбинаты канцеляриясендә хезмәт итә, аннан корыч коючы ярдәмчесе, 35 нче мартен мичендә корыч коючы булып эшли. Сменага 900 тонна корыч коя. Металлурглар арасында татарлар күп эшләгәнлеге исендә калган. Соңрак Свердловск шәһәрендәге Урал политехника институтына укырга керә һәм 1974 елда аны уңышлы гына тәмамлый. Бер үк вакытта күпсанлы геологик экспедицияләрдә катнаша.

(Дәвамы киләсе санда).

Билал КАНЕЕВ,
Амур ФӘЛӘХ.
Чаллы.

Милли хәрәкәт

Буа районының Яңа Чынлы авылында туган, Казан авиация институтының самолетлар төзү факультетын тәмамлаган һәм илдә үзгәреш җилләре исә башлангач, Чаллы каласында оешкан милли хәрәкәт җитәкчеләренең берсенә әйләнгән ***Фаикъ абый Таҗиев*** *белән даими очрашып торабыз. Ничә гасыр буе татар халкына каршы алып барылган пычрак сәясәт, аеруча аның җанисәп алдыннан отыры көчәеп китүе һич тә тынгы бирми. Җитмәсә, гаять дәрәҗәдә милли җанлы көрәштәшебез әле хәрби училищеда укыган чагында ук татар халкының каһарман улы Петр Гаврилов белән элемтәдә яшәгән Хәниф Әхкәмов – уртак дустыбыз да. Фаикъ абый белән әңгәмәбез менә шул җәһәттән башланды.*

– Хәниф Башкортстанның Балтач районындагы туган авылы Көндәлегә, төп нигезләрендә хуҗасыз калган йортларына еш кайтып йөрде. Чаллыдан сәфәргә чыгып киткән саен, авылдашларына күчтәнәчкә дип букчаларга татар китаплары, газета-журналлар төяп китте. Тарихи йортлары урынын сквер төзү өчен бирүе, әти-әниләреннән сакланып калган мирасны – йорт җиһазларын авыл музеена тапшыруы, һичшиксез, күркәм гамәл. Тик менә җанисәп алдыннан, алардан сорап та тормыйча, тоталар да сандык, гөбе, кашна кебек күз карасыдай сакланган әйберләрне район үзәгендә Уфадан торып оештырылган «Мишәр үзәге»нә алып китәләр, әле хәтта сандыкта «мишәр бизәкләре» табып юаналар. Бу гыйбрәтле хәлләрдән соң, Хәниф гаилә байлыгын кире кайтаруларын таләп итте һәм шул теләгән тормышка ашырмыйча тынычланмады. Аның ягыннан бу дөрес гамәлме?

– Башкача ничек булсын! Хәниф дустыбыз үз гаиләләре ядкәрләрен ихлас күңелдән музейга дип тапшыра, ә заказ буенча пычрак сәясәт үткәрүчеләр, бу тарихи байлыкны татар милләтен бүлгәләү өчен уйлап чыгарылган явыз ниятләрдә файдалана. Хакимиятләр безнең мәгарифне, мәдәниятне юк итү, милләтнең тамырын корыту, тәмам юкка чыгару өчен төрле пычрак алымнар куллана, күрше республиканың Балтач районындагы әлеге вакыйга – шуның типик бер чагылышы. Ни аяныч, татар халкын бүлгәләргә, таркатырга тырышулар аеруча татарофоб Ильминский чорларыннан бирле алып барыла. Яңа гасырда бу яман идеологиянең төп илһамландыручылары – Россиянең элеккеге мәдәният министры Владимир Мединский белән Мәскәүдәге этнология һәм антропология институты директоры Валерий Тишков. Үзебезнекеләр арасында да дошман тегермәненә су кояргa атлыгып торучылар аз түгел. Бер мәлне Мордовиядә яшәүче Камил Тангалычев дигән урыс телендә язучы активлашып китте. Анычча, Татарстаннан читтә яшәүче татар-мишәрләргә Казан ягы йогынты ясарга тиеш түгел, янәсе, бу фәкать Россия мәнфәгатендә һәм вәкаләтендә икән. Иҗаты белән дә әлләни җәлеп итә алмаган милләттәшкә, хаталанауын дәлилләп җавап язарга туры килде. Тик безне бүлгәләү мөмкин түгел, чөнки тарих шаһит: чыгышлары белән Чистайдан һәм Арча-Әтнә яклырыннан булган Фатыйх Әмирхан белән Габдулла Тукайның дуслыгы – шуңа саллы мисал. Безнең якта да бүлгәләнү галәмәте бөтенләй юк. Үзем күрше Шәйморза авылындагы, Габдулла Рәхимкулов, Ренат Таҗетдинов шикелле күренекле шәхесләр укыган мәктәпне тәмамладым, гәрчә беркайчан да «мин – мишәр», «син – татар», дип сагашучыларны очратмадым. Гомумән, безне ике халык дип раслау өчен нигез юк. Әмма милләт дошманнары бик мәкерле, безгә бу җәһәттән бик сак булырга кирәк.

– Шөкер, милләт дошманнарының әлегәчә үз теләкләренә ирешә алганы юк. 2002 елда үткән җан исәбен алу вакытында үзләрен «мишәр милләте» дип аерып күрсәтүчеләр ярты меңнән артмады. Шул мәкерле сәясәт идеологларының берсе Тишков, бу хәлгә аптырап: «Мин берничә йөз мең кешенең мишәр булып язылачагын көткән идем!» – дип белдерергә мәҗбүр булды. Шуннан соң, 2010 ел белән чагыштырганда, соңгы җанисәптә үзләрен «мишәр» дип белдерүчеләр саны нибары бер кешегә артты һәм андыйларның саны 787 гә җитте, шуларның 374 е – Башкортстанда.

– Әлбәттә, безне бүлгәләргә омтылучыларның уңышка ирешә алмаулары сөенечле хәл, әмма тынычланырга ярамый. Авылда үзебезне татар дип үстек, татар булып яшәдек, бернинди аерымлыклар да күрмәдек, Казанга баргач кына «мишәр» икәнемне сиздерделәр. Бездә фәкать диалект аермасы гына бар, әдәбиятыбыз – бер, мәдәниятебез – бер, телебез – бер, яшәү рәвешебез – бер! Без, һичшиксез, бер бөтен татар милләте вәкилләре.

– Без Фаикъ Таҗиевны татар милләтен, аның асыл мәнфәгатьләрен яклап, татар һәм рус телләрендә дистәләрчә мәкаләләр язган автор буларак та беләбез. Югары техник белем алган кешегә андый омтылыш каян килә икән?

– Язмалар да язарга хирыс булганнан, йә язасы килеп, «кул кычытып» торганнан тумый иде. Сәбәбе – татарны массакүләм мәгълүмат чараларында гомуми кимсетү, татарча урта белем бирүне бетерү һәм бөтән тискәре күренешләргә түзеп тора алмауда. Шулай ук, бик шома язмасам да, милләт язмышына кагылышлы көндәлдә төенләнгән уй-фикерләрне халкыбызга җиткерәсем килде. Милләт дошманнарының мәкерлеген фаш итү һәм аларның безнең халкыбызны каралтып, тарихыбызны бозып матбугатта чыгарган язмаларына каршы җавап урысча бирү ихтыяҗы туа бит. Гадел булмаган милли сәясәт үткәрүгә ризасызлыгымны белдереп, ил, республика җитәкчелегенә күп мөрәҗәгатьләр белән дә чыгарга туры килә. Татарның үткәнен бозып, Россиянең һәм рус халкының ялган тарихын чынбарлык итеп күрсәтергә тырышуларны да игътибарсыз калдырып булмый. Әлбәттә, болар өчен күбрәк белергә, тарихны мөмкин кадәр җентекләбрәк өйрәнергә кирәк. Олыгая төшкәч кенә, 2010 елдан башлап, «Звезда Поволжья» газетасына мәкаләләр язарга тотындым. Барлык мәкаләләремнең саны илледән артып китә.

– Владивостокта Марксизм-Ленинизм университетын тәмамлаган коммунист, Чаллыда төзелеш идарәсендә төзелеш механизмы участогы башлыгы, аннары идарә башлыгының икътисад буенча урынбасары, комсомол пропагандисты ничек итеп милли сәясәттә яшәп килүче гаделсезлеккә игътибар итә башлады соң?

– КАИны тәмамлагач, Казанда калу мөмкинлеге дә бар иде, әмма без дустым Рәфыйк Җаббаров белән башка юнәлешне сайладык. Яшь чак, романтик рух көчле, күңел еракларга омтыла, яңа җирләр күрәсе, тайгаларда йөрисе килә һәм без, үз теләгебез белән, Ерак Көнчыгыш таралфларына ук китеп бардык. Приморье краендагы Арсеньев каласында урнашкан авиазаводта мин инженер-технолог, ә дустым Рәфыйк – Антонов конструкторлык бюросы филиалында инженер-конструктор булып эшли башладык. Без килгәндә андагы «Прогресс» заводында Ан-14 самолетлары җыялар иде. Яшьлек хыялымны тормышка ашырдым: тайгага походларга йөрдем, планер спорты белән дә мавыгып киттем. Владивостоктагы Марксизм-Ленинизм университетында читтән укып, комсомол пропагандисты булып чыктым. Мин үсмер чактан ук татарның милли хокукларына каршы үткәрелгән гаделсезлекләрне белеп торсам да, аның асылын, нигезләрен тәгаен аңлап та бетерми идем һәм бу сәясәтне уңай якка үзгәртү ысуллары барлыгын да күз алдыма китерә алмый идем әле.

– Ул вакытта партиянең генераль секретарьләре үз нотыкларында коммунизмга якыная баруның билгесе итеп буйсындырылган милләтләрнең ничә проценты урыс телен үзенең ана теле итеп тануын китерә торган иде.

– Ни кызганыч, Россиянең бүгенге түрәләре урыслаштыру ысулын тамырыннан үзгәртеп, татарча белем биргән мәктәпләрне юк итү өчен, инде урысчадан татарчага күчереп бастырылган дәреслекләрне дә гамәлгә куймый, шул юл белән (идентификацияләү), милли белем бирү системасын юкка чыгарып бара. Югыйсә, мин үзем дә бәләкәй генә татар авылы Яңа Чынлыда җидееллык татар мәктәбен бетергәч, Иске Шәйморза урта мәктәбендә укыдым. Мин укыганда (1957-1960) анда ике татар классы, сигез укучыдан торган бер урыс классы балаларга белем бирә иде. Ишетүемчә, хәзер Иске Шәйморза мәктәбен дә тулаем урысча укытуга күчергәннәр.

Ерак Көнчыгыштан Үзбәкстанга күчендем, анда татар кызына өйләндем. Миннән бер елга алданрак Татарстанга әйләнеп кайткан Рәфыйк дустым чакыртуы буенча Чаллыга кайтым да, Төзелешне механизацияләү идарәсендә эшкә урнаштым. Чаллыда да эшче яшьләрне «сәяси агарту» алып барырга туры килде. Моның өчен күп нәрсәдән хәбәрдар булырга, дөньядагы сәяси һәм иҗтимагый хәл-вакыйгаларны белеп торырга кирәк бит. Кая карама – дөнья буйлап милли-азатлык көрәше бара. Мәсәлән, Африкада Ангола белән Мозамбик Португалия колонизаторларыннан котылу өчен көрәшә, Азия һәм Латин Америкасы илләрендә дә шундый күтәрелешләрне тынып тормый. Әлбәттә инде, СССР азатлык даулаучы халыкларның яклый, аларга булыша, юнәлеш бирә, чөнки төп максат – бөтен дөньяда социализм урнаштыру. Әйтерсең лә, үзебездә милли проблемалар юк, барысы да ал да гөл. Нәшер ителгән Ленин хезмәтләрен укыйм да үзебездәге милләтләргә карата үткәрелүче сәясәт белән чагыштырам. Күрәм, Ленин бабай күрсәткән юл белән барабыз дип лаф орсак та, без ул юлдан шактый читләшкәнбез икән. Читләшү генә түгел, милли мәсьәләләргә үтә тискәре караштагы Сталин, аннан соң Хрущев идарәсе чорында Суслов безне бөтенләй башка юнәлештә алып киткән. Ленин исә үткән гасыр башыннан ук «махровый» шовинизмга каршы көрәшкән, барлык милләтләрнең тигез хокукка ия булырга тиешлеген алга сөргән. Шул җәһәттән, аның 1914 елның 12 декабрендә Лондонда «Социал-Демократ» газетасында чыккан «О национальной гордости великороссов» исемле мәкаләсе игътибарга лаек. Шаккатмалы хәл, әле 1903 елда ук, РСДРПның Англия башкаласында үткән II съездында кабул ителгән программасының 8 һәм 9 нчы пунктларында Россия империясендә яшәүче барлык халыкларның үзбилгеләнү һәм туган телләрендә уку хокуклары гарантияләнә, диелгән. Бәлки шуңадыр, Сталин Россия карамагында яшәүче мөселманнарның уку-язуын башта гарәпчәдән латин хәрефләренә, аннары урыс графикасына күчерсә дә, ана телләрендә белем бирүче мәктәпләрне гамәлдән чыгармый торган.

– Без кайчан Ленин бабай күрсәткән юлдан читләшкәнбез соң?

– Партиянең генераль секретаре итеп сайлангач, Иосиф Сталин хәйләкәр алымнар белән партиянең политбюросын үз коралына әверелдерә. Шуңа күрә Ленин милләткә тигез хокуклар бирүне күз уңында тоткан үз концепциясенең сакланмаячагын, Сталинның тупаслыгын һәм бөтән тискәре якларын искә төшереп, генераль секретарь постына бүтән, тәртиплерәк коммунистны сайларга тәкъдим итә, ләкин авырып яткан юлбашчының хаты вәзгыятькә йогынты ясый алмый. Аның изоляциядә калуына Сталин гаепле була. 1918 елның августында оештырылган коралы һөҗүмнән соң Ленинның сәламәтлеге какшый, 1922 елның май аенда авыруы көчәя. Көрәштәшләренең күбесе яңа «юлбашчы» ягына авышкан, җитмәсә, яралангыннан соң, РСФСР Халык комиссарлары советы рәисе ва-

ветераны

зыйфасын вакытлыча башкарып торган Яков Свердлов серле рәвештә үлеп китә. Сталин төрле юллар белән, Ленинның Горкида төп караучысы булып калган хатыны Надежда Крупскаяны башка бурычлар йөкләп ике мәртәбә: башта бер атнага, соңрак, тагын бер айга Мәскәүгә чакырткан. Күпмедер дәрәҗәдә Ленинның терәге булып килгән Инесса Армандны Нальчикка «ялга» озаталар, ул аннан әйләнеп кайта алмый, кисәк кенә вафат була. Нәтиҗәдә Ильич тулысынча чекистлар карамагында кала. Шул шартларда да ул үз фикер-карашларын көрәштәшләренә җиткерергә тырыша. 1922 елның декабреннән 1923 елның мартына кадәрге чорда авыру әйтеп торганнарны стенографистлар Володичева белән Фотиева язып барган. «Съездга хат» исеме белән тарихка кереп калган һәм Ленин васыятьләре буларак кабул ителгән шул язмаларның берсендә дөрес милли сәясәт алып бармаучы, тәкәббер һәм дорфа Сталинны партиянең генераль секретаре булып торуы тискәре нәтиҗәләргә китерү ихтималлыгын искәртә. Тагын бер хатында милләтләрне союздаш һәм автоном республикаларга бүлүнең хата булачагын кисәтә. Интригалар кору һәм корал кулланып банк басуга да маһир Сталин авыру Ленинның партия съездында каралсын дип язган: «Как нам реорганизовать Рабкрин?» язмасын «Правда» газетасының гомуми тиражына кертмәү максаты белән бу номерның бер данәсендә бастырып чыгарттыра да, шуны Ленинга укырга бирдерә... Янәсе, язмаң «Правда» газетасында басылып чыкты. Ә ул вакытта «Рабкрин»ның җитәкчесе Сталин үзе булган. Большевиклар партиясенең эчке эшчәнлеген Н.Хрущев кушуы буенча җентекләп өйрәнгән тәҗрибәле коммунист Ольга Шатуновская бу хакта махсус протоколда да теркәп калдырган.

– Ничек милли хәрәкәткә кереп киттең, Фаикъ абый?

– Яшьтән үк үз милләтебезгә карата тискәре мөнәсәбәт тудырылуын күреп үстем, ә инде Ленин хезмәтләре белән җентеклəбрәк танышкан саен, аның сәбәпләрен ныграк төшенә бардым. Милли көрәшкә китергән төп сәбәпләрнең берсе – РСДРПның II съездында кабул ителгән программа һәм Ленин хезмәтләре белән танышу нәтиҗәсе. Чынлап та, милли тигезлек нигезләре нәкъ менә аның тәгълиматларында ярылып ята. Аларны санга сукмау, бер ясалма совет милләте әвәләү шаукымы Чаллы каласы өчен дә хас күренешкә әйләнгән иде. Татар мәктәпләре, татар бакчалары юк, язма такталар фәкать рус телендә генә, транспортта үз туган телеңдә сөйләшү кузгатсаң, «бөек» милләт вәкилләре шундук ысылдаша башлый. Исем өчен генә ябыштырылган Мулланур Вахитов исемендәге соңгы татар мәктәбе бинасыз калган дип ишеттек. Бу турыда баласы шунда укыган бер инженер әйткән иде. Гаиләмдә ике кыз белән бер малай үсә иде, аларны туган телебездә, динебез кушканча тәрбиялисем, укытасым килә. Ярый әле, тәхеткә Горбачев килеп, дөньялар үзгәреп китте. Әмма, барыбер, Россия җирлегендә искелеккә берегеп каткан җәмгыятьне җиңел генә уңай якка үзгәртү мөмкинлеге ачык күренми иде.

Чаллыда милли хәрәкәт оеша башлавын һәм булачак көрәштәшләрем турында хәбәрдар булмаган көе, беренче адымнарымны ясадым: Татар һәм Башкорт атом станцияләре төзелешенә каршы зур плакат яздырып, аны ГЭС бистәсендәге, Җиңү һәйкәле каршындагы 5 катлы йортның түбәсенә менгереп элдем. Аннары ул плакатны КамГЭСта узган зур бер җыелыштә катнашучылар укысын дип, Геройлар аллеясы каршына бәйләп куйдым. 1988 елның сентябрендә үзебезнең төзелеш идарәсендә үткән партия җыелышында, сүз сорап, тиеш булганча, бераз икътисад турында сөйләдем дә, алдан әзерләнгәнчә, Чаллыда милли сәясәтнең тупас рәвештә бозылуын күрсәтүче мисаллар белән дәлилләп, чыгышымны төгәлләдем. Ул чакта мине хуплап кул чабучылар булмады, хәтта күпләр соңыннан кул бирүдән туктады... Кулдан язылган чыгышымны, Чаллы коммунистларының ул чактагы беренче секретаре Логутовка юлладым. Ул аны хезмәткәре Ф.З.Мостафинага төшергән булып чыкты. Фәйрүзә Зөфәр кызы исә, Чаллыда милли хәрәкәт оештыруның башында торучыларның берсе, «Камэнерготехпром» директоры Габдулла Сәрвәретдиновка җиткергән. Алар КамАЗ мәдәният сараендагы депутатлар бүлмәсендә җыела икән, телефон аша миңа чыктылар һәм шулай итеп, милли хәрәкәткә кушылып киттем. Беренче булып танышкан милләттәшләрем: КамПИ укытучысы доцент Гаяз Малихов, педагогия институтыннан Зәмзәмия Казыйханова белән Рәиф Закиров, шулай ук табибә Сүрия Усманова, Нәсим Усманов, табиб Наил Мансуров, Зиннур Әһлиуллин, Әскәр Ханнанов, Илгизәр Гыйлфанов, КамАЗ хезмәткәре Габдрахман Җәләлетдинов, Рифкат Курмашев, Габдерәүф Гыйзәтуллин, Рифкат Сагидуллин һ.б. иде.

Яр Чаллы Татар иҗтимагый үзәгенең оештыру җыенын 1988 елның 18 мартында уздырдык. Җыелышны Габдрахман Җәләлетдинов алып барды, төп докладны һәм ТИҮ уставы проектын Наил Мансуров укыды...

Аннары, Чаллының милли хәрәкәте мин эшләп йөргән штабта гына түгел, шәһәрнең зур предприятиеләрендә дә бар иде. Мөнир Ситдиков, Тәүзих Гыйльфанов, Якуб Хөснетдинов... һәм мин исемнәрен онытып бетергән асыл егет һәм кызларыбыз КамАЗ структураларында һәм шәһәребезнең бүтән предприятиеләрендә милләт проблемаларын хәл итү максаты белән миннән ким эшләмәде. Камазның «Нур» гәҗите журналисты Чәчкә Хөснетдинова милли хәрәкәт эшчәнлеген генә түгел, гомумән татар тормышын яктыртып килде. Айдар Хәлим җитәкләгән «Аргамак» журналы татар тарихына, аның бүгенге яшәешенә багышланган темаларны бастырып чыгара иде. «Камгэсэнергострой» берләшмәсенең «Таң Йолдызы» гәҗите Сүрия листлары: Хәниф Хөснуллин, Зөбәир Мифтахов, Әхмәт Дусайлы һ.б.ның язмалары еш кына милли проблемаларга багышлана иде. Шуның өстенә Җәмил Сафиуллин хезмәтенә була чыгып торган «Иттифак» партиясенең «Алтын Урда» газетасы, Тәлгат Әхмәдишин тырышлыгы белән чыгарылып килгән «Азатлык» яшьләре газетасы, Дамир Шәйхетдиновның «Безнең Юл», «Чаллы яшьләре» һ.б. исемдәге милли басмалар эшләп торды.

– Төп эштән аерылмыйча, ротация буенча, дүрт мәртәбә ТИҮ рәисе булып тору, Милли Мәҗлескә депутат итеп сайлану, иҗтимагый тормышның үзәгендә кайнау, мәкаләләр язу, документлар әзерләү... Боларның барысына да ничек өлгермәк кирәк?

- Ул күтәрелеш елларында, тарих тарафыннан бирелгән мөмкинлекләрне файдаланып калу кирәк дип уйлый идем шул. Шуңа күрә милләтебезнең киләчәге һәм дәүләтчелек идеяларын тормышка ашыру өчен ял күрмичә, ашкынып йөрдек. Гомуми рәсми җыенда Чаллы ТИҮнең беренче рәисе итеп әзерлекле сәясәтче һәм тирән белемле техник фәннәр кандидаты Гаяз Малихов сайланды. Милли хәрәкәткә килүчеләр арасында нәкъ менә ул татарның бөек милләт икәнен иң яхшы белүче, төбенә төшеп, нигезләп аңлатучы кешеләрнең берсе иде. Ул марксизмга кермичә эш-гамәлләр кылса, мин Ленин теорияләренә нигезләндем. Тик, ни аяныч, Гаязны соңга таба милли хәрәкәттән читләштерделәр һәм бизнеска кертеп җибәрделәр. Әмма җаны-тәне белән үз милләте өчен өзгәләнеп яшәгән Гаяз Малихов эшмәкәр булып китә алмады. Аның тәкъдиме белән, чират буенча (ротация), оешманың икенче рәисе итеп мине сайлап куйганлыктан, 1989 елның февралендә ТИҮнең Казанда үткән оештыру съездында Чаллы бүлеге җитәкчесе буларак катнаштым. Республика җыенында беренче булып язучы Фәүзия Бәйрәмова ясады. Аннары Рафаил Хәкимов чыгышын тыңладым. Чаллы делегациясе исеменнән Йосыф Җимангулов чыгыш ясады – шулай килешкән идек...

Иң зур казанышларыбызның берсе – татар мәгарифен торгызуга керткән өлешебез булды. Ул изге эштә милли хәрәкәттә катнашучы һәркем кулдан килгән ярдәмен күрсәтергә тырышты. Үземнең улым Газиз белән кызым Дилфүзә ЗЯБ бистәсендәге 21 нче мәктәптә укыйлар иде - татар класслары юк. Мәктәп директоры Мөкаддәс Минязевка: «Әйдә, бер класс булса да ачыйк инде», – дим. «Балалар җыеп булмый бит, узган уку елында 8 бала булса ача идек. Бер укытучы бирәм, туплап карагыз», – ди. Өй саен йөреп, 7 ата-ананы үз сабыйларын татар классына бирергә күндерә алдык. Тагын бер бала кирәк. Аптырагач, 6 яшьлек төпчегебез Гүзәлне яздырдым. Ул чактагы беренче уңыш канатландырып җибәрде. Минязев М.И депутат та булгач, аннан үзем яшәгән ЗЯБ бистәсендә бер татар мәктәбе ачарга булышуын үтендем. Моның өчен иң кулай вариант – үзара янәшәдә генә урнашкан 4 нче һәм 6 нчы мәктәпләрнең берсен татарныкы итеп үзгәртү дип уйладык. Максатыбыз – 4 нче мәктәпне татарныкы итеп үзгәртү, ә 6 нчы мәктәпне урыс мәктәбе килеш калдыру иде. Ул вакытта зур авырлык белән булса да, максатыбызга ирештек. Бераздан, нәкъ безнең үрнәк буенча эш йөртеп, әдип Вахит Имамов оештырган икенче төркем дә, Яңа шәһәрнең 52нче комплексындагы 51 нче мәктәпне урысныкы итеп калдыруга, ә 52 нче мәктәпкә фәкать татар балаларын гына туплап, яңа уку йорты ачтыруга иреште. Кызганыч, бу елларда ихластан торып, гаиләләребезне, шәхси тормышыбызны онытып йөрүебез нәтиҗәсендә ирешкәннәребезне тәмам югалтып барабыз шул.

Әңгәмәдәш – **Марат ФАЗЫЛОВ.**

Чаллы шәһәре.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

25 ноябрь (шимбә). ***Җөмәдел әүвәл аеның 12 нче көне. 13 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 15.06 сәгатьтә калка, 5.51 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.46 сәгать.***

Үзгәрешләр көне. Үткәннәр турында уйланып, нәтиҗәләр ясау яхшы. Ач торырга ярамый – теләсә нәрсә ашарга була. Йөрәк, тире, кан тамырлары зәгыйфь. Чикләвек ашау файдалы.

Баллы суган

Аяктагы кан тамырлары тромбозын болай дәвалыйлар. 1 стакан башлы суган согына 1 стакан бал кушып, бүлмә температурасында 3 көн төнәтәләр, аннан соң 3 көнгә суыткычка куялар. Көненә 3 тапкыр, ашарга ярты сәгать кала, 1 әр аш кашыгы эчәләр.

26 ноябрь (якшәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аеның 13 нче көне. 14 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 15.18 сәгатьтә калка, 7.32 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.43 сәгать.***

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик яхшы тәмамланачак. Теләсә нинди вак-төяккә игътибарлы булу сорала. Эчәклек һәм тирене чистарту уңай нәтиҗә бирә. Балан, фасоль, борчак, арпа ашау файдалы.

Борчак шифасы

Борчак кандагы шикәр микъдарын киметә, бавыр эшчәнлеген яхшырта, бәвел куу үзлегенә ия. Ул цистеин, метионин, триптофан аминокислоталарына бай. Цистеин җитешмәгәндә катаракта башлана, метионин азлыгыннан бавыр интегә. Борчак шикәр авыруы белән чирләүләргә бик файдалы: 2 аш кашыгы киптереп вакланган кузакны 1 литр суда сүрән утта 15 минут пешерәләр, 40 минут төнәтәләр дә, 2-3 ай буе көненә 3-4 тапкыр, ашарга 15 минут кала, яртышар стакан эчәләр. Подагра, нефрит, бәвел ташы, ашказаны һәм эчәклек авырулары булганнарга исә борчак ашарга ярамый.

27 ноябрь (дүшәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аеның 14 нче көне. 15 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 15.38 сәгатьтә калка, 8.57 сәгатьтә бата. 12 сәгать 16 минуттан тулы Ай. Көн озынлыгы 7.40 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Тыелгысыз хисләр күңелсез вакыйгага китерергә мөмкин. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

Тырнак гөл сихәте

Гепатит белән чирләүчеләргә халык медицинасы мондый киңәш бирә: 40 грамм кипкән тырнак гөл чәчкәсен яки үләнен 1 литр суда пешерәләр һәм көн дәвамында 3 кә бүлеп эчеп бетерәләр. Хәл әйбәтләнгәнче шулай дәвалаланалар.

28 ноябрь (сишәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аеның 15 нче көне. 16 нчы Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында,16.08 сәгатьтә калка, 10.23 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 7.37 сәгать.***

Тыныч, иҗади, уңышлы көн. Һәрнәрсәдә гармониягә омтылу, җан тынычлыгын саклау мөһим. Дулкынландыргыч очрашулар булырга мөмкин. Беркемгә дә үпкә сакларга ярамый.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Тоз кабу җитә

Кинәт кенә тамыр тартыша, аякны көзән җыера башласа, тел очына әз генә аш тозы сибеп, авызны ачып торырга кирәк. 3-5 минуттан тамыр тартышу бетә.

29 ноябрь (чәршәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аеның 16 нчы көне. 17 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында,16.54 сәгатьтә калка, 11.26 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 7.34 сәгать.***

Бернәрсә дә планлаштырмыйча, теләгән нәрсәне генә эшләү яхшы. Нерв һәм эндокрин системаларга, күзгә игътибарлырак булу сорала. Үпкәләшкән кешеләр белән дуслашыр вакыт. Яшелчәләрне күбрәк ашау файдалы.

Чияле дару

100 грамм чия ботагын 1 литр суда 15-20 минут пешерәләр, суытып, сөзәләр. Көненә 3 тапкыр, ашар алдыннан, 1 әр аш кашыгы эчү калкансыман биз шешкәндә, эчәклек атониясе вакытында файдалы. Өзеп кенә алынган чия яфрагы кан туктату үзлегенә ия. Әгәр борын еш канаса, яфракны ваклап, борынга тыгарга кирәк. Чия тамыры исә ашкайнату бозылганда һәм хәтта ашказаны җәрәхәте вакытында да булыша ала. Моның өчен чия тамырын яхшылап юып, сүрән утта 10 минут пешерәләр һәм чәй урынына эчәләр. Дизентерия булганда, 1 уч чия җимеше сабын яртı литр суда 30 минут кайнаталар да, көненә 2-3 тапкыр яртышар стакан эчәләр.

30 ноябрь (пәнҗешәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аеның 17 нче көне. 18 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 17.57 сәгатьтә калка, 12.22 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 7.32 сәгать.***

Алдашу, ялганга бай көн. Бизләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

Шифалы төнәтмә

100 әр мл дүләнә, сукыр кычыткан, валериана, пион төнәтмәләрен, корвалол, суны кушып, банкада әйбәтләп болгаталар, көн саен йокларга ятар алдыннан 1 әр аш кашыгы эчәләр. Мондый төнәтмә кан басымын төшерә, нерв системасын ныгыта, йокысызлыктан дәвалый.

1 декабрь (җомга). ***Җөмәдел әүвәл аеның 18 нче көне. 19 нчы Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 19.12 сәгатьтә калка, 12.53 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 7.29 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Күп аралашмаска, күз тиюдән, чит тәэсирләрдән сакланырга кирәк. Бурычка алырга да, бирергә дә ярамый. Нерв системасы, эчәклек, арканың өске өлеше зәгыйфь.

Тәмле күмәч

1 стакан җылы сөткә 2 аш кашыгы шикәр, 1-1,5 аш кашыгы коры чүпрә, 6 аш кашыгы он салып, кабарырга куялар. Кабарып менгәч, 50 грамм эретелгән атланмай, 3 әр аш кашыгы иссез үсемлек мае һәм шикәр, 2 йомырка, 1 чәй кашыгы тоз, 3 стакан чамасы он салып, камыр басалар, җылы урынга куялар. Камыр күтәрелгәч, бәләкәй генә бертигез түгәрәкләр әвәлиләр, майланган табага ара калдырып тезәләр. 20 минут кабарткач, тугланган йомырка сарысы сөртеп, өстенә умач (1 аш кашыгы шикәр, 2 аш кашыгы он, 1 чәй кашыгы атланмай) уып сибәләр дә, газ мичендә пешерәләр.

Зинадан авырга узгач...

Зинаның нинди төрләре бар? Зина кылгач тәүбә китерүнең тәртипләре нинди? Исламда зина белән бәйле сорауларга Чаллыдагы «Ак мәчет» мәдрәсәсе мөгаллиме Илдар хәзрәт Хәмидуллин җавап бирде.

– Бүгенге көнкүрешебездә кыз авырга узгач никах укытучылар күп. Андый никах дөрес буламы? Бу никахта туган бала зинадан туган булып саналамы?

– Кыз авырга узгач укыткан никах дөрес. Ләкин никах укытыр алдыннан зина кылган егеткә дә, кызга да, бу гамәлләре өчен кичерүне сорап, тәүбә кылырга кирәк. Бу урында никах укытканнан соң аларга җенси тормыш белән яшәргә ярыймы, дигән сорау да килеп басар. Әгәр дә бу кызның ире шушы алдан зина кылган егете булса, никахтан соң җенси мөнәсәбәтләргә керү рөхсәт ителә. Әмма хатын-кыз авырлы килеш башка ир-атка да тормышка чыгарга мөмкин бит әле. Бу очракта хатын-кызның баласы туганнан соң гына ире белән якынлык кылырга хакы бар. Ә бала, никах укытылгач туса да, зинадан туган бала булып санала.

– Зинадан туган кешенең нинди гаебе бар? Никахсыз килеш яралган бала киләчәктә нинди газапларга дучар була?

– Бу сорауны Мөхәммәд сәлаллаһу галәйһи вәсәлламнең хәләл җефете Гайшәгә дә биргәннәр. Зинадан туган баланың гөнаһлары турында сорагач, ул: «Зинадан туган бала ата-анасының кылган гөнаһлары өчен җаваплы түгел», – дигән. «Әнгам» сүрәсенең 164 аятендә дә: «Бер кеше дә икенче кешенең гөнаһы өчен җаваплы түгел», – дип атап әйтелә. Димәк, Аллаһы Сөбхәнә вә Тәгалә каршында әлеге баланың гаебе юк. Бала андый никахтан туса да, соңыннан изгелекләр кылып, дөрес итеп яшәсә, ул берниндı газапларга да дучар булмаячак. Әгәр дә инде ата-анасының гамәлләрен кабатласа, Аллаһы Тәгаләнең ачуына дучар булыр. Ләкин зина баласы булган өчен генә Аллаһы Тәгалә каршында аның дәрәҗәсе кимемәс.

– Фәкыйрьлектән, «баланы ашата алмабыз» дип куркып, аборт ясату яки ясатмау турында сорауны ничек хәл итәргә?

– Бу мәсьәлә пәйгамбәребез Мөхәммәд сәлаллаһу галәйһи вәсәллам вакытында да бар иде. Ислам динен кабул иткәнчегә кадәр кайбер гарәпләрнең дә, ачлыктан куркып, балаларын төшертүләре билгеле. «Әнгам» сүрәсенең 151 аятендә Аллаһы Тәгаләбез: «Ач булудан яки үстерү мәшәкатеннән куркып балаларыгызны үтермәгез, чөнки аларны да, сезне дә без ризыкландырабыз», – дип әйтә. Безгә, бөтен кешелеккә ризык бирүче бер Аллаһы Тәгалә. Кешенең баласын туендыра алмам дип борчылып абортлар ясатуы зур гөнаһ булып санала, бу тыела. Чөнки кеше үзенең дә ризыгын тәэмин итә алмый, аны бирүче Аллаһы Тәгалә. Без үзебез дә иртәгә нәрсә булачагын белмибез. Шуңа күрә туйдыра алмауны сәбәп итеп баланы төшертү зур хәрам булып санала. Шушы ук аятьтә Аллаһы Тәгалә тыелган әйберләрне зекер итте. Алар арасында кеше үтерү бар. Ә кеше үтерүгә ана карынында булган сабыйны үтерү дә керә. Моның гөнаһы бик зур. Бу турыда Аллаһы Тәгаләбез «Ниса» сүрәсенең 93 аятендә: «Кем дә кем белә торып мөэминне үтерсә, аның җәзасы мәңгелек җәһәннәм, Аллаһы Тәгалә аңа ачуланды, ләгънәт кылды һәм зур газап әзерләде», – дип әйтә.

– Бала үз ризыгы белән туа дигән сүз дә шуннан чыккандыр.

– Һәрбер туган баланың тәкъдире, ашаячак ризыгы, бу фани дөньяда бәхетле яки бәхетсез булачагы Аллаһы Тәгаләбез тарафыннан алдан язып куелган була. Кеше, үзенең билгеләнгән ризыгын ашап бетермичә, мәңгелек тормышка күчмәс.

– Җенси якынлык кылу өчен генә вакытлыча никах укытып торган парлар турында ишеткән бар.

– Кыз да, егет тә никахның вакытлыча икәнлеген белгән очракта никах дөрес булып саналмый. Гали исемле сәхабә исеменнән мондый сүзләр риваять ителә. Ул әйтте: «Рәсүлебез Мөхәммәд сәлаллаһу галәйһи вәссәлам вакытлыча никахтан тыйды», – диде. Кешеләр моның хөкемен белә торып та шулай эшләсә, дин буенча зина кылучы булып саналалар. Гаилә никахтан башлана һәм ул иң изге гамәлләрнең берсе булып тора. Никахның максаты – гаилә төзеп, мәңгелек тормышка күчкәнче бергә булу, матур итеп балалар үстерү, аларны асыл кешеләр итеп тәрбияләү. Шуңа күрә ир-ат белән хатын-кызның җенси ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен генә укытылган никахы дөрес булып саналмый, ул кабул булмый. Белгән килеш андый никахны укыту тыела.

– Зинаның нинди төрләре бар?

– Зина төрләре турында Мөхәммәд сәлаллаһу галәйһи вәсәлламнән хәдис риваять ителә. Пәйгамбәребез зинаның берничә төрен аерып күрсәтә. Шуларның беренчесе – күз зинасы. Кешене зина кылуга иң беренче чиратта карашын чит хатыннардан сакламау этәрә. «Әйт ышанучы хатыннарга, алар үзләренең кайбер карашларын төшерсеннәр һәм гаурәт әгъзаларын сакласыннар, күренгәннән кала (йөз һәм кул чугы) башка матурлыкларын күрсәтмәсеннәр», – диелә «Нур» сүрәсендә.

Икенчесе – тел зинасы. Зинаның бу төренә флиртны кертергә мөмкин. Мәсәлән, ир-ат рөхсәт ителмәгән хатын-кызга яки хатын-кыз ир-атка рөхсәт ителмәгән сүзләр сөйли. Шулай ук пәйгамбәребез калеб яки йөрәк зинасын аерып күрсәтә. Бу инде ярамаган уй-фикерләрең белән зина кылу. Мәсәлән, ир-ат хәләл җефете була торып башка хатын-кызны уйлап, аны күз алдына китереп яса, бу калеб зинасы була. Башка хәдисләрдә шулай ук кул зинасы (рөхсәт ителмәгән кешегә кагылу), аяк зинасы (ярамаган кеше янына бару) да китерелә.

«Адәм баласына зинаның бер өлеше язылган, ул аңа барыбер ирешәчәк. Күзләрнең зинасы – караш, телнең зинасы – сөйләм, колакларның зинасы – тыңлау, кулларның зинасы – тоту, аякларның зинасы – адымнар. Күңел тели һәм сорый, ә җенси әгъзасы моны раслый яки кире кага», – дип язылa «Мөслим» китабында.

Бу алда әйтеп үткән әйберләр кече зина, яки зур зина кылырга этәрүче сәбәпләр дип әйтсәк була.

– «Зинага якын да килмәгез» дигән сүзләрне ничек аңларга?

– Аллаһы Тәгалә «Әл-Исра» сүрәсенең 32 аятендә: «Зинага якын да килмәгез, дөреслектә ул пычрак, яман һәм бик кабәхәт эш», – дип әйтә. Яки Аллаһы Тәгаләбез кешеләргә «зина кылмагыз» гына дими, «аңа якын да килмәгез», – дип яза. Ислам галимнәре фикеренчә, бу сүзләр «зина кылмагыз» дип әйтүгә караганда күпкә көчлерәк яңгырый, аның нинди зур гөнаһ икәнлеген әйтеп бирә. Аллаһы Тәгалә кешеләрне зинага якынайтучы юллардан, сәбәпләрдән ерак торырга өнди. Мәсәлән, ир белән хатын-кызның икесе генә калу яисә үзара сөйләшеп йөрүләре үк зинага этәргеч булырга мөмкин. Аллаһы Тәгалә шулардан ерак торырга чакыра, «якын да килмәгез» дип, аның ни дәрәҗәдә пычрак эш икәнлеген күрсәтә.



● «Әнгам» сүрәсенең 151 нче аяте.

– «Йөз хатын белән зина кылуга караганда, күрше хатыны белән зина кылу куркынычрак» дигән гыйбарә ни турында?

– Бу турыда бер Ислам галиме язып калдырган. Бу урында «күрше хатыны белән зина кылу» дигән сүзне ире булган хатын-кыз белән зина кылу дип аңлау дөресрәк булыр. Галим кияүдәге хатын-кыз белән зина кылу кияүдә булмаган хатын-кыз белән зина кылуга караганда күпкә начаррак, дигәнне әйтергә теләгән. Ни өчен? Чөнки ир кеше монда бер генә гөнаһ кылмый. Ул, беренчедән, хатын-кызны аздыра. Икенчедән, аның иренең хакына керә. Әгәр бу хатын-кыз зина кылганнан соң балага узса, аны кем исеменә теркиләр? Әлбәттә, рәсми яши торган ире исеменә. Шуның өстенә монда әле баланың да хакы бозыла дигән сүз.

«Мөслим» җыентыгында пәйгамбәребез Мөхәммәд сәлаллаһу галәйһи вәсәлламнең бер хәдисе риваять ителә. «Күршесе аның усаллыгыннан имин булмаган кеше җәннәткә кермәс», – ди ул анда. Иманлы кеше булу өчен күрше хакын белү һәм үтәү шарт. Ә инде күршесенең хатыны белән хыянәт итү бернинди кысаларга да сыймый. Ир-ат үзе зина кылудан тыш, әле күрше хакына да хыянәт итә дигән сүз.

– Карт кешенең зина кылуы куркынычрак дигән сүзләр ни аңлата?

– Моның турында пәйгамбәребез Мөхәммәд сәлаллаһу галәйһи вәсәллам: «Аллаһы Тәгалә кыямәт көнендә өч кеше белән сөйләшмәс, аларга миһербанлы карашы белән карамас, гөнаһларыннан арындырмас. Болар: тәкәбберләнеп йөргән ярлылар, еш ялган сөйләгән түрәләр, өйләнгән һәм карт зиначылар», – диде.

Ни өчен дигән сорау килеп туар. Чөнки бу атап үтелгән кешеләрнең гөнаһ кылуга ихтыяҗлары юк иде. Карт кешенең зина кылуына тукталыйк. Өлкән яшьтәге кешенең шәһвәте яшь кешенекенә караганда күпкә зәгыйфьрәк була. Яшь кешене исә дәрте ташып тору, каны кайнау да зина юлына этәрә ала. Ул моның гөнаһ икәнлеге турында иң ахыргы минутта гына уйларга мөмкин. Ә карт кеше инде үзе яшь буынга киңәшләр бирерлек итеп акыл утырткан, төпле фикерле булырга тиеш. Ниндидер гөнаһлы адымга барганчы җиде кат уйларга тиеш. Шуңа да Кыямәт көнендә зина кылган өчен карт кешедән күбрәк соралыр.

– Зина кылган егет белән кызның гөнаһы ата-анасына да төшәме?

– Монда шулай ук бер кеше икенче кешенең гөнаһы өчен җаваплы түгел дип әйтеп булыр иде. Ләкин ата-ана һәм баланы тәрбияләү мәсьәләләре буенча Мөхәммәд сәлаллаһу галәйһи вәсәлламнең бер хәдисе бар. Ул «Әл-Бохари» җыентыгында китерелә. «Сезнең һәрберегез көтүче һәм һәрберегез үз көтүе өчен җаваплы», – диде ул. Ягъни ата-анасы баласына дөрес тәрбия бирмәгән булса, аны әдәпле, әхлаклы итеп үстермәсә, нәсел дәвамчысының зина кылуы алар өстенә дә гөнаһ булыр. «Балаларга кадер-хөрмәт күрсәтегез һәм асыл тәрбия бирегез», – диде Рәсүлебез.

Кайбер ата-ана кызның яки егетнең сайлаган пары белән никахсыз очрашып йөрүенә риза була. Үзләре үк улларына: «Җитешерсең әле, 25 яшең тулгач кына өйләнерсең», ә кызларына: «Бөтен тормышың алда, нигә шулай кияүгә чыгарга ашыгасың?» дип әйтә килиләр, балаларның никахсыз очрашып йөрүләренә, зина кылуларына үзләре үк юл ачалар.

Әгәр баласы ата-анасы затлы әдәп һәм тәрбия биреп тә хаталана икән, моның өчен ата-анасына гөнаһ язылмас. Ата-ана баласын тәрбияләүдә һич кимчелек күрсәтергә тиеш түгел. Кире очракта баласының ялгыш адымы өчен гөнаһ алар өстенә дә ятар. «Әй, кешеләр, үзегезне һәм гаиләләрегезне җәһәннәм утыннан саклагыз, – дип әйтте «Тәхрим» сүрәсендә Аллаһы Тәгаләбез. Ул безне үзенең газапларыннан үзе кисәтте, якыннарыбызны да сакларга чакырды. Ә бу саклануның иң гади юлы – динне өйрәнү. Үзегез дә өйрәнегез, гаиләләрегез – балаларыгызга да дингә өйрәтүгә зур әһәмият бирегез. Дини тәрбия биреп, якыннарыгызны Аллаһы Тәгаләнең ачуыннан һәм газабыннан коткарырсыз.

– «Зина ул – әҗәт. Әгәр шул әҗәтне өстеңә алсаң, үз гаиләң әһелең белән түләрсең була», – дигән сүзгә аңлатма бирсәгезче.

– Әлеге сүзләрне бер Ислам галиме үзенең шигырендә китерә. Бу гыйбарә әгәр кеше зина кыла икән, көннәрдән бер көнне ул шушы зинаның «әҗәтен» түләячәк, яки шушы зиначының да хатыны яки балалары зина юлына басар, гомере бәхетсез булыр дип аңлатыла. Аның гөнаһы нәселенә төшәргә мөмкин дип тә аңларга була. Зина кылган кеше, әлбәттә, балаларын тәрбияләүгә дә хилафлык китерә. Бу кеше үзенең дәвамчыларына начар үрнәк күрсәтә.

– Зинаны ничек дәлилләргә? Ире хатынның яки хатыны ирен зина өстендә тотты ди. Алар моны үзләре генә дәлилли аламы?

– Хәнәфи мәзхабе буенча «Кудури» китабында: «Зинаны раслау өчен 4 кеше аңа шаһит булырга тиеш», – дип язылган. Яки дүрт кеше зинаны башкалардан ишетеп кенә түгел, үз күзләре белән күрергә тиеш. Алар шаһитлек биргән очракта, бу зина булып санала. Ләкин шәригатебездә алай кешеләр килеп зинаны раслаганы турында зекер ителми. Дин китапларында андый очраклар турында язылмый. Гадәттә, зина кылганнан соң кешеләр үзләре тәүбәгә килеп, пәйгамбәребезгә сөйли торган булган. Әгәр ире хатынын хыянәттә гаепли икән, бу очракта дәлилләүнең үз тәртибе бар. Ул дини китапларда лиган дип атала.

Лиган – ул ир яки хатын-кызның тормыш иптәшен зина кылуда гаепләп, бу хакта ант иткәннән соң аерылышулары.

Диндә бөтен талак, зина мәсьәләләрен казыйлар чишә. Ир кеше хатынының зина кылуы турында казыйга барып сөйли. Шул рәвешле хатын-кыз да иреннән аеруны сорап казыйга мөрәҗәгать итә ала.

Ләкин хатын-кыз шуны белергә тиеш: ул ире зина кыла дип уйларга мөмкин. Ә чынлыкта көндәш хатын-кыз иренең икенче никахлы хатыны булып чыгуы бар. Шуңа күрә бу мәсьәләләрне казый җентекләп тикшерергә тиеш. Ир-атка икенче хатын алу өчен беренче хатынының рөхсәт бирүе зур шарт булып тормый. Әмма бу матур күренеш түгел, андый никахлар бәрәкәтле булмый. Беренче хатынына хөрмәт йөзеннән, аннан менә мондый аңлашылмаучанлыклар килеп чыкмасын өчен ир-атка хатынына яңадан өйләнәчәген хәбәр итсә, яхшырак.

Бүгенге заманда видео дәлилләр турында сорау туарга мөмкин. Диндә видеога төшереп зинаны дәлилләү кабул ителми. Чөнки видеоны үз файдаңа үзгәртеп була.

– Зина кыла дип нахак балә ягучыга нинди җәза бирелә?

– Дәлиле булмаган килеш кешене зинада гаепләп йөрүче дә җәзага тартыла. Дин буенча мондый гайбәт таратучыга 80 камчы каралган. Бу «Кудури» китабында китерелә. Мөселман илләрендә казый мондый нахак сөйләп йөрүчеләргә әнә шундый җәза бирергә мөмкин. Ләкин безнең җәмгыятьтә мондый ысуллар кулланылмый инде. Әгәр кеше икенче берәүне сәбәпсез гаепләп йөрсә, андый кеше Кыямәт көнендә Аллаһ Тәгалә каршында каты газапка ия булыр диелә.

– Зина кылган кеше ничек тәүбә китерә? Ул кичереләме?

– «Әл-Фуркан» сүрәсенең 70 аятендә Аллаһы Тәгаләбез зур гөнаһ кылганнарны зикер иткәннән соң һәм аларны җәһәннәмдә нәрсә көткәннәрен бәян иткәннән соң: «Мәгәр берәү тәүбә итеп иман китерсә һәм алга таба изге гамәлләр кылса, андый кешеләрнең начарлыгын яхшылыкка алыштырырбыз», – диде. Аллаһы Тәгалә аларны ярлыкады һәм мәрхәмәтле булды. Димәк, кеше гөнаһын танып, дөрес итеп тәүбә итсә, Аллаһы Тәгалә аның зина гөнаһын да ярлыкар.

– Тәүбә китерүнең тәртибен тәфсилләп аңлатсагыз иде: нинди сүзләр әйтергә, нинди догалар укырга?

– Тәүбә итү өчен кеше иң беренче итеп бу начар гамәлне кылуыннан туктарга тиеш. Икенчедән, эшләгән эшләренә чын күңеленнән үкенергә тиеш. Өченчедән, бу эшне башка эшләмәячәкмен дип үз-үзенә һәм Аллаһ Тәгалә каршында сүз бирергә тиеш.

Була шундый кешеләр – гөнаһ кыла да, кешеләр алдында шуның белән горурланып, мактанып сөйләп йөри. Ә үзе мин хәзер тәүбә иттем инде, ди. Тәүбә – эшләнгән гөнаһның өчен ихластан үкенеп, аны бүтән кылмаска ниятләп катгый карар кылу ул. Чын күңелдән тәүбә иткән кешене «Әл-Фуркан» сүрәсендә әйтелгәнчә, Аллаһы Тәгалә гафу итәр.

Тәүбә намазы – эшләнгән гөнаһлар өчен үкенеп, тәүбә итәр өчен укыла торган ике рәкәгать нәфел намазы. Кеше яхшы итеп тәһарәт алып, шушы намазны укый һәм Раббысына түбәнчелек күрсәтеп үзенең барлык гөнаһларын кичерү сорый. Аллаһы Тәгаләбез безгә карата мәрхәмәтле, шуңа күрә тәүбәне кайсы телдә итсәң дә кабул ителә. Әмма кеше ихластан Раббыбыздан гафу сорарга тиеш. Аллаһы Тәгалә безнең күңелебездә булганнарны белеп, сизеп тора, бер генә уеңны да аннан яшереп калып булмый. Тәүбә итүнең махсус догасы да бар. Мөхәммәд сәлаллаһу галәйһи вәсәллам бер хәдисендә тәүбә итү догасының догаларның хуҗасы икәнлеген әйтте. Анда:

«Әллаһүммә әнтә Раббии ләә иләәһә илләә әнт. Халәкътәнии вә әнәә гәбдүк вә әнәә гәләә гәһдикә вә вәгъдикә мәстәтагътү. Әгүүзү бикә мин шәрри мәә сәнәгътү. Әбүү'ү ләкә бинигъмәтикә гәләййә вә әбүү'ү бизәнбии. Игъфир лии, фәиннәһү ләә йәгъфируз-зүнүүбә илләә әнт» яки «Йә Аллаһ! Син минем Раббым, Синнән башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк. Син мине барлыкка китердең, мин Синең колың һәм мин булдыра алганча Синең әмерләреңне үтим вә әйткән вәгъдәңә ышанам. Мин синә кылган начарлыктан сыенам һәм Синең миңа биргән нигъмәтеңне танийм. Шулай ук мин кылган гөнаһымны да танийм. Мине гафу ит. Синнән башка беркем дә гөнаһларны гафу итми», – дип әйтелә.

Намаз укыганнан соң шушы доганы ятлап, яки карап укыса дөрес булыр, иншә Аллаһ.

– Зиначылар тәүбә итмәгән очракта, аларны үлгәч нинди җәза көтә?

– «Әл-Бохари» җыентыгында шундый хәдис бар. Мөхәммәд сәлаллаһу галәйһи вәсәлламнең төшендә ике фәрештә килә. Алар аны үзләре белән җәһәннәмдәге кешеләрнең ничек газапланганнарын күрсәтергә алып баралар. «Без анда күрдек бер казан. Аның авызы тар иде. Ә эченнән кешеләрнең бик каты, куркыта торган тавышлар белән кычкырганнары ишетелде. Шул казан эчендә ирләр һәм хатыннар, ә астында җәһәннәм уты яна иде. Әлеге кешеләр шул утта газапланды. Кабат Аллаһы Тәгаләбез аларны терелтә һәм алар киредән шушы ук газапны күрә иде», – дип сөйләде Мөхәммәд сәлаллаһу галәйһи вәсәллам.

Ул фәрештәләрдән: «Болар кемнәр?» – дип сорады. «Бу – зина кылучылар. Алар шушы газапны үлгәннән соң Кыямәт көненә кадәр күрерләр», – дип җавап бирде алар. Шулай ук башка хәдистә мөмкинлекләре була торып та зина кылмыйча калган кешеләр мактала. «Кыямәт көнендә бик каты эссе булыр. Кешеләр, кайсы авызына, кайсы колагына кадәр, үз тирләренә батар. Бер урында да күләгә булмас. Әмма җиде төркем кешеләрне Аллаһы Тәгалә үз күләгәсе белән каплар. Әлеге төркемнәрнең берсе зина кылмыйча калган ир-атлар һәм хатын-кызлар булыр», – дип әйтелә анда.

Гөлназ ХӘБИБУЛЛИНА.

Һава кушылган ризык

Замана гастрономиясендә иң модалы ашамлык – молекуляр ризыклар, ягъни мәсәлән, ит урынына – желе, кәһвә яки чәй урынына – печенье. Киләчәк ризыгын француз химигы Эрве Тис уйлап тапкан. Заманча технологияләр ярдәмендә пешекчеләр каты ашамлыкларны күбек яки эмульсия хәленә китерә, ә сыекларын – катыра. Мәсәлән, түбән температурада пешерелгән йомырка крем кебек йомшара, ипигә ягарлык була. Химия, молекулаларга бәйле булганга, мондый ризык ясалма тоелырга мөмкин. Тик бу алай түгел. Молекуляр гастрономиядә бары тик суүсемнәрдән алынган табигый өстәмәләр, желатин, сода, чүпрә кулланыла. Шунлыктан мондый ризык сәламәтлек өчен зыянлы түгел. Хәзер итне 61-64 градус температурада берничә сәгать буе пешерү модалы, бу очракта аның бөтен файдалы матдәләре саклана икән. Ә гомумән алганда, әлеге химик-технологик фокуслар инде күптән мәгълүм, аларны уйлап табучылар да европалылар түгел. СССР вакытында ук молекуляр технологияләр кулланылган инде. Метилцеллюлоза – табигый куерткыч, аны каймакка кушып, ашханә мөдирләре 1 килограмм ризыкны 200 килограммга әйләндерә, барлыкка килгән “каймак”ның куелыгына шаккатарлык була. 10 грамм иттән әзерләнгән казылык та чынныннан тышкы кыяфәте белән аерылмаган, сыйфатын исә берничек тә тикшереп карый алмаганнар.

(“Лента.ру”).

Балык мае сихәте

Балык маен көн саен куллану күңел төшенкелегеннән саклый икән. Норвегиянең Берген университеты каршындагы Хокланд хастаханәсе галимнәре шундый нәтиҗәгә килгән. Алар үткәргән тикшеренүдә 22 мең кеше катнашкан. 40-74 яшьлек кешеләрне 2 ел дәвамында күзәтү күрсәткәнчә, көн саен балык мае эчкәннәрнең 30 процентында депрессия билгеләре кимегән. Әлеге майны озак вакыт буе кулланганнарның эмоциональ халәте яхшырган. Сихәтле май Омега-3 кислотасына бай, нәкъ менә шушы матдә инсульт, инфаркт һәм яман шеш килеп чыгу куркынычын күпкә киметә.

(“Die Presse”).

Асыл алма

Алманың тагын бер сихәтле үзлеге ачылган. Моңарчы алма согы кан тамырларындагы атеросклерозны дәвалауда кулланылса, хәзер исә бу файдалы җимешнең яман шешнең кайбер төрләрен үсүдән туктата алу үзлеге расланган. АКШның Корнель университеты галимнәре алма кабыгындагы шифалы кушылмалар – тритерпеноидларның бавыр, ашказаны һәм күкрәктәге шеш күзәнәкләренең үсүен туктатуын дәлилләгән. Әлеге куркыныч чирдән саклану өчен, табибләр көн саен бер генә булса да алма ашарга киңәш итә. Әгәр инде алманың 5-6 төшен дә ашап куйсаң, организм йодка да туеначак.

(“The Local”).

Мьянма чибәрләре

Мьянмадагы падаунг халкы хатын-кызларының муены жирафныкы кебек озын. Биш яшь тулгач, кыз баланың муенына бакыр божра кигерә башлыйлар, үскән саен, спиральнең бормалары арта бара. Нәтиҗәдә муен озыная һәм кайвакыт хәтта ярты метрга да җитәргә мөмкин, божраларның авырлыгы исә дүрт-биш килограмм тәшкил итә. Кияүгә чыккач, муенны озынайтудан туктыйлар, тик теләгән кеше аннары да бакыр спираль киеп йөрүен дәвам итә ала. Борынгы легенда буенча, әлеге гореф-гадәт кырда эшләгән хатын-кызны юлбарыс һөҗүменнән саклау зарурлыгыннан килеп чыккан. Элеккерәк заманда исә ирләренә хыянәт иткән хатыннар өчен үзенчәлекле җәза да уйлап табылган: аларның муеныннан божраларын салдырып алганнар – зәгыйфьләнгән умырткалар инде мөстәкыйль рәвештә башны тотмаган, шуңа күрә мескенкәй бик газапланып үлгән. Бүген исә Мьянма хатыннарының бакыр божралары байлык күрсәткече булып тора һәм бизәнү әйбере санала. Озын муенлы хатын-кызлар туристларны җәлеп итә. Иң зур Най-Сон авылына ел саен 1200ләп сәяхәтче килә, аларның һәркайсы биргә 250 бат түләп керә. Көньяк Африкадагы ндебеле кабиләсендә дә моңа охшаш гадәт бар, анда кызлар муенына божраны 12 яшьтән алып кияүгә чыкканчы киеп йөри.

(“TravelAsk”).

● Лев Толстой.

● Агата Кристи.



● Эрнест Хемингуэй.

● Харуки Мураками.

Һәркемнең үз ысулы

Китап язар өчен, илһам кирәк. Бөек әсәрләр нинди генә шартларда язылмый икән бит! Лев Толстой (1828-1910) иртәнге тугызларда гына йокысыннан торган, юынып, киенеп, сакалын тараганчы, беркем белән дә сөйләшмәгән. Аннары чиле-пешле ике йомырка ашап, кәһвә эчкән дә, төшке ашка кадәр кабинетына кереп бикләнгән. Кайвакыт анда тавыш-тын чыгармыйча хатыны Софья да утыра торган булган – “Сугыш һәм солых” романының берничә бүлеген кулдан күчереп язарга яки язучының яңа бүлекләрне кычкырып укуын тыңларга туры килгән. Аннары Толстой сәйранда йөргән, аннан яхшы кәефтә кайтса, тәэсирләре белән уртаклашкан, балалары белән шөгыльләнгән. Кәефе начар булса, китап укыган. Агата Кристи (1890-1976), инде дистәләгән китап авторы чагында да, анкетада үзен “хуҗабикә” дип күрсәткән. Аның аерым кабинеты да, хәтта язу өстәле дә булмаган. Буш вакытында йокы бүлмәсендәге кечкенә өстәлдә яки аш өстәлендә яза торган булган. Әгәр инде өйдә ялгыз калу бәхете тәтесә һәм беркем дә комачауламаса, дөньясын онытып язган да язган. Эрнест Хемингуэй (1899-1961) гомере буена таң атканда торган. Хәтта төн буена эчсә дә, иртәнге алтыдан да соңга калмаган. Аннары төшкә кадәр аягүрә басып язган, санап куелган кәгазе беткәч, карандаш белән язганнарын машинкада баскан. Ул көн саен ничә сүз язуын санаган һәм график төзегән. Харуки Мураками (1949 елда туган) көн саен иртәнге дүрттә тора һәм алты сәгать буе яза. Аннан соң йөгерә, йөзә, укый, музыка тыңлый. Кичке тугызда йокларга ята. Мураками фикеренчә, шулай кабатлана торган режим аңа иҗат итү өчен бик файдалы транска китәргә булыша. Кайчандыр ул гел утырып кына эшләгән, симергән, көненә өчәр кап тәмәке тарткан. Аннары авылга яшәргә күчеп киткән, балык һәм яшелчә ашауга күчкән, тәмәкесен ташлаган һәм инде 25 ел буе йөгерә. Мондый тормышның бердәнбер кимчелеге – аралашу булмау. Көндәлек режимын саклау өчен, Мураками чакырган җирләргә бармый, шуңа дуслары үпкәле. Тик язучыны бу куркытмый: аңа үз укучысы өчен мавыктыргыч яңа китап язу бар нәрсәдән рәхәтрәк.

(“Bookmix.ru”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

27 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АЛМАШ». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30, 16.00 «Халкым минем...» 12+
12.00, 22.40 «МӘХӘББӘТ ҺӘМ ЙОЛДЫЗЛАР». 16+
13.00, 14.45 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
15.15 «Учимся вместе» һәм «Шаян пластилин».
17.30 «Ватандашлар». 16+
18.00 «Кто мы татары?» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 12+
21.00 «Заман көзгесе». 6+
22.10 «Tatarstan today. Открытый миру». 16+
23.30 «ТРЮКАЧ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 0.15 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Башвактыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Гадел Кутуй турында телеочерк. 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30 «Заман көзгесе». 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30 «Сәләт». 6+
19.10, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
20.30 «Таяну ноктасы». 16+
21.25, 0.40 «Күңелләрдә тальян моңнары». 12+
21.55 «Туган авылым». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «КУМИР». 16+
11.30 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ПОСЛЕДНЯЯ НЕДЕЛЯ». 12+
14.50 «Первые в мире». 12+
15.00 «Жизнь замечательных идей». 12+
15.30 «Цареубийство. Следствие длиною в век». 12+
16.30 «МИНДАЛЬНЫЙ ПРИВКУС ЛЮБВИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «ДЕНЬГИ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «ТЕСТ НА БЕРЕМЕННОСТЬ». 16+
22.55 «Большая игра». 16+
23.55 «Машков». 12+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 Утро России.
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 О самом главном. 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 60 минут. 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 Малахов. 16+
21.20 «ЕКАТЕРИНА. ФАВОРИТЫ». 16+
22.20 Вечер с Владимиром Соловьёвым. 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Даты, определившие ход истории».
7.05 «Пешком...»
7.35 Черные дыры. Белые пятна.
8.20 Невский ковчег. Теория невозможного. Вадим Вилинбахов.
8.50 «И ЭТО ВСЁ О НЁМ».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «Наблюдатель».
11.15 ХХ век. «Путь к роли. Наталья Гундарева и Марина Неёлова».
12.45 Новости. Подробно. АРТ.
13.00 «Книги моей судьбы».
13.25 «СЛУЖИЛИ ДВА ТОВАРИЩА».
15.00 Линия жизни. Наталия Касаткина.
15.55 «Агора».
17.15 Симфонические оркестры России. Национальный филармонический оркестр России. Художественный руководитель и главный дирижёр Владимир Спиваков. Солист Александр Рамм.
17.55 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
18.35 «Валерий Брюсов. Побеждённый учитель».
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Петр Толстой. «Слабые связи - сильная сторона химии».
20.45 «Сати. Нескучная классика...»
21.30 «2 Верник 2».
22.25 «31 ОТДЕЛ».
23.30 «Рэгтайм, или Разорванное время». «Первая командировка».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 Утро. Самое лучшее. 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 Сегодня.
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «БАЛАБОЛ». 16+
22.15 К 60-летию Владимира Машкова. «На стороне чувств». 16+

Сишәмбе

28 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.15 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АЛМАШ». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 16+
11.15, 0.25 «Если хочешь быть здоровым». 16+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «МӘХӘББӘТ ҺӘМ ЙОЛДЫЗЛАР». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 16+
14.00 «Путь». Красная горка. 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Учимся вместе» һәм «Мин татарча өйрәнәм».
17.15 «Казаннан - казанга». 16+
17.45, 0.40 «Таяну ноктасы». 16+
18.45 Хоккей. «Ак Барс» - «Лада». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.00 «ТРЮКАЧ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.30, 18.20, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
9.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
10.00 «Күңелләрдә тальян моңнары». 12+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате». 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Халкым минем». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДЕНЬГИ». 12+
11.30 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ПОСЛЕДНЯЯ НЕДЕЛЯ». 12+
14.45 «Заповедники РФ». 12+
15.10 «Кто нас нарисовал». 12+
15.30 «Цареубийство. Следствие длиною в век». 12+
16.30 «МИНДАЛЬНЫЙ ПРИВКУС ЛЮБВИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «ТЕСТ НА БЕРЕМЕННОСТЬ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 Утро России.
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 О самом главном. 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 60 минут. 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 Малахов. 16+
21.20 «ЕКАТЕРИНА. ФАВОРИТЫ». 16+
22.20 Вечер с Владимиром Соловьёвым. 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Даты, определившие ход истории».
7.05, 15.15 «Пастер и Кох: битва гигантов в мире микробов».
8.00 «Почерк эпохи». «Велимир Хлебников. Я для вас Звезда...»
8.25 «Жизнь и судьба».
8.50, 22.30 «31 ОТДЕЛ».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «Наблюдатель».
11.15 ХХ век. «Песни Марка Фрадкина».
12.10 «Забытое ремесло».
12.45 Новости. Подробно. Книги.
13.00 «Книги моей судьбы».
13.30, 13.50, 14.10, 23.55 «ПОРУС».
14.30 Больше, чем любовь.
16.15 «Сати. Нескучная классика...»
17.15 «Библейский сюжет».
17.40 Симфонические оркестры России. Большой симфонический оркестр имени П.И. Чайковского. Художественный руководитель и главный дирижёр Владимир Федосеев. Солист Адам Гуцериев.
19.00 «Почерк эпохи». «Рина Зелёная. За кадром...»
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Илья Смирнов. «Китайская культура в зеркале поэзии».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Искусственный отбор.
21.45 «Белая студия».
23.30 «Рэгтайм, или Разорванное время». «История с фотографиями».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 Утро. Самое лучшее. 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 Сегодня.
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «БАЛАБОЛ». 16+
22.15, 0.00 «ЛИХАЧ». 16+

Чәршәмбе

29 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АЛМАШ». 16+
11.00, 0.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «МӘХӘББӘТ ҺӘМ ЙОЛДЫЗЛАР». 16+
13.00, 0.25 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Азбука долголетия». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Учимся вместе» һәм «Шома бас».
17.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Гаилә учагы». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 12+
21.00 «Ватандашлар». 16+
23.00 «ТРЮКАЧ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10, 8.30, 18.20, 23.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
9.30 «Йөрәктән-йөрәккә». Гадел Кутуй турында телеочерк. 16+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05, 21.25 «Ике аккош». Нәҗибә Ихсанова, Исламия Мәхмүтова, Зөһрә Сәхәбиева тормыш һәм мәхәббәт турында.. 12+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
19.10, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00, 0.15 «Гаилә учагы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДЕНЬГИ». 12+
11.30 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ПОСЛЕДНЯЯ НЕДЕЛЯ». 12+
14.45 «Заповедники РФ». 12+
15.10 «Кто нас нарисовал». 12+
15.30 «Цареубийство. Следствие длиною в век». 12+
16.30 «МИНДАЛЬНЫЙ ПРИВКУС ЛЮБВИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «ТЕСТ НА БЕРЕМЕННОСТЬ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 Утро России.
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 О самом главном. 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 60 минут. 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 Малахов. 16+
21.20 «ЕКАТЕРИНА. ФАВОРИТЫ». 16+
22.20 Вечер с Владимиром Соловьёвым. 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Даты, определившие ход истории».
7.05, 15.20 «Математика и подъем цивилизации».
7.55 «Почерк эпохи». «Рина Зелёная. За кадром...»
8.25 «Жизнь и судьба».
8.50, 22.25 «31 ОТДЕЛ».
9.30 «Вологда. Усадьба Брянчаниновых».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «Музыкальный киоск».
11.50 Больше, чем любовь.
12.45 Новости. Подробно. Кино.
13.00 «Книги моей судьбы».
13.30, 13.50, 14.10, 23.55 «ПОРУС».
14.30 «Все краски мира».
16.10 «Белая студия».
17.15 «Библейский сюжет».
17.40 Симфонические оркестры России. Российский национальный оркестр. Дирижёр Димитрис Ботинис.
18.30 «Рассекреченная история».
19.00 «Почерк эпохи». «Даниил Хармс. Я творец мира...»
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Александра Баркова. «Мифология в современном обществе».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Абсолютный слух.
21.40 «Светильник правды и добра».
23.30 «Рэгтайм, или Разорванное время». «Не тому дали Нобелевскую премию».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 Утро. Самое лучшее. 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 Сегодня.
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «БАЛАБОЛ». 16+
22.15, 0.00 «ЛИХАЧ». 16+

Пәнҗешәмбе

30 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.15 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 18.45 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АЛМАШ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «МӘХӘББӘТ ҺӘМ ЙОЛДЫЗЛАР». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Память сердца». 16+
14.15 «Классный час». 16+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Учимся вместе» һәм «Музыкаль тәнәфес».
17.15 «Точка опоры». 16+
19.15 Хоккей. «Ак Барс» - «Автомобилист». 6+ По окончании - «Погружение на 100». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Наша Республика - наше дело». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 0.15 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.30, 23.10 «Кәмит Җәвит». 16+
9.30 «Гаилә учагы». 16+
10.00 «Туган авылым». 12+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.20 «Идрис Газиев тәкъдим итә». «Сәйдәш театры». 16+
19.15, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Tatarstan today. Дөньяга ачык». 16+
21.25 «Йөрәктән-йөрәккә». Гадел Кутуй турында телеочерк. 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДЕНЬГИ». 12+
11.30 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ». 12+
12.30, 18.30 «Подружки». 16+
13.00, 23.50 «ПОСЛЕДНЯЯ НЕДЕЛЯ». 12+
14.45 «Заповедники РФ». 12+
15.10 «Кто нас нарисовал». 12+
15.30 «Спутник. Русское чудо». 6+
16.30 «МИНДАЛЬНЫЙ ПРИВКУС ЛЮБВИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.

9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «ТЕСТ НА БЕРЕМЕННОСТЬ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 Утро России.
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 О самом главном. 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 60 минут. 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 Малахов. 16+
21.20 «ЕКАТЕРИНА. ФАВОРИТЫ». 16+
22.20 Вечер с Владимиром Соловьёвым. 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Даты, определившие ход истории».
7.05, 15.15 «Математика и подъем цивилизации».
7.55 «Почерк эпохи». «Даниил Хармс. Я творец мира...»
8.25 «Жизнь и судьба».
8.50 «31 ОТДЕЛ».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Спрашивайте, мальчики».
12.10 «Забытое ремесло».
12.45 Новости. Подробно. Театр.
13.00 «Книги моей судьбы».
13.30, 13.50, 14.10, 23.55 «ПОРУС».
14.30 Острова. Эдуард Артемьев.
16.15 «2 Верник 2».
17.15 Пряничный домик. «Сказки Удмуртии».
17.40 Симфонические оркестры России. Большой симфонический оркестр имени П.И. Чайковского. Художественный руководитель и главный дирижёр Владимир Федосеев. Солистка Дали Гуцериева.
19.00 «Почерк эпохи». «Николай Некрасов. Народный поэт».
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Екатерина Манойло. «Отец смотрит на запад».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 «Семнадцать мгновений весны». Штирлиц, а вас я попрошу остаться!»
21.40 «Энигма. Ксения Сидорова».
22.25 ЗВОНОК.
23.30 «Рэгтайм, или Разорванное время». «Выставка на ограде храма».

«НТВ»
5.00 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 Утро. Самое лучшее. 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 Сегодня.
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «БАЛАБОЛ». 16+
22.15, 0.00 «ЛИХАЧ». 16+

Җомга

1 декабрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АЛМАШ». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Если хочешь быть здоровым». 16+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Учимся вместе» һәм «Төймә».
17.30 «Кто мы татары?» 12+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты. 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Наши герои». 16+
21.00 «Юлчы». 16+
22.10 «ВОЛГА-ВОЛГА».
23.45 «СВАДЕБНЫЙ ПОДАРОК». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.30, 18.20, 23.10 «Ком сәгате». 16+
9.30, 16.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.00, 20.30 «Заман көзгесе». 6+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05 «Исламия... тормыш үзе язган рольдә...» Исламия Мәхмүтова турында телеочерк. 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 21.55 «Күңелләрдә тальян моңнары». 12+
18.00 «Яңалыклар». 12+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Туган җир». 12+
21.25 «Кто мы татары?» 12+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ДЕНЬГИ». 12+
11.30 «АВТОШКОЛА». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.50 «ДУЭЛЯНТ». 16+
14.45 «Наша марка». 12+
15.00 «Кто нас нарисовал». 12+
15.30 «Страна Советов. Забытые вожди». 12+
16.30 «МИНДАЛЬНЫЙ ПРИВКУС ЛЮБВИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.20 «Fam TV». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО МАЙОРА БАРАНОВА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «Фантастика». 12+
23.40 «Матадор». «Объединенные цвета Оливьеро Тоскани. Конец века по Годфри Реджио». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 Утро России.
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 О самом главном. 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 60 минут. 12+
14.55 Судьба человека с Борисом Корчевниковым. 12+
16.30 Прямой эфир. 16+
21.30 Гала-концерт финалистов шоу «Ну-ка, все вместе!» 6+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Даты, определившие ход истории».
7.05, 15.20 «Математика и подъем цивилизации».
7.55 «Почерк эпохи». «Николай Некрасов. Народный поэт».
8.25 «Жизнь и судьба».
8.50 ЗВОНОК.
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «АДМИРАЛ НАХИМОВ».
12.00 Открытая книга. Екатерина Манойло. «Отец смотрит на запад».
12.45 «Светильник правды и добра».
13.25, 13.45, 14.05 «ПОРУС».
14.25 «Энигма. Ксения Сидорова».
15.05 «Забытое ремесло».
16.10 «Первые в мире».
16.30 Письма из провинции.
17.15 «Волшебная флейта. Путешествие». XVI Зимний международный фестиваль искусств Юрия Башмета в Сочи.
19.45 Искатели. «Бриллианты Перси-Френч».
20.30 Линия жизни.
21.25 «МЫ ИЗ ДЖАЗА».
22.50 «2 Верник 2».
23.40 «ПОХИТИТЕЛЬ БАЙКОВ».

«НТВ»
5.00 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 Утро. Самое лучшее. 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня.
8.25 «Мои университеты». 6+
9.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.55 Жди меня. 12+
20.00 «БАЛАБОЛ». 16+
22.15 «ЛИХАЧ». 16+

Шимбә

2 декабрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.30 «Музыкальный майдан». 16+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
13.30 «Гаилә учагы». 16+
14.00 Гала-концерт Республиканского фестиваля рабочей молодёжи «Наше время - Безнең заман». 6+
16.30 «Халкым минем...» 12+
17.00 «Күңелләрдә тальян моңнары». 6+
17.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 16+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «ЖЕНИХ НАПРОКАТ». 16+
23.50 «ПРОЩАЙТЕ, ФАРАОНЫ!» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Хәй Вахитов турында телеочерк. 16+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 Спектакль «Кияүләр». 16+
17.15 «Калеб». 6+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Бир кулыңны». Зөлфирә һәм Алмаз Мирзаяновлар концерты. 16+
21.50 Спектакль «Хушыгыз!» 16+

«ЭФИР»
5.00 «Деревни России». 12+
5.20, 14.35 «Государственная грамота. Указы Петра I». 12+
5.45 «Руби и Повелитель воды». 6+
7.00 «Смешарики. Новые приключения».
7.30 «Фиксики».
7.45 «Белка и Стрелка. Тайны космоса».
8.00 «Записки земского доктора». 6+
8.50 «ПРЕСТУПЛЕНИЕ В ФОКУСЕ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЛЮБОВЬ ПО РАСПИСАНИЮ». 12+
14.50 «Наука верующих или вера ученых». 12+
15.30 «СХВАТКА». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «БРОНКСКАЯ ИСТОРИЯ». 16+
23.00 «ДЕЛО КОЛЛИНИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Наше всё». 12+
11.05 «ПроУют».
12.15 «Поехали!» 12+
13.10 Подкаст.лаб «Обман веществ». 16+
13.50 Подкаст.лаб «Креативные индустрии». 16+
14.35 «КРАЙ». 16+
17.00 «Я люблю мою страну».
18.20 «Михаил Задорнов. вся жизнь». 16+
19.15 «Эксклюзив». 16+
20.05 «Кто хочет стать миллионером?»
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.20 «ФАВОРИТКА». 18+

«РОССИЯ»
5.00 Утро России. Суббота.
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 По секрету всему свету.
9.00 Формула еды. 12+
9.25 Пятеро на одного.
10.10 Сто к одному.
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.50 «В кругу друзей».
12.50 Доктор Мясников. 12+
14.50 «Парад юмора». 16+
17.50 Привет, Андрей! 12+
21.00 «ЭТО ЖИЗНЬ». 16+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
8.00, 8.20, 8.40, 9.00, 9.20, 9.40 «ПОРУС».
10.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «МЫ ИЗ ДЖАЗА».
11.40 Человеческий фактор. «Творческая деревня».
12.05 Черные дыры. Белые пятна.
12.45 «Охотники за медом».
13.30 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
14.50 «Нобелевские победы российской науки». Николай Басов и Александр Прохоров.
15.35 «Первая позиция».
16.20 «Рассекреченная история».
16.45 «АКТРИСА».
18.00 Большая опера.
19.45 «МАЛЕНЬКИЙ БУДДА».
22.00 «Агора».
23.00 «Великие мгновения музыки».
23.55 «НА МУРОМСКОЙ ДОРОЖКЕ...»

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
7.30 Смотр.
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «Поедем, поедим!» 16+
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.10 «Попутчик». 16+
14.20 «Игры разумов».
15.00 «Своя игра».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Секрет на миллион». 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Суперстар!» 16+
23.35 «Ты не поверишь!» 16+

Якшәмбе

3 декабрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Болгар радиосы» концерты. 12+
8.00, 13.00 «Адымнар». 16+
8.30 Мультфильмы.
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы-шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы».
10.15 «Дуслык иләндә». 12+
10.35 «Туган авылым». 12+
11.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
12.00 «Видеоспорт». 16+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.45 «Наша Республика - наше дело». 16+
14.45 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
15.45 «Ком сәгате». 16+
16.45 Хоккей. «Ак Барс» - «Нефтехимик». 6+
19.30, 22.30 «Семь дней». 16+
20.30 «Заман көзгесе». 6+
21.00 «Болгар радиосы» концерты. 16+
21.30 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.30 «ОБЛАСТИ ТЬМЫ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять».
7.00 «Адымнар». 16+
7.30 «Кто мы татары?» 12+
8.00 «Сәйдәш яры». 12+
9.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
10.00 «Әдәби хәзинә». 6+
10.30 «Күңелләрдә тальян моңнары». 12+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Гаилә учагы». 16+
13.50 «Tatarstan today. Дөньяга ачык». 16+
14.20 «Синең өчен сөюләрем». Азат һәм Алсу Фазлыевлар концерты. 16+
16.20, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+
21.50 Спектакль «Син бит минем бергенәм». 16+

«ЭФИР»
5.00 «Деревни России». 12+
5.20, 14.35 «Государственная грамота. Указы Петра I». 12+
5.45 «Прыг Скок в поисках сокровищ». 6+
7.00 «Смешарики. Новые приключения».
7.30 «Белка и Стрелка. Тайны космоса».
8.00 «География вкуса». 12+
8.15 «Наша марка». 12+
8.30 «СХВАТКА». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ОТЕЦ ПОНЕВОЛЕ». 16+
14.50 «Блин.Ком. Некоторые любят погорячее». 16+
15.50 «ПРЕСТУПЛЕНИЕ В ФОКУСЕ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «КРОВЬ И ВИНО». 16+
22.45 «ЛЮБОВЬ ПО РАСПИСАНИЮ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 Подкаст.лаб «20 лет спустя». 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Играем свадьбу!» 12+
11.05 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других». 12+
12.15 «Повара на колесах». 12+
13.10 «Видели видео?»
15.00 «Правдивая история. Тегеран-43». 12+
17.05 «Живое сердце танка». 12+
19.00 «Перепой звезду». 12+
21.00 «Время».
23.00 «Что? Где? Когда?»

«РОССИЯ»
6.15 «ТЫ БУДЕШЬ МОЕЙ». 12+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 Когда все дома с Тимуром Кизяковым.
9.25 Утренняя почта с Николаем Басковым.
10.10 Сто к одному.
11.00 Вести.
12.00 Большие перемены. 6+
13.00 «ВСТРЕЧНАЯ ПОЛОСА». 12+
17.00, 19.00 Песни от всей души. 12+
18.00 «Всероссийский телевизионный конкурс юных талантов «Синяя Птица».
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым. 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Доктор Айболит».
7.50, 8.10, 8.30, 8.50, 9.10, 9.30 «ПОРУС».
9.50 Диалоги о животных.
10.30 Больше, чем любовь.
11.10 «ГОРЕ ОТ УМА».
13.55 Невский ковчег. Теория невозможного. Алексей Львов.
14.25 «Игра в бисер» «Викентий Вересаев. «Записки врача».
15.05 «Элементы» с Григорием Голдовским».
15.35 «Великие мгновения музыки».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Музыка «летающих тарелок».
17.50 «Пешком...»
18.15 «Романтика романса».
19.10 «Макар».
19.30, 19.45 Новости культуры.
20.25 «СТАКАН ВОДЫ».
22.35 Балет «Поединок».
23.30 «Кинескоп».

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды…». 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Человек в праве». 16+
17.00 «Следствие вели…». 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 «Итоги недели».
20.20 «Шоу Аватар». 12+
23.10 «Звезды сошлись». 16+

Туган тел форумы

Казанда өч көн дәвамында Бөтенроссия «Туган тел» форумы булып узды. Аның эшендә Россиянең 28 төбәгеннән, шулай ук Татарстаннан 800 гә якын делегат – татар теле һәм әдәбияты укытучылары һәм мөселман дини укыту оешмалары мөгаллимнәре катнашты. Делегатлар форумның икенче көнендә Арчада белем бирү учреждениеләренең эшчәнлеге белән танышты, татар телен уку-укытуга бәйле көнүзәк мәсьәләләргә багышланган төрле педагогик остаханәләрдә катнашты. Форумның «Тәрбия. Белем. Тел» дигән темага багышланган пленар утырышы «Корстон» сәүдә-күңел ачу үзәгендә узды. Форум быел беренче тапкыр үткәрелде.

Соңгы елларда татар яшьләре, балалар арасында телебезне белүчеләр нык кимеде. Хәтта чепчи татар авылларда да үзара русча аралашу башланды. Бөтенроссия «Туган тел» форумы шушы вазгыятьне уңай якка борып җибәрү ниятеннән мәсьәләне уртага салып сөйләшүне күздә тотып уздырылды. Форумда бу уңайдан күп кенә фикерләр яңгырады, хәтта капма-каршылары да бар иде. Форумны ачып җибәргән һәм алып барган Бөтендөнья татар конгрессы Милли шура рәисе В.Шәйхразыев татар теле укытучыларының милләт сакчылары булырдай катлам, аларның милли хәрәкәт вәкилләре, халкыбызны әйдәп баручы көч булып торуын ассызыклап үтте. Туган (татар) тел һәм әдәбияты укытучылары ассоциациясе рәисе, Татарстан Мәгарифне үстерү институты доценты, филология фәннәре кандидаты Рузилә Фәттахова туган телне кадерләп саклау, аның сафлыгы өчен көрәшү эше нигездә ана теле укытучыларына йөкләнүен белдереп, залдагыларның игътибарын Татарстанда һәм Россия төбәкләрендә хезмәт итүче мөгаллимнәрнең эшчәнлеген татар теле һәм әдәбиятын предмет буларак укыту белән генә чикләнмәвенә искәртте. Татар теле укытучылары – балаларга милли тәрбия бирүче, халкыбыз мирасын киләчәк буынга тапшыручы төп көч. Ассоциация рәисе бу уңайдан Татарстан Дәүләт Киңәшчесе М.Шәймиевнең «татар теле, әдәбияты укытучылары татар телен саклау буенча аерым миссия үти» дигән сүзләрен искә төшереп, туган тел укытучысының хезмәте гаять киңкырлы булуын, күп энергия һәм ихтыяр көче таләп итүен ассызыклап, бу җаваплы эштә татар теле укытучысына һәр яктан ярдәм кирәклеген әйтте. «Туган телне саклауны укытучыларга гына йөкләп калдыру зур хата», – дип белдерде ул. Бу юнәлештә эш ата-ана ярдәменә таянып алып барылырга тиеш. Федераль закон нигезендә, әти-әниләр туган телләрне сайлау хокукына ия. Бу мәсьәлә исә аеруча четерекле. «Ата-аналар белән тиешле аңлату-агарту эшләрен оештыру игътибар сорый», – диде Р.Фәттахова. Ул ассоциациянең җирле оешмаларын булдыру тәкъдиме белән дә чыкты.

Ассоциация ил күләмендә 4 меңнән артык татар теле укытучысын үз сафларына алган инде. «Татарстан районнарында, Россия төбәкләрендә ассоциациянең җирле оешмаларын булдыру кирәк», – ди җитәкче. Моннан тыш оешманың уставы нигезендә, грантларга дәгъва итү өчен барлык мөмкинлекләр бар. Шуңа күрә ассоциация татар теле укытучыларының методик үзәге генә түгел, укытучыларга кыю проектларны гамәлгә ашырырга ярдәм итүче оешма буларак та күзаллана.

Татарстанның мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин фикеренчә исә баланың туган телне камил белмәвендә ата-ананы гына гаепләү дөрес түгел. Балалар бакчасы ата-аналарны гаепли, мәктәп укытучысы тәрбиячене күрсәтә. «Бу очракта «гаилә – балалар бакчасы – мәктәп» эш формуласы бербөтен һәм бердәм эшчәнлекне тәшкил итәргә тиеш», – ди министр. Аның фикенчә, бер-береңне гаепләү – туган телдә тәрбия кылу һәм укыту мәсьәләсен катлауландыра гына. Ә уңай мисаллар шактый. И.Һадиуллин бу мәсьәләдә үрнәк итеп Казан шәһәренең татар телендә тәрбия һәм белем бирүче 209 нчы балалар бакчасы һәм 1 нче татар гимназиясен китерде. «Алар арасында үзара киңәшеп, эшчәнлекне бер максатка юнәлтеп алып бару хезмәттәшлеге гамәлгә куелган һәм анда ата-аналарның роле дә гаять зур», – диде ул. Ул шулай ук Россия төбәкләреннән Саратов шәһәре татар гимназиясен һәм Самара өлкәсенең «Яктылык» мәктәбен, Татарстаннан данлыклы Ш.Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясен, Зәй шәһәренең Ринат Фәрдиев исемендәге гимназияне, Мөслим гимназиясен милли тәрбия бирү өлгесе булган уку йортлары дип атады. Мәгариф министры телне үзләштерү өчен иң кулай чор 6-7 яшькә кадәр икәнлеген әйтеп, сөйләм теле формалашуы өчен бик чикле вакыт бирелүен, ул чорны игътибарсыз уздыру киләчәктә бала өчен өстәмә авырлыклар тудырачагын да искәртте.

Татарстан Рәисе Р.Миңнеханов мондый җыеннарның, мәсьәләне уртага салып сөйләшүнең кирәк булуын белдерде. «Татарны бөтен дөньяда белергә тиешләр», – диде. Татарстан Рәисенең күңеленә «Туган тел» форумы уңаеннан «Корстон»ның беренче катындагы залда балалар мәгарифенә багышлап оештырылган күргәзмә дә хуш килгән. «Аны карагач, күңелдә тынычлык урнаша, анда якты киләчәгебез күренгәндәй булды», – диде ул.

Шулай ук ул республикада, Бөтендөнья татар конгрессында, Татарстанда яшәүче халыкларның туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясендә, Мәгариф һәм фән министрлыгында кыска гына вакыт эчендә күп эшләр башкарылуын һәм аның нәтиҗәсе булуын, эшне шушы юнәлештә алып барырга кирәклеген билгеләп узды. «Телебез безгә кирәк. Шуңа да гаилә, балалар бакчасы, мәктәп бер булып эшләүне үзебездән башлау мәслихәт. Укытучының роле зур. Шушындый форманы нәтиҗәле дип таптык, аны киләчәктә дә алып барачакбыз, башлаган эшләрне алга таба да дәвам итәчәкбез», – диде Татарстан Рәисе.

Чувашстанның Комсомол һәм Батыр районнарының татар авылларында балалар туган телебездә бик матур сөйләшә. Бу эшнең дөрес куелышыннан да килә. Тукай авылындагы «Мәхәллә йорты»нда алып барылган ислам дине кагыйдәләре һәм шәригать кануннары белән бергә гореф-гадәтләргә нигезләнгән татар тәрбиясе бирелү дә үрнәк итеп куярлык. Меңьярым халык яшәгән Тукай авылында мәктәптә дә татар теле, әдәбияты укытыла, үз гореф-гадәтләребезгә нигезләнгән татар тәрбиясе бирелә. Бу мәктәптә бишенче сыйныфка кадәр барлык дәресләр дә татар телендә алып барыла.

Әмма аларның да мәсьәләне тагын да яхшырту уңаеннан үз теләкләре бар. Комсомол муниципаль округы Тукай авылы мәхәлләсе имам-хатыйбы, «Мәхәллә йорты» мөдире Наил Ямалетдинов, Россиянең барлык мәктәпләрендә IV сыйныфта закон буенча «Дини мәдәниятләр һәм дөньяви этика нигезләре» укытылуын әйтеп, мәктәптә татар теле дәресен сайлаган кебек, бу фәнне дә теләк буенча аерып алып булуын әйтте. Теләгән бала – православие, яки ислам дине нигезләрен өйрәнә. Ләкин Ислам мәдәнияте буенча федераль белем стандартларында расланган китапның рус телендә генә булуы авырлык тудыра. «Бу фән татар балаларына үз телләрендә укытылса, дин мәдәниятен өйрәтү өстәмә татар теле дәресе булып торыр иде. Бу дәреслекне федераль исемлеккә кертсә, әйбәт», – диде Н.Ямалетдинов.

Мәхәллә имам-хатыйбы «Дини мәдәниятләр һәм дөньяви этика нигезләре»н татар мәктәпләрендә татарча укыту кирәклеген ассызыклый. «Чит төбәкләрдә бу аеруча мөһим мәсьәлә. Югыйсә, балалар пәйгамбәрне – пророк, иманны вера дип өйрәнәчәк, башка төшенчәләрне дә чит телдә кабул итәчәк», – ди. Ул «Мәхәллә йорты»н салуда Татарстан Рәисе Р.Миңнеханов ярдәм күрсәтүен әйтте. «Мәхәллә йорты»нда мәхәллә мәктәбе урнашкан. Анда теләге булган кешеләр, авыл балалары Чувашстанда бердәнбер дәүләт лицензиясе булган «Гөлстан» мәдрәсәсенең гамәлдәге программасы нигезендә укый, чәй мәҗлесләре, авылның иҗтимагый советы утырышлары уза. Мәчет залында гыйбадәт кылына.

Әстерханның Г.Тукай исемендәге 74 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе директоры, Татарстанның атказанган укытучысы Надежда Гоголева соңгы елларда татар теле, мәдәнияте белән кызыксыну артуын белдерде. Ул белем бирү планы кысаларында татар телен укытуны алга алып бару, хәзер татар теле дәресләре I-IX сыйныфларда кертелү, төрле милләт балаларының аны телеп өйрәнүе турында сөйләде. 2023 елда IX сыйныфны тәмамлаучыларның кайберләре беренче тапкыр татар теле предметы күрсәтелгән аттестат алган.

Казанның Яңа Савин районындагы 13 нче гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучысы, «Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы» Бөтенроссия конкурсы җиңүчесе Алинә Шәнгәрәева татар теле укытучысына җәмгыять тарафыннан таләпләр дә, игътибар да зур булуын белдерде. «Туган тел укытучысының абруе үзебездән тора. Татар телен югары дәрәҗәдә укыту өчен бездә бөтен шартлар да бар. Монда мескенләнеп утырырга кирәкми. Укучылар да хәзер күпне белә. Укытучы замана белән атламаса, укучыга кызык булмый», – диде.

Уфа фән һәм технология университеты Стәрлетамак филиалының татар һәм чуаш филологиясе кафедрасы мөдире Илсур Мансуров делегатларның игътибарын татар теле һәм әдәбияты белгечләрен әзерләүдә хәл ителәсе мәсьәләләргә юнәлтте. Әйтик, югары уку йортларында татар теле бүлекләрен саклау, студентлар җыю анда эшләүче педагогларның шәхси эшенә әверелеп киткән. «Хәзер инде милли бүлекләрдә белем алырга теләүчеләр элекке кебек күп түгел, төркемнәрне туплау зур кыенлык белән бара, укытучылардан зур тырышлык сорала», ди ул. Алар кафедрага укучыларны җәлеп итү өчен төбәк укытучыларына фәнни-методик ярдәм күрсәтү, бәйгеләр оештыру, студентларны фәнни-иҗади яктан үстерү кебек эшләр алып бара, имидж өчен заманча чаралар оештыра. Әмма абитуриентлар кирәгенчә чират тормый.

И.Мансуров Башкортстан уку йортларының барысында да татар теле һәм әдәбияты белгечләре әзерләү өчен шартлар тудырылган булуы турында да әйтте. «Республика җитәкчелеге кафедралар эшчәнлегенә уңай мөнәсәбәттә, материаль-техник базаны яхшырту, фәнни-педагогик кадрларны саклап калу, бюджет урыннарын бирү өчен барысын да эшли», – диде ул.

Форум уңаеннан беренче каттагы залда балалар мәгарифенә багышлап оештырылган күргәзмә белән танышканда, Татарстан китап нәшриятында балалар өчен чыгарылган басмаларның бай ассортиментына, «Сабантуй» журналы кече яшьтәге балалар өчен чыгарган кызыклы китапларга, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты эшләгән яңа буын татар теле һәм әдәбияты буенча укыту-методик комплекслар, институтның электрон проектларына да игътибар иттек. Күп телле «Адымнар» мәгариф комплексы күргәзмәсе янында аның директоры Айдар Шәмсетдинов белән дә гапләшеп алдык. Ул ата-аналарның таләпләрен кайгыртып, ике белем траекториясен тәкъдим итүләре турында сөйләде. «Уку йортында татар балалары өчен саф милли мохит булдырдык. Соңгы елларда Казанда бериш татар балалары туган телләреннән читләште. Аларны милләт сафына кайтару максатыннан Федераль университет галимнәре белән татарча сөйләшмәгән, әмма телебезне белергә теләүче балалар өчен уникаль Татар теле дәресләге эшләнде. Балаларны татар теле белән кызыксындыру ниятеннән ике атна саен аудио әкият чыгарабыз. Тулы метражлы ике нәфис фильмыбыз бар», диде ул.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотосы

Челтәрләрем – күңел бизәгем

Балык Бистәсе элек-электән зәркән осталары һәм челтәр бәйләүчеләр белән дан тоткан. Бүген шуларның берсен – челтәр үрүне Рәмзия Сәхәбетдин кызы Фәттахова торгыза. Ул Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетында төп милли һөнәрләребезне торгызу һәм үстерү максатында ачылган гамәли бизәү сәнгате бүлегендә белем алган. Әйтергә кирәк, анда укып чыгучылар шактый булса да, бүген үз һөнәрләре буенча эшләүчеләр бик сирәк.

Рәмзиябез шундый энҗе бөртегедәй кадерле кешеләребезнең берсе. «Гамәли бизәү кафедрасын синең өчен генә булса да ачарга кирәк булган», ди икән мөгаллимнәре. Шуларның берсе – челтәр бәйләү буенча оста Альбина Петровна Обрезкова. Ул әлеге һөнәрне 1990 елларда ук өйрәнү вә торгызу эшенә керешә. Үзенең укыту-өйрәтү методикасын булдыра. Әнә шул мөхтәрәм ханымнан белем ала да инде безнең Рәмзия. Ә укуын тәмамлап Балык Бистәсенә әйләнеп кайткач, кызны район мәдәният йортына эшкә чакыралар. Һәм Р.Фәттахова 2009 елда «Яңарыш» студиясен оештырып җибәрә. Бүген анда унлап кул остасы челтәр үрә. Иң сөендергәне, борынгы һөнәргә кызыгып балалар да килә. Рәмзияне үзен Татарстаныбызда гына түгел, Россия дә дә беләләр. Ул Алабугада узган зур ярминкәдә һәрдаим катнаша, «Каравон» фестивалендә дә кул остасын һәм аның челтәрләрен көтеп алалар. Һөнәрчеләр арасында үткәрелгән республика күләмендәге байтак бәйгеләрдә дә җиңү яулады.

Рәмзия Фәттахованың нинди зур эшкә алынганы әйбәтрәк аңлашылсын өчен, челтәр бәйләү һөнәренең тарихына күз салыйк. «Таткультресурсүзәк» сайтында челтәр бәйләү һөнәренең Бельгия, Италия, Нидерландта зур үсеш алуы, әмма галимнәрнең фаразларына караганда, Европага Шәрыктән керүе турында язылган. Рәсми мәгълүматларга караганда, Россиягә ул XVIII гасыр башында керә, әмма XVI-XVII йөзләрдә үк инде бездә авыл саен диярлек челтәр бәйләгәннәре мәгълүм. Казан төбәгендә дә нәкъ шул чорда челтәр бәйли башлаганнар дип исәплиләр. Бездә ике зур үзәк була. Берсе – Балык Бистәсендә. Тагын берсе – Мамадыш өязендә. 1887 елда бер Балык Бистәсе авылында гына да 255 челтәр бәйләүче исәпләнә. Мамадыш өязенең Нырты, Әбди, Покровка исемле өч авылында 280 оста челтәр бәйли. Бу саннардан чыгып, нәфис һөнәрнең нинди киң таралыш алуын чамаларга була. Кыз балаларны 7-8 яшьләреннән үк челтәр бәйләргә өйрәтә башлаганнар. Һөнәрнең тарихын тирәнтен өйрәнгән С.Давыдовның фикеренчә, крестияннәрне азат итү челтәр бәйләүне шактый какшаткан, элек алпавыт хатыннары крестиян хатын-кызларын туплап кул эшенә өйрәткән булса, 1861 елдан башлап ирек алган ярлы катлам гүзәл затлар таралып бетә, әмма һөнәрнең үсеше сүлпәнәйсә дә, өзелми. Балык Бистәсендә ике буын алпавыт Донауровлар челтәр бәйләү һөнәрен крестияннәргә ирек бирелгәннән соң да кайгырта, 1910 елга кадәр хатын-кызларны махсус укыта. XX гасыр башларында челтәр үрүчеләр шактый була әле, чөнки Бөтенроссия, халыкара күргәзмәләрдә кул эшләре зур бәяләнә, чит илләрдән сорау зур була. Мода үзгәргәч, чит илләр соратмый башлагач һәм крестияннәр җир эшенә күчә барган саен исә 1920-1930 еллардан башлап һөнәр үсеше нык сүлпәнәя һәм ахыр чиктә юкка чыга. Озак вакыт үткәч, 1990 елларда гына торгызыла башлый. Челтәрләрне бик сыйфатлы житен җепләрдән үрәләр. Ыргак белән түгел, «коклюшка», безнеңчә әйтсәк, җөя таякчыклары белән бәйлиләр. Челтәрнең бизәгенә, катлаулылыгына карап, таякчыклар 300 гә кадәр җитәргә мөмкин. Эш вакытында агач җөя таякчыклары бер-берсенә бәрелеп, чулпы, алка зыңгылдавына охшаш, музыка сыман нәфис бер тавыш барлыкка китерә.

Рәмзия Фәттахова белән Балык Бистәсе үзешчәннәре Татарстан Мәдәният министрлыгы оештырган «Республикабызның мәдәни башкаласы» бәйгесе кысаларында Казанга осталыкларын күрсәтергә килгәч таныштык. Ул үзе белән Балык Бистәсе туган як музее фәнни хезмәткәре Любовь Ахунованы да алып килгән иде. Челтәрләрен күрсәтеп кенә калмадылар, тамашачыларга махсус мендәрләргә куеп үреп тә күрсәттеләр. Гомумән, Рәмзиябез кая нинди ярминкәгә, күргәзмәгә барса да, туган төбәгендә ерак гасырларда чәчәк аткан борынгы һөнәр турында бәйнә-бәйнә сөйләп, халыкта кызыксыну уятырга тырыша. Шулай итеп кул остасы гына түгел, мәгърифәтче дә ул. Челтәрләребезгә сорау үскәннән-үсә бара, ди ул сөенеп. Иң мөһиме, Рәмзиянең яңалык кертү белән мавыкмыйча, һөнәрне ничек булган шулай торгызуы, традицияне бозмавы, мирасыбызга сакчыл каравы. Балык Бистәсе Олы Елга кызының нинди зур эшкә тотынганы аңлашылдымы инде хәзер!? Һәрбер милли һөнәр төрен торгызырга Рәмзиядәй кыю, талантлы, эшкә бирелгән осталар булсын иде...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип
Мөнирә СӘГЫЙДУЛЛИНА

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;
222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;
222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;
222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 24.11.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2550 данә

Заказ 2645

16+